ИДЕЛ
Яшьләр журналы
2017, №08 (335)
1989 елның июль аеннан чыга



# ЭЧТӘЛЕК

*Сөй җирене, сөй халыкны,
Сөй халыкның дөньясын!*


**2** ТҮР БАШЫ
**Ландыш ТИМЕРОВА**
*Үсеш – лотерея түгел, җитди эволюция процессы*

**6** СӘЛБИТ
**Ландыш ЗАҺРЕТДИНОВА**
*Кабат Биләргә кайттык*

**8** ВӘЗГЫЯТЬ
**Лилия НУРМӨХӘММӘТОВА**
*Җитәкчеңә ничә яшь?*

**11** ИДЕЛ-ЙОРТ
**Энҗе БАСЫЙРОВА**
*«Татар кызына өйләнүем – күкләрдә язылган никах»*

**14** ШАГЫЙРӘ ЮЛЪЯЗМАСЫ
**Рифә РАХМАН**
*Аурупага яңа заманда сәяхәт*

**17** КӘСЕП-КӘСӘБӘ
**Мәрьям НАСЫЙРОВА**
*Нефтьне өчпочмакка алмаштыру нәрсәгә китерә?*

**20** ЛӘБИБИ ХӘТЕР
**Ләбиб ЛЕРОН**
*Абитуриент көндәлеге – 2*

**24** ШИГЪРИЯТ
**Рөстәм МИНГАЛИМ**
*Кулым сузып, тамчы җыям учыма*

**26** ШИГЪРИЯТ
**Айгөл ХӘСӘНОВА**
*Кабат янмас йөрәк уйакта, Күзләремдә сагыш бар чакта...*

**27** ШИГЪРИЯТ
**Эльвира РӘФЫЙКОВА**
*Бастырылган һава – һава түгел...*

**28** ШИГЪРИЯТ
**Гөлүсә АРИКЕЕВА**
*Сәйләннәр иленә сөйләрсең*

**30** ДҮРТ ХИКӘЯ
**Рүзәл МӨХӘММӘТША**
*Сәер кеше*

**35** ӘДӘБИ БӘЙГЕ
**Гөлназ МӘХМҮТОВА**
*Бал корты*

**36** ТӘРҖЕМӘ
**Ленар ШӘЕХ**
*Якут киңлекләре яңгырашы*

**40** НӘСЕР
**Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА**
*Кем беренче?*

**58** АВЫЛ ҺӘМ РУХ
**Гөлүсә ШИҺАПОВА**
*Мунчәлием, син минем йөрәк тибешем!*

**62** ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛ
**Рамилә НОТФУЛЛИНА**
*Нурмый бабай игелеге*

**64** МӘДРӘСӘ
**Энҗе БАСЫЙРОВА**
*«Кыйбласыннан барыбер тайпылмас иде»*


**67** ИҖТИҺАД
**Радик САБИРОВ**
*Яшәүче яшәргә тиеш!*

**70** СӘХНӘ АРТЫНДА
**Эльвира ШАКИРОВА**
*Башкортстан җырчылары гади. Чөнки алар артта калган?*


**74** СӘЛӘТЛЕЛӘР МӘКТӘБЕ
**Сөмбел ӘХМӘТҖАНОВА**
*«Халкымның тагын да грамоталы булуын телим»*

**76** ЯШЬЛӘР ГАЛӘМЕ
**Лиана МӘРДАНОВА**
*Зәринә Хәсәншина: «Җебеп торырга яратмыйм»*

**78** ЯҢА ДУЛКЫН
**Рәйсә БОРҺАНИЕВА**
*Лилия Кадыйрова: «Креативлыкның милләте юк»*





**ИДЕЛ-ЙОРТ**
*«Татар кызына өйләнүем – күкләрдә язылган никах»*



**КӘСЕП-КӘСӘБӘ**
*Нефтьне өчпочмакка алмаштыру нәрсәгә китерә?*



**ЛӘБИБИ ХӘТЕР**
*Абитуриент көндәлеге-2*

# Заман

*түр башы*

**Ландыш Тимерова**

## Үсеш – лотерея түгел, җитди эволюция процессы

Тимур Сөләйманов белән «Сәләт-Беләр» форумында очрашырга сөйләштек. Форумга кунаклар өзлексез килеп тора, аларның һәрберсен директор Тимур абый («Сәләт»тә абый, апа дип эндәшү гадәткә кергән) елмаеп үзе каршы ала, матур итеп озатып кала. Без әңгәмә корыр алдыннан гына да Тимур Сөләйманов бер төркем чит ил кунаклары белән алар телендә сөйләшеп, аралашып алды. Һәр сәлкешне елмаеп сәламли, кул биреп күрешә ул. Олыны да, кечене дә – һәммәсен бердәй хөрмәтләүче җитәкче белән әңгәмә кордык. Бүгенге көн лидеры кем ул? Яшь җитәкче нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Киләчәкне ничек күзаллый? Гомумән, яшь лидерны бүгенге көндә ни борчый һәм ул нинди уй-хыяллар белән яна? Шундый һәм башка күп кенә сорауларны «Сәләт» Фондының башкарма директоры Тимур Җәүдәт улы Сөләйманов белән ачыкладык.




**Тимур, Сез балачактан ук бик актив, иҗади бала булгансыз, олимпиадаларда, төрле бәйгеләрдә уңышларга ирешүегезне дә беләбез. Шулай да, җитәкче булу өчен лидерлык сәләте дә кирәк бит әле. Җитәкчелек маһирлыгы Сезгә кайдан килә?**

Иң мөһиме – кешегә сыйфатлы, тиешле мохит кирәк. Икенчедән, әлбәттә, ул – укытучылар. Менә шул ике критерийны үземә «Сәләт» бирде. Лидерлык сыйфатларын, профессиональлекне үстерер өчен, кайсы өлкәдә алсак та, мохит һәм укытучылар кирәк. Әлбәттә, гаиләдән дә күп нәрсә тора. Әмма әти-әни гел эштә, вакытлары җитми. Җиде яшькә кадәр балалар һәрвакыт ата-анасы белән. Унөч яшьтән алып, алар күбрәк үзара сөйләшә, сорауларына җавапны мәктәптә, дус-ишләре аша таба, кызыксынган нәрсәләрне интернеттан эзли. Шул яшьтә балага аеруча зур игътибар таләп итела, нәкъ шушы вакытны югалтырга ярамый. Унөч-уналты яшьтә балалар әле үзләрен эзли һәм аларга мөмкинлекләр мохитен булдыру әһәмиятле. Шәхсән үзем өчен

мине тәрбияләүдә «Сәләт» – беренче, хәзер дә шулай.

**Бер ел дәвамында Испаниянең Гранада университетында белем алу тәҗрибәсе Сезгә ни дәрәҗәдә ярдәм итте? Җитәкчеләргә чит илдә уку, чит телләр белү кирәкме?**

Лидер булу өчен генә түгел, читтел белү – һәрбер кешегә кирәк. Ул, беренчедән – яңа тәҗрибә, аны өйрәнгәндә син көчәя барасың. Икенче яктан, телне белгәч, тагын да күбрәк мөмкинлекләр ачыла. Чит илдә уку минем өчен бик зур тәҗрибә булды. Син яңа җиргә килгәндә берәүне дә белмисең, сине дә бер кеше белми. Димәк, яңабаштан үзеңне күрсәтергә, яңа дуслар табарга тиешсең. Мөнәсәбәтләрне чит телдә корганда тагын да авыррак. Беренче ай бик читен булды, ә менә өч-дүрт айдан соң, яңа телне ныклап үзләштергәч, җайланды. Минем өчен зур сынау вакыты иде ул. Шул юл белән холыкны тәрбияләп була. Бөтен нәрсә әзергә-бәзер, менә ал дип бирелсә, син үз потенциалыңны берничек тә күрсәтә, ача алмыйсың. Телләрне өйрәнү бүгенге көндә аеруча әһәмиятле. Зур планнарны тормышка ашыру өчен инглиз теле һәм башка чит телләрне белү бик кирәк. Мәгълүмат ул бит төрле илләрдән, төрле телләрдә ирешә. Туксан проценты – инглиз телендә. Мин туган телем – татар, шулай ук урыс, инглиз, испан телендә сөйләшәм. Калган телләрне, шул ук алман телен, мәсәлән, күпмедер аңлыйм, аралаша да алам.

**Сез җитәкчелек эшен башкарудан тыш, фән белән дә шөгыльләнәсез. Читен түгелме?**

Диссертацияне әле яклыйсы бар. Теманы үзгәртеп, «Сәләт» белән бәйләргә ниятлим. Хакимият, төрле оешмалар кеше капиталын үстерергә ничек ярдәм итә ала, сәләтле яшьләр Татарстанда калсын өчен бүгенге көндә нинди шартлар тудырырга кирәк? Безнең студентларның, яшьләрнең чит илгә китүе начармы, әллә әйбәтме, мәнә шул мәсьәләләр бик кызыклы. Яшьләрнең чит илгә барып укырга теләкләре булуда бер начарлык та юк. Бу – алар өчен мөмкинлек, дөнья зур, матур икәнен күрсеннәр. Үзебезнең туган җиребезне уңайлы, сыйфатлы, бәрәкәтле, сагынып кайтырлык урын итәргә тырышырга тиешбез. Испаниядә бер ел укыдым, әйе, матур, мөмкинлекләр бар, яңа кешеләр күп, шартлар шәп… Әмма анда калмадым, туган җиремә кайтасым килде, чөнки монда да мөмкинлекләр җитәрлек. Иң мөһиме – Татарстанда шундый шартларны булдыру. Көч белән яшьләрне берничек тә тотып калып булмый, кирәк тә түгел ул. Барсыннар, алар бит безнекеләр, дөньяда никадәр күп булсак, шулкадәр әйбәт. Әмма карашларыбыз, уй-фикерләребез барыбер туган җиребез белән бәйле булырга тиеш.



**Җитәкче кеше һәрвакыт формада булса, физик һәм акыл ягыннан гел үсешкә омтылса гына башкаларны үз артыннан әйди ала. Моның өчен ниләр эшлисез? Сез бик оста биюче дә бит. Бүгенге көндә әлеге сәләтегезне эшкә җигәсезме?**

Мин футбол уйнарга яратам. Кичә менә дуслар белән, вакыт табып, баскетбол уйнап алдык. Җиде ел бал биюләре белән шөгыльләндем. Төрле зур халыкара чараларда ул һөнәремнең дә кирәге чыкты. Әйтик, 2015 елда Швейцариядә Давос шәһәрендә узган зур форумда катнашырга туры килде. Форум кысаларында бию белән бәйле чаралар да булды, вальс, фокстрот биедек. Әмма бию, спорт минем өчен – хобби гына. Спорт та холыкны тәрбияли. Җиңәсеңме-җиңеләсеңме, син һәрвакыт күнекмәләргә килергә, авырмы-түгелме – аңларга тиешсең. Парлап биисең икән, син парың өчен дә җаваплы. Командада эшләү ул – зур җаваплылык. Спортта да, башка өлкәдә дә шулай.

**Тимур, белемнәрне көнкүрештә куллану, күрсәтү, файдалану өчен нишләргә кирәк? Туктаусыз алга ыргылган тормышта ничек мәгълүматлы булырга?**

Укырга кирәк. Хәзерге вакытта мәгълүмат кытлыгы юк. Минем эш сәгатем иртәнге җидедә башлана. Җидедән сигезгә кадәр иң шәп вакыт, чөнки әле шылтыратулар юк, син дә шылтырата алмыйсың, берәү дә әле ул вакытта эштә түгел. Юлда, хезмәткә керешкәнче шәхесне

**«Лидерны, профессиональлекне үстерер өчен, кайсы өлкәне алсак та, мохит һәм укытучылар кирәк».**

үстерүгә бәйле лекция-видеолар карыйм, мәкаләләр укыйм. Иртә белән без йокыдан торгач теш чистартабыз, юынабыз – ул гадәткә кергән. Һәр иртәдә мәгълүмат туплауны да шулай гадәткә кертү бик мөһим.

**Үз тормышыңда нинди вакыйгаларны «Бу – минем тормыш юлымда иң зур баскыч» дип әйтә аласыз?**

Үсеш ул – эволюция процессы, лотерея сыман, нәрсәдер булды да тормыш үзгәрде түгел. Эволюция вакытында һәр мизгел, тормыш дәресләре, укытучылар да бик әһәмиятле урын алып тора.

Әле бию белән мавыкканда беренче өч елда гел ахыргы урыннарда идем. Әмма аңа карап кына туктамадым, тырыштым, ныграк көч сарыф итеп биедем. Нәтиҗәдә, берничә титулга лаек булдым. Бу – минем өчен яхшы сабак. Тагын берсе – җиңү дәресләре. Соңгы урынны алып, барыбер күтәренке кәеф белән дәвам итә белү – бер нәрсә, беренче урынны яулап, тагын да алгарак омтылып кара! 2005 елда «Ел студенты» премиясенә лаек булдым. Җиңдем, җитте, бар да шәп, дип туктап та була. Испаниягә барып, яңадан үземне күрсәтә алуым шулай ук мөһим баскыч иде. Гаилә кору, бала туу да – тормышымда зур вакыйгалар. Алар һәркайсы кеше тормышына йогынты ясый һәм шәхесне үстерә. Минем өчен тагын бер бик мөһим баскыч ул – «Студентлар лигасы», дүрт ел дәвамында шул оешманы җитәкләвем. Анда яңа команда тупларга, ректорлар белән мөнәсәбәтләр җайларга, беренче тапкыр Президент белән очрашуларда катнашырга кирәк булды. Хәзер инде туплаган белем-тәҗрибәмне «Сәләт»тә йөз процент кулланырга тырышам.

**Җитәкче буларак Сезне нинди авырлыклар, кыенлыклар сагалады? Истә калырлык форс-мажорлар килеп чыкканы бармы?**

Һәрвакыт нииндидер бер хәлгә тарыйсың инде, аларны хәзер генә сөйләү кызык. Шул мизгелдә исә һәрбер проблемалы ситуация форс-мажорлы. Иң истә калганы ике ел элек булды. «Сәләт-Биләр»гә Президентыбыз килергә тиеш, каршы алырга инде без әзер, остаханәләр башланды. Бөтен министрлар мәртәбәле кунакны каршы алырга җыелды. Президент килергә биш минут калды дигәндә, көчле давыл купты! Башта тавышын ишеттек. Карасак, урман ягыннан ун-унбиш метрга тузан күтәрелде, дивар сыман яңгыр безгә таба килә. Чын мәгънәсендә гадәттән тыш хәл иде бу! Менә шул вакытта нишләргә белмәдек. Сәхнәгә йөгердем. Микрофонны алып: «Гадәттән тыш хәл, барыгыз да палаткаларга керегез!» – дидем. Ә монда өч мең биш йөз кеше! Ярый ла команда әйбәт, үз эшен тиешле югарылыкта башкарды. Чатырларга качтык. Яңгыр җиде минутта үтте дә китте. Табигать шартлары начар булу сәбәпле, Президентка очкычка утырырга рөхсәт бирмәгәннәрдер, дип уйладык. «Мондый хәл булгач, Президент килми ахрысы», – дип күпердән чыгып барганда ни күрим: безгә таба Президент атлый. Җәяү. Шаккаттык. Илбашы килгәч, кояш та күренде. Инде остаханәләрне яңадан башлап җибәрдек. Ул бит ике йөз кеше булганда бер хәл, өч мең биш йөз булса – икенче. Андый вакыйгалар балалар, әйдаманнар, әти-әниләр белән дә булгалап тора. Балаларның кайсыдыр: «Миңа монда ошамый, монда «слишком много татарского языка, не хочу», – ди. «Син монда татар телле мохит икәнен белмәдең мени?» – дип сорыйбыз. Ә ул: «Белдем, тик миңа не хочется», – ди. Ел саен икенче-өченче көнне берике бала шулай кайтып китә.

**Командам яхшы, дидегез. Зур эшләрне тормышка ашыру өчен яхшы команда, терәк һәм таяныч булырдай кешеләр кирәк шул. Аны ничек туплыйсыз?**

Кешеләр белән аралашканда, команда туплаганда, үзем өчен ике төп критерийны ачыкладым. Беренчесе – намуслылык, әхлаклылык, икенчесе – профессиональлек. Профессионал ул – бер урында тукталып калмый, һәрвакыт яңа белемгә омтыла, мәгълүмат эзли торган кеше. Әй, мин аны беләм инде, дип әйтә икән, үсеш туктала. Фәндә дә, бизнеста да шулай.

**Яшь җитәкчеләргә хөкүмәт тарафыннан ярдәм бармы? Кайсы яклап ярдәм итүләрен телисез?**

Хөкүмәткә без бик рәхмәтле. Ярдәм булмаса, мондый шартлар тумас иде. Күп ярдәм булса да, аз ярдәм булса да, әлеге эшне барыбер башкарыр идек, чөнки безнең яшәү мәгънәсе – «Сәләт». Аны дәүләткә кирәкле көч дип саныйлар, ярдәм итәләр икән, бу бер яктан – бәя, икенче яктан – җаваплылык, чөнки без дә нәтиҗәләр күрсәтергә тиешбез. «Сәләт-Биләр» форумына ел саен Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм күп кенә махсус кунаклар килә. Кемдер матди яктан, кемдер оештыру ягыннан булыша. Балалар – бүгенгебез дә,



## «Бөтен нәрсә әзергә-бәзер, менә ал дип бирелсә, син үз потенциалыңны берничек тә күрсәтә, ача алмыйсың».

киләчәгебез дә. Барлык ресурсларны без аларга бирергә тиеш, чөнки балалар шул ресурсларны кулланып үссә, без үзебез дә, дәүләтебез дә, Татарстаныбыз да көчле булыр.

**«Сәләт» – татар телле мохит, дибез. Әлеге сүзләр ни дәрәҗәдә чынбарлыкка туры килә? Бүгенге яшьләребезнең күбесе ана телен арткы планга калдырып килгән бу заманда татар телле мохитне булдыру, саклау авырмы? Әлеге җаваплы юнәлештә эшләүдә нинди тәҗрибәләрегез бар?**

Һәрвакыт тарихка таянабыз, телебез турында беркайчан да онытмыйбыз. Тел һәм тарих – һәрчак бергә. «Сәләт-Биләр» форумының темасы – дүртенче сәнәгать революциясе. Аланнарның атамалары да хан исемнәре белән аталды – Атилла бабайдан башлап, Икрам ханга хәтле. Балалар кызыксыналар, дип уйлыйбыз. Тарихны мавыктыргыч форматта бирергә тырышабыз. Төркемнең исеме, әйтик, Аспарух икән, алар барыбер, ник Аспарух икән, дип, өйләренә кайткач та эзләнәчәк. Аларда иң элек кызыксыну хисен уятырга кирәк. Телне дә җиде, унсигез көндә берничек тә өйрәтеп бетереп булмый. Балалар мәктәптә унбер ел дәвамында көн саен диярлек татар теле укып та, күбесе телне белми. Ни өчен? Чөнки кызыксынулары юк. Кызыксыну булса, алар мәгълүматны үзләре дә ала. Татар телен бер дә белмичә киләләр, әмма, янып китеп, яңа сүзләрне өйрәнәләр, икенче елга, бәлки берике елдан соң әйдаман булып монда яңадан кайтырга уйлыйлар. Андый теләгең бар икән, татар телең менә дигән дәрәҗәдә булырга тиеш. Тел белү дәрәҗәсе юк, әмма Канадага барырга тели икән, «Сәләт-Монреаль»га тел белмәгән килеш юл ябык. «Сәмрух» премиясен алырга телисең икән, рәхим итеп, телне өйрән. Бу – мотивация. Кирәк дип бөтен кеше әйтә, тик ул мотивация түгел. «О, мин Канадага барырга телим, ул бик кызык, шуңа күрә мин үзем өйрәнәм», – ди бала һәм өйрәнә. Кирәк сүзен без әйтмибез. Юк, кирәкми, өйрәнмә, тик син бармыйсың, шул гына.

**«Идел» журналына биргән бер интервьюда «Сәләт» – социаль лифт», дигән идегез...**

Лифт ул өскә-аска йөри. «Сәләт» – канатлар. Кешегә канатлану кирәк, син үзең оча аласың. Ул – мөмкинлекләр мохите. Социаль лифт дип тә әйтеп була, әмма канат белән чагыштыру миңа күбрәк ошый.

**«Сәләт» – лидерларны барлый, әзерли торган оешма, дидек. Күзәтүләрегездән чыгып әйтегез әле, республикада өметле яшьләр, үсеп килүче лидерлар бармы? Алар белән ничек эшлисез?**

Әлбәттә, бөтен юнәлешләрдә дә бар. Ел саен яңа буын килә. Минемчә, зур юнәлеш – ул хәзерге заманда булган мөмкинлекләрне балаларга дөрес итеп күрсәтә белү. Чөнки мәгълүмат миллионлаган. Китапханәгә барасы юк, энциклопедия эзлисе юк, интернетны ач та кара. Әмма аны балаларга дөрес итеп күрсәтергә һәм кызыксындырырга кирәк. Мин «Сәләт»тә 2002 елда сәлкеш булдым һәм без яшәгән лагерь белән мондагыларын янәшә куярлык түгел. Хәзер бассейннар, мунчалар... Шәп шартлар. Әмма шул шартларның тәмен, рәхәтен күрә һәм рәхмәтле була белергә, дөрес итеп кулланырга гына кирәк. Шуңа күрә без монда балаларның иң-иңнәрен чакырабыз. Шартлар тудырабыз һәм хәзерге замана яшьләренә әйтәбез: менә бу сезнең старт позициясе. Сез бездән дә алдарак барырга тиеш, чөнки без – дәвам итүчеләр. Мин үзем эти (*Җәүдәт Сөләйманов,* – ***авт.***) башлап җибәргән эшне дәвам итәм, ул – минем остазым, укытучым.

**Сезнеңчә, уңышның сере нидә? Җитәкче кешегә кайсы сыйфатларга ия булу кирәк? Лидерлыкка омтылган яшьләргә нинди киңәш бирер идегез?**

Лидер үзе генә түгел, команда өчен дә җаваплы. Үз эшеңне җиренә җиткереп башкару һәм җаваплы кеше булу – бер әйбер. Командада барыбыз да бер максатка таба барабыз, шул ук идея, принципларга таянабыз икәнлеген аңлау таләп ителә. Әмма лидер ул – төп җаваплылыкка ия булганлыгын тоя торган кеше.

Яраткан эшеңне табу – уңышның яртысы. Иң авыры – дөрес юнәлешне, кызыксынган эшне, хоббины кәсеп итү. Икенчесе – хезмәт сөю. Эшләргә, эшләргә, эшләргә, шул хезмәтнең рәхәтен, тәмен тоя белергә кирәк. Шул очракта команда да, тырышлыгыңны күреп, хөрмәт белән карар һәм синең белән бергә эшне таләп башкарыр. Акчасы да килер, ресурслары да булыр, иң мөһиме – яраткан эшеңне табу һәм бирелеп хезмәт кую.

Яшьләргә киңәшем шул: янып йөрү, тырышу, бер урында туктап калмау, әмма ашыкмау әһәмиятле. Әлбәттә, үзеңне төрле яктан сынап, тәҗрибә туплауны хуплыйм. Ләкин инде бер юнәлешне сайлыйсың икән, шуның нигезенә хәтле кереп китәргә, асылына төшенергә, белгеч булырга омтылырга кирәк.



Ландыш Заһретдинова

# КАБАТ БИЛӘРГӘ КАЙТТЫК

Ике дистә елдан артык инде һәр ел саен Изге Биләр каласы, мәгъруp Хуҗалар тавы, Изге Чишмә буе Татарстан район-шәһәрләреннән генә түгел, Русиянең башка төбәкләреннән, хәтта чит илләрдән килгән иң сәләтле, иң булдыклы, иң тәрбияле һәм акыллы балалар, яшьләр авазыннан яңгырап тора. Әллә шуңа, биредә табигать тә Форумда катнашучыларның самими куанычларын үзенә сеңдергән төсле тоела. Мондагы шагыйранә матурлык, «Сәләт»леләрнең гаҗәеп җанлы һәм искиткеч куәтле энергетикасын җыйган мохит бүтән беркайда юк! Биләр Форумын үзем дә, сабыйдай куанып, үзгә бер ашкыну белән көтеп алам. Бирегә килгән һәр катнашучы, кунаклар, «Сәләт» ветераннары да шундый ук җылы хисләр кичерүенә иманым камил.

Изге Биләр җирлегенә быел бергәләшеп җыелып, «Идел» коллективы белән аяк бастык. Күп кенә хезмәттәшләрем – «Сәләт»нең ветераннары. Казан-Биләр арасында сузылган күңелле сәяхәтебез дәвамында нәкъ менә «Сәләт»кә бәйле истәлекләр белән уртаклаштык, хатирәләрне яңарттык, рәхәтләнеп ял иттек.

Бу елда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме буенча «Сәләт» форумы ике сменада узды. Әлеге форумнар үзендә Русиянең төрле төбәкләреннән, Татарстанның барлык районнарыннан, якын һәм ерак чит илләрдән килгән сигез меңнән артык иң-иң

Фотолар «Сәләт» архивыннан алынды







сәләтле балаларны һәм яшьләрне үзенә җыйды. «Тамырларыгызны тоеп, бирегә төрле яктан тупланасыз. Сәлам, балалар; ачык, аяз күк кебек әйдаманнар; килгән кунаклар, табигатебез!» – дип сәламләде Форумда катнашучыларны Әдип Әлмир.

Биш йөзләп эксперт, укытучы Форумны тиешле югарылыкта үткәрүгә көч кертте. Гүзәл Биләр җирендә эшчәнлеген җәелдергән чарада иң мөхтәрәм һәм мәртәбәле кунак – Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та булып китте.

Форумда «Дүртенче сәнәгать революциясе контекстында белем алу» темасын үзәккә алып эшләде. Шулай ук аның программасы уку-укыту технологияләре белән танышуга йөз тоткан иде. Моның өчен киләчәк буынның һөнәри ориентациясе, үзлектән белем алу үзенчәлекләре буенча күнекмәләр булдырылды. Биредә барлыгы йөз сиксән тематик уку-укыту мәйданчыгы эшләде. Алар интерактив очрашулар, дискуссияләр һәм остаханәләр форматында тормышка ашырылды.

Форумның өстәмә темасы – «Экология һәм тотрыклы үсеш» дип исемләнгән. Ул арт-объектларда, тотрыклы үсеш максатлары уенында, Татарстанның һәм Русиянең әйдәп баручы экспертлары, галимнәре белән тематик очрашулар барышында, һөнәри осталыклар лабораториясе эшчәнлегендә ачылды.

Биләр Форумы кысаларында үткән «Сәләт» берләшмәсе ветераннарының II Эшлекле Форумы зур бер вакыйга булды. Монда «Сәләт»тә төрле елларда килгән биш йөз катнашучы җыелды. Әлеге эшлекле форум «Сәләт» ветераннары арасында үзара тәҗрибә уртаклашу, тупланган тәҗрибәне яшь буынга да җиткерү максатыннан оештырылды.

«Сәләт»тә олыга да, кечегә дә хөрмәт зур. Шулай итеп, Форумның аерылгысыз бер юнәлешен тәшкил иткән «Бәләкәч» балалар клубын да телгә алу кирәк. Анда «Сәләт» хәрәкәтенең иң кечкенә әгъзалары тәрбияләнә. Ике яшьтән алып җиде яшькә кадәрге сабыйлар театр, музыка, инглиз теле һәм рәсем сәнгате буенча дәресләр алды.

Биредә яңалык, кызыклы мизгелләрне тотып алып, катнашучыларга гына түгел, бөтен дөньяга ирештерү өчен алны-ялны, көнне-төнне белмичә эшләгән медиа-үзәк кызлары-егетләре дә игътибарга лаеклы. «Сәләт TV» телевидениесе, «Сәләт FM» радиосы эшчәнлеген билгеләмәсәк, тулы картинаның бер чите төссез калыр сыман.

...Төрле яктан һәрбер аланның сөрәннәре яңгырый. Берсеннән-берсе кызыклы сүзләрдән тезмәләр, самими балалар тавышыннан катнашучылар күңелендә шатлык-сөенеч уяна; җылы атмосфера, якын һәм рәхәт мохит һәркемне үз куенына сыендыра да бәхетле мизгелләр хасил итә. «Сәләт» дөньясында ел дәвамында кайнап, киләсе елда да Хуҗалар тавы киңлекләренә килү нияте белән таралышты балалар, саубуллашу мизгелләрендә күзләрендә энҗе бөртекләре ялтырый иде...











Лилия Нурмөхәммәтова

# Җитәкчеңә ничә яшь?

Хезмәт базарының яртысын 30-49 яшьлекләр алып тора. 20-29 яшьлекләр – 23,9, 50-59 яшьтәгеләр – 22,5, 60 яшьтән узучылар 4,4 процент чамасы икән. Татстатистика мәгълүматларына күз салсак, республикада эшләүче кешеләрнең уртача яше 40 чамасында. Хезмәт базарындагы вәзгыять аңлашыла, ә җитәкче урыннарда хәлләр ничек? Зур дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр арасында 40 яшьләр тирәсендәгеләр, аннан яшьрәкләр бармы? Бу сорауга без дә җавап табарга тырышып карадык.

**«КОМСОМОЛ КЕШЕ ИТТЕ»**

Яшерен-батырын түгел, совет чорында яшь буын белән эшләү ныклы куелган иде. Октябрят, пионер, комсомол оешмалары гөрләп торды. Ул чорда комсомолларны үстерү дигән нәрсә бар иде. Үзеңне күрсәтә аласың икән, үрләр яуларга була. Аеруча активларны, алдынгыларны КПСС сафларына кабул иттеләр. Бу исә дәрәҗәләргә ирешү өчен мөмкинчелек барлыкка килә дигән сүз иде. Заманалар үзгәрү белән әлеге системаны да таркаттылар. 1970-1985 еллар аралыгында туучыларның кайсысы бу оешмаларның ничек эшләвен бераз күреп калды, яшьрәкләре бөтенләй ни икәнен дә аңламады. Бүген менә шушы буын хезмәт базарының төп көче булып санала да инде.

– Илдә егерме еллар дәвамында яшьләр белән эшләү нык аксады, – дип бу уңайдан үзенең борчуын җиткерә профессор, хирург, КДМУда булачак табибларга бирем бирүче Иван Клюшкин. – Шөкер, соңгы вакытта төрле хәрәкәтләрне кабат яңарттылар. Аларның исемнәрен, эшләү алымнарын үзгәртсәләр дә, асылы шул килеш калды. Элек ватанпәрвәрлек төшенчәсе бар иде. Безне Ватанны яратырга, аңа хезмәт итәргә өйрәттеләр. Заманында көчле рухлы шәхесләрне шулай тәрбияләргә тырыштылар. Без – шул буын кешеләре. Үткәннәрне сүгәргә ярамый. Ул чорның балаларын, шул исәптән мине дә, әлеге система зур тормышка чыгарды, кеше итте.

Хәзер яшьләр белән эшләү ничек соң? Сүз дә юк, соңгы елларда алар бергә туплана башлады. Иҗтимагый үзәкләр генә дә республикада егермеләп тирәсе. Аларның һәрберсе талантлы яшьләрне барлау, үстерү өчен оештырылган. Мондый иҗтимагый эшләрдә катнашучыларның фикерләү дәрәҗәсе дә башка. Алар тормышка икенче күзлектән карый, яңа омтылышлар белән яши, яңалыклар алып килергә тырыша. Белгечләр яшьләрнең бу рәвешле калкып чыгуы ил үсеше, икътисады өчен дә кирәк булуын белдерә. Моннан берничә ел элек өметле, талантлы кадрларны барлау максатыннан республикада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен кадрлар хәзерләү, туплау

юнәлешендә эш башланып китте. Әлеге хезмәт республика Президенты фәрманы нигезендә алып барыла да инде. Бүген җитәкчеләр арасында яшь, аңа исемнәр калкып чыккан икән, бу – белемле кадрлар белән эшләүнең җимеше.

**МИНИСТРЛАР**

Министрлар Кабинетының рәсми сайтыннан түрәләрнең биографиясен карап утырганда, иң беренче булып авыл хуҗалыгы һәм азыктөлек министрлыгына күз төште. Иң озак кәнәфидә утырган министр да Марат Әхмәтов булып чыкты. Ул 1999 елдан алып бүгенгәчә әлеге вазифада. Министрлыкта яшьләр шактый, бүлек җитәкчеләре арасында аларны күп күрергә була. Ә менә урынбасарлар, күбесенчә, өлкән кешеләр. Бары күптән түгел генә билгеләнгән Олег Земсков кына 1973 елгы. (Аңа кадәр бу постта эшләгән Марат Җаббаров 1983 елгы иде.) Башка министрларның яшьләренә килгәндә, Азат Хамаев (җир), Алмас Нәзиров (урман), Айрат Сибагатуллин (мәдәният) 60 яшь тирәсендә булсалар, 1960-1969 еллар арасында туучылар – Энгель Фәттахов (мәгариф), Ирек Фәйзуллин (төзелеш), Рафис Хәбибуллин (гадәттән тыш хәлләр), Радик Гайзатуллин (финанс), Ленар Сафиннар (юл) булып чыкты. Гадел Вафин (сәламәтлек), Роман Шәйхетдинов (элемтә), Эльмира Зарипова (социаль яклау), Фәрит Габделганиев (экология), Альберт Кәримов (сәнәгать, сәүдә), Владимир Леонов (яшьләр, спорт), Артем Здунов (икътисад) 1970 елларда туучылар. Яңа сулыш алып килүчеләр дип, алар турында әйтергә тулы хокукыбыз бар. Министрлар арасында иң яше кем икән дип уйлыйсызмы – Юстиция министры Рөстәм Заһидуллин. Агымдагы елның 23 июнендә генә әлеге җаваплы вазифага билгеләнгән ул. Рөстәм Илдус улы 1986 елда Казан шәһәрендә туган. 31 яшьлек министр КДУның юридик факультетын тәмамлаган.

Министрларның урынбасарлары арасында да яшьләр шактый. Бөтенесе турында да санап чыксак күпкә китә дип, иң яшьләрен ачыкларга булдык. Сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Алмаз Хөсәенов – 1988 елгы. 29 яшьлек урынбасар Балык Бистәсе районының Шумково авылында туган. Мәскәү университетында белем алган, белгечлеге буенча икътисадчы-менеджер. Күзгә ташланган яшь җитәкчеләрнең тагын берсе – төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Айрат Гатиятов (1989 елгы). Ул Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлаган. Министрлыкларга булган сәяхәтне шуның белән тәмамлап торыйк.

Хөкүмәтнең башка тармакларында вәзгыять ничек? Министрлар Кабинеты каршында эшләп килгән ун ведомствоның өчесендә җитәкчеләре республиканың уртача хезмәт яшендәгеләр – болар инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина, ветеринария идарәсенең баш ветеринар табибы Алмаз Хисаметдинов, ЗАГС башлыгы Альбина Шәвәлиева. Комитетларда да яшь җитәкчеләр бар. Сатып алулар буенча комитет җитәкчесе Ольга Редько – 1981, ә менә аның урынбасары Мария Ротарь 1987 елгы булып чыкты. Туризм буенча Сергей Иванов та, тарифлар буенча Марат Зарипов та, архив җитәкчесе Ираида Әюпова да 1971-1976 елгылар.



**Җәмгыятьнең тоткасы булган егет-кызлар торгынлык чорында да үсеп, калкып чыга алган икән. Димәк, яшьләр нинди генә заманалар килсә дә, беркайчан да югалып калмый. Чишмәдәй тибеп чыгалар да, агымсу кебек, үз юлларын таба беләләр...**

### ШӘҺӘР, РАЙОН, АВЫЛ БАШЛЫКЛАРЫ

Республикада кырык өч муниципаль район һәм ике шәһәр округы бар. Аларда да яшьләргә кытлык дип булмый. Ә иң башта озак еллар эшләгән район башлыклары турында берничә сүз. Муниципаль берәмлекләр советының рәсми сайтыннан күренгәнчә, Әтнә районы башлыгы 1950 елгы Габделәхәт Хәкимов иң өлкән җитәкче генә түгел, ә 1990 елдан бирле бер район белән бик озак җитәкчелек итүче дә. Спас районы башлыгы Камил Нугаев (1956 елгы) бу урында 1995 елдан бирле. Аксубай, Алексеевск, Апас, Биектау, Алабуга, Яңа Чишмә, Балык Бистәсе, Тукай районнарының һәм Чаллы шәһәренең җитәкчеләре дә 1950 елларда туучылар. Әгерҗе, Актаныш, Әлки, Арча, Баулы, Балтач, Зәй, Лениногорск, Мамадыш, Менделеев, Минзәлә, Түбән Кама, Саба, Сарман, Тәтеш, Теләче, Чирмешән, Ютазы районнары башлыклары һәм Казан шәһәре мэры 1960 елларда туган. Азнакай, Бөгелмә, Югары Ослан, Чүпрәле, Яшел Үзән, Кайбыч, Кама Тамагы, Лаеш, Мөслим, Нурлат, Питрәч, Чистай районнары башлыклары исә 1970 елларда дөньяга килгәннәр. 1980 елларда туучылар да бар. Кемнәрме? Әлмәт районы һәм шәһәре башлыгы Айрат Хәйруллин (1981 елгы), Кукмараныкы Сергей Димитриев (1982), Буа районына күптән түгел генә билгеләнгән Марат Җаббаров (1983) иң яшь район башлыклары.

Дәүләт хезмәткәрләре саналган авыл җирлеге башлыклары турында яза башласаң, яшь җитәкчеләр сафын тагын дәвам итәргә булыр иде. Муниципаль берәмлекләр советында 40 яшькәчә җитәкчеләр бу постта шактый. (Араларында 25 яшьлекләр дә бар.) Нәтиҗә чыгарыр өчен саннарга тукталу да җитәр. Муниципаль берәмлекләре башлыкларын (район һәм авыл советы җитәкчеләре) яшь буенча чагыштырып караганда, 50дән узучылар 44,8 процентны тәшкил итә. Ә менә 36-50 яшьлекләр – 44,3, 35 яшькәчә булган җитәкчеләр 10,9 процент.

### АЛМАШКА КЕМНӘР КИЛӘЧӘК?

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр рәсми сайтында республикадагы югары постка җитәкче сыйфатында килергә мөмкинлеге булганнарның исемлеге белән дә таныштык. Әлеге рәсми исемлектә 1969 елда туган ике кешенең генә исемен күрергә була. Иң өлкәннәре шулар, диюем. Калганнары – барысы да яшьләр. 1970-1979 елгылардан ун кешенең исеме язылган. 1980-1989 елгылар – унҗиде. (Бу исемлеккә керүчеләрнең кайберләре инде болай да җитәкче органнарда. Киләчәктә аларның карьера баскычы тагын да югарырак күтәрелергә мөмкин.) Исемлек шуның белән тәмамлана дип уйлыйсызмы? Юк. 1990 елгылар да бар. Әлегә – берәү. 1990 елгы 27 яшьлек егет кадрлар резервына кертелгән. Димәк, яшьләр хакимияттә утырмый, киләчәктә килми, дип әйтә алмыйбыз.

### КӘНӘФИДӘ – ТҮРӘ БАЛАЛАРЫ

Күпләр кәнәфидә түрә балалары гына утыра ала, дип уйлый. Дөрестән дә, әтиең дәрәҗәле урында эшләмәсә, үз көчең белән генә югары үрләр яулау авыррак бирелә, анысы. Тик яшь җитәкчеләр арасында да гади гаиләдән чыгучыларны шактый күрергә була. Үзем белгән берничә кешене генә мисал итеп китерергә булдым. Республиканың баш ветеринар табибы Алмаз Хисаметдинов белән бер мәктәптә укыдык. Әти-әнисе гомерләре буе совхозда гади эшче булып эшләде. Алмаз үзе дә мәктәптән соң бер ел авылда төрле эштә эшләде, аннан мал табибына укырга керде. Югары уку йортын тәмамлаганнан соң районга кайтып, хуҗалыкта баш мал табибы булды. Менә шуннан соң аны күреп алып, үстерә башладылар. Мамадыш якларына китеп хуҗалык җитәкчесе итеп билгеләделәр, район хакимиятендә дә эшләде, аннан Казанга алдылар.

Кукмара районы башлыгы Сергей Димитриев та җитәкче баласы түгел. Пчеловод авылында туып үскән егетнең әти-әнисе шулай ук гади кешеләр. Үз районында үсә алды. Зәй районы башкарма комитет җитәкчесе Илнар Хафизов та гади авыл малае, хезмәт юлын радиода журналист булып башлап, түбәннән күтәрелде. Лаеш районы башлыгы Михаил Афанасьев та үз тырышлыгы белән баскычларга менгән кеше. Әти-әниләре – укытучылар. Михаил Павлович үзе дә хезмәт юлын мөгаллимлек эшеннән башлаган. Әлеге исемлекне тагын да дәвам итәргә булыр иде.

Моңарчы 1970 еллардан соң туган җитәкчеләр бөтенләй юк дәрәҗәсендә, алар бик аз, дип уйлап йөри идем. Бу буын белән эшли торган оешмалар булмады, югары урыннарда 50 яшьтән узганнар гына утыра, дигән фикердә булдым. Күңелгә дә аларга алмашка 1985 елдан соң туучылар гына килә, дигән уй кереп утырган иде. Ялгышканмын. Җәмгыятьнең тоткасы булган егет-кызлар торгынлык чорында да үсеп, калкып чыга алган икән. Димәк, яшьләр, нинди генә заманалар килсә дә, беркайчан да югалып калмый. Чишмәдәй тибеп чыгалар да, агымсу кебек, үз юлларын таба беләләр...

Энҗе Басыйрова

# «ТАТАР КЫЗЫНА ӨЙЛӘНҮЕМ – КҮКЛӘРДӘ ЯЗЫЛГАН НИКАХ»



Татарлар белән төрекләрне берләштергән кыйммәтләр бихисап һәм бу рухи, милли тормышта да, тарихта да чагыла. Моның өчен Йосыф Акчура, Садри Максуди кебек татарның күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләренең Төркия үсеше өчен җан атып йөрүләрен генә искә төшерү дә җитәдер. Хәзерге вакытта Татарстанның икътисадына күз салсак та, бездәге читтән кергән инвестицияләрнең шактые солтан иленнән килүен күрербез. Татарларның яшәргә Төркиягә китүе, төрекләрнең, киресенчә, безгә килүе дә һичкемдә гаҗәпләнү хисе уятмый. Чөнки бу ике милләт күптән тугандаш халыкларга әйләнгән инде. Сәхифәбезнең герое да язмышын Казан белән бәйләгән төрек егете – Рәшит Дженк.

1999 ел. Төркиянең Афьонкарахисар шәһәрендә (*бу шәһәр Төркиянең Конья, Искешәһәр, Кютахья, Ушак, Бурдур кебек дәүләт берәмлекләре кисешкән чатта торуы белән кызыклы. Аның киңлекләрендә Эгей һәм Кара диңгезләрнең бассейннары урнашкан. Шулай ук күп урынын акмый торган Акшәһәр тоз күле алып тора, – **авт.***) туып үскән Рәшит Дженк урта мәктәпне тәмамлаганнан соң алга таба укуын дәвам итү өчен чит илгә китү ягын чамалый башлый. Германиядәге туганы үзе янына килергә кыстаса да, Аурупада виза алу авыр, тормыш кыйммәт, укыган өчен дә саллы гына түлисе була,

дип, егет Русиядәге югары уку йортларын барларга керешә. Озак эзләнгәч, Чуашия дәүләт университетында туктала һәм Чабаксар шәһәренә килеп төшә. Белем – бәхет, гыйлемсез дөнья ләхеткә тиң, дип, Рәшит тәрҗемәче булырга, урыс телен өйрәнергә ниятли. Ә тел – ул дәрья, телләр белгән кеше илләр белгән диган сүз. Героем да, биш ел гыйлем ипие кимергәч, татарларның мәркәзе – Казанга юл тота. Уку дәверендә бу якларны шултиклем ярата ул, кире Төркиягә кайтып китү турында уйлап та карамый. «Студент елларында каникулларда Казанга кесә чыгымнары өчен булса да дип, акча юнәтергә килә идек. Бу шәһәрне шул чагында ук яраттым, – дип сөйли Рәшит. – Бирегә күченгәч, бер-бер артлы тәрҗемә эшенә заказлар табылды. Кайда төзелеш, кайда кафе-ресторан өлкәсендә сөйләшүләр алып барганда урысча белмәгән милләттәшләремә партнерлары белән аңлашырга, рәсми кәгазьләр тутырырга, килешүләр төзергә булыша башладым». Мондый эшлекле әңгәмәләр хәтта министрлар дәрәҗәсендә уза. Рәшит элеккеге төзелеш министры Марат Хөснуллин белән очрашуын әле дә тәэсирләнеп бәян итә. Шулай булмыйни, гади эшче гаиләсендә тәрбияләнгән егет чит илгә китеп хөкүмәт даирәсендә сөйләшүләр алып барсын да ничек хис-кичерешләрен яшереп калсын инде. Рәшиткә язмыш әнә шулай кирәкле вакытта һәм тиешле урында элемтәләр урнаштырырга мөмкинлек бирә. Берничә ел тәрҗемәче булып йөргәннән соң җәмәгать туклануы тармагына эшкә күчә, аны бер кафеның җитәкче урынбасары итеп куялар. Бераз тәҗрибә туплагач, тәвәккәлләп, үз кәсебен ача. Кыюлык – адәм баласының канаты, диюләре хак. Рәшитнең дә кыюлыгы һәм тырышлыгы үзенекен ала. «Софра Кебаб» кафесы тиз арада мөселман яшьләре яратып йөри торган урынга әйләнә. «Софра» – табын, «кебаб» утта кыздырылган ит дигәнне аңлата. Кафеның төп ризыкларыннан берсе – учакта кыздырылган ит», – ди танышым.

Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына дигәндәй, танышым булачак хатыны Рәүфәне җәмәгать туклану урыны ачу турында хыялланып йөргәндә очрата. Пермь ягыннан Казанга укырга килгән татар кызы кафега эшкә урнаша. Ике арадагы дуслыктан бик тиз кайнар мәхәббәт бөреләнә. Өйләнгәч, кайвакыт Рәшитнең күңелен бимазалаган, бәлки канкардәшләрем янына кайтып китәргәдер, дигән шикле уй тәмам эреп югала. Төрек егетләренең Русия кызларын үз итүләре, аларга өйләнергә теләүләре сер түгел. Рәшит үзенең мисалында моны очраклы хәл, күкләрдә язылган никах, ди. Ни өчен милләттәш ир-егетләренең безнең кызларны ошатуын исә аңлатып бирә алмады. Әйе, күңеленә мәхәббәт кошы кунса, акыл йөрәккә буйсынудан туктый шул. Шуңа да, танышым әйтмешли, иң мөһиме – никахлар гомерле булсын, дип юрыйсы гына кала.

Рәшит һәм Рәүфә Дженк гаиләсендә алма кебек ике кызлары – Гөлсем белән Гөлшат үсеп килә. Татарча да матур яңгырасын, төрекчәгә дә аваздаш булсын дип, сабыйларга исемне бергә сайлаганнар. Кызларның олысы быел беренче сентябрьдә Казанның Ф. Аитова исемендәге уникенче кызлар гимназиясенә укырга барырга әзерләнә. «Балалар монда тугач, аларның тамырлары биредә, дип әйтергә хакыбыз бар, – дип дәвам итә танышым. – Үзебезне дә Татарстан кешесенә әйләндек, дип саныйм. Ияләштек, җайлаштык, күп кенә авырлыклар, тулай торактагы кечкенә генә бүлмәгә сыенган, аннары фатир яллап торган авыр чаклар артта калды. Ипотекага алынган булса да, үз оябыз бар һәм шуңа куанып көн күрәбез. Баштагы мәлдә телне камил белмәү, дуслар юклык, кем белән киңәшергә икән дип аптырап йөрү уңайсызлык тудыра иде. Бүгенге көндә танышлар арткannан-арта. Биредәге төрекләр белән генә түгел, ә татар, урыслар арасында да дусларыбыз күп. Татарстанның халык артисты, җырчы Искәндәр Биктаһировлар гаиләсе белән гел күрешеп торабыз, улы Сәйдәш, төрекчә әйтсәк, аркадашым. Янәшәңдә шундый ачык, киң күңелле затлар барда, үзеңне ничек ялгыз хис итәсең?»

Берничә ел элек Төркия чигендә безнең ил хәрби очкычы бәреп төшерелгәч, ике мәмләкәт арасындагы мөнәсәбәтләр шактый киеренкеләнде. Шул мизгелләрдә дә Рәшит авырлык сизмәвен, туган ягына күчену теләге тумавын әйтә.

Әйе, агач кайсы якка кыек булса, шул якка авар. Адәм баласы да нәкъ шулай: зәгыйфь ягы аны упкынга илтә. Моңа юл куймас өчен шул җитешсезлекне вакытында күреп алып төзәтергә кирәк. Бу уңайдан Рәшитнең «тузмас киеме» – акылы, «корымый торган коесы» – гыйлеме бар. Өстәвенә, төрекләр белән татарларның тел охшаш, дин бер, бәйрәмнәр уртак. Танышымның иң яраткан бәйрәме – ураза гаете. Көне буе ашамый-эчми торганнан соң авыз ачарга ифтарга җыелгач, анда кичергән ләззәтне, ризыкның тәмен сүз белән аңлатып бирә алмый. «Бөтен арыганнар юылып төшә, кәеф күтәрелә. Бала чактан ук ураза тотам һәм тәмен елдан-ел

ныграк тоям», – дип тәэсирләнеп сөйли ул рамазан ае турында.

Гаиләдә өч телдә аралашлар. Татарстанда яшәгәч, хәләл җефете татар милләтеннән булгач, күбрәк татарчага өстенлек бирәләр. «Безнең телләр охшаш бит, шуңа да татарчага өйрәнү җиңел булды. Хатынымның туган ягына авылга кайткач татарча сөйләшергә туры килә. Ә сала, андагы рәхәтлек турында сәгатьләр буе гапләшергә әзермен. Анда бит йокы да татлырак. Авылның токмачлы ашы, өчпочмак, төрледән-төрле пирог – һәммәсе телне йотарлык. О, ул мең сихәт бирә торган мунча! Ә саф сулы чишмә! Җир астыннан чип-чиста, саф су бәреп чыксын да, ничек хәйран калмыйсың?! Төркиянең мин үскән төбәгендә андый сулыклар бөтенләй юк. Чишмәләрне беренче мәртәбә монда күрдем».

Эш мәшәкате белән авылга сирәк, елга бер мәртәбә генә кайталар икән. Төркиягә дә шулай. Тик ике атналык сәяхәт вакытында диңгездә ял итәргә дә өлгерәләр. «Туганнар яныннан тагын бер ел читтә яшәргә җитәрлек көч-куәт җыеп киләбез», – ди Рәшит. Биредә инде, билгеле, күп вакыты эштә уза. Шулай да, җаен табып, балалары белән еш кына Кол Шәриф мәчетенә, зоопаркка баралар, Камал театры спектакльләрен яратып карыйлар, андагы кайбер артистлар белән якыннан аралашалар. Ә менә туганнарының Казанны әлегәчә күргәннәре юк, Татарстанга килергә хыялланалар гына. Кардәшләре татар кызына өйләнгәч, безнең мәдәнияткә кызыксынулары арткан. Рәүфәне исә беренче күрүдә үк үз иткәннәр. Әти-әнисе, өч бертуганы гына түгел, башка кардәшләре дә «кызның асылын эләктергәнсең» дип, Рәшиткә мактау сүзләре ирештергән. «Мин – нәселебездә башка милләт кызына өйләнгән бердәнбер кеше. Ике ир туганым да төрек кызларына өйләнде, апа да үз милләтебез кешесендә кияүдә», – дип елмая бәхетле ир.

Төрек танышым иҗади җанлы кеше дә булып чыкты әле. Шигырьләре студент чагында, чуаш теленә тәрҗемә ителеп, журналда басылган хәтта. Хәзер инде дөнья матавыгы белән иҗат онытылды дип авыр суласа да, хәләл ризык тәкъдим итүләре белән мөселман халкының ышанычын яулый алуларына эчкерсез шатлана. Эшкуарның максаты акча эшләү булырга тиеш түгел, ди басым ясап. «Малтабарлык бит табыш китерү чарасы гына түгел, ә иҗат кебек күңелгә рәхәтлек алу чыганагы да, – ди Рәшит. – Безнең туклану урыннарына кергән кунаклар канәгать калсын, сөенеп китсен дип тырышам. Ә акча, табыш – үзе килә». Шундый ният белән яшәгәнгәдер, Рәшит Диния нәзарәте уздырган хәйрия чараларында теләп катнаша: ураза аенда «Зәкят» фонды белән берлектә ифтар мәҗлесләре үткәрсәләр, айга бер мәртәбә һәр җомга шәһәрнең «Колхоз базары» янында мескен-мохтаҗларга ризык тараталар. Еш кына ятим балаларны кафеларына чакырып кунак итәләр. Яхшылык җирдә ятмый, диләр. Төрек егетенең дә Татарстанда кылган игелекләре эзсез калмас, дип ышанабыз.



Авылда кунакта



Рифә Рахман

# АУРУПАГА ЯҢА ЗАМАНДА СӘЯХӘТ

*Ахыры. Башы журналыбызның апрель, май саннарында*

Элекке илебез СССР чигендәге республикалар белән чиктәш Румынияне күрү теләгем бик күптән – чегәннәр хакында кинолар карагач, Вакулага бәйле куркыныч хикәятләр тыңлагач барлыкка килгән иде. Җитмәсә, кайбер фильмнар Брашов шәһәре янындагы Дракула замогы янында да төшерелгәч, бу теләк Маҗарстанга барган саен уянып-уянып куйды. Ниһаять, ул минем чынга ашты. Инде бу юлы самолетта аның башкаласы Бухарестка очтык.

Түбән Дунай бассейнында җәелеп яткан, Көнчыгышын Кара диңгез юган һәм халкы Румыния буйлап сәяхәт итү теләгем аның тулаем яисә әле бу, әле теге өлкәләренең 300 ел дәвамында Госманлы империясенә керүе белән дә бәйледер, чөнки, кайсы гына җирне басып алсалар да, төрекләр берсеннән-берсе гүзәл архитектур корылмалар, дәвалану урыннары төзегән, җирле халык кыяфәтендә үз чалымнарын калдырган. 1877 елда башка илләрдән тулысынча мөстәкыйльлек алган Румыниядә дә бу сизелә. Шул ук вакытта монда төрекләрнең үзләренә дә тәэсире зур Византия стиле хакимлек итә. Ә менә элек Австро-Венгрия составына кергән, Беренче Бөтендөнья сугышыннан соң Румыниягә кушылган Трансильвания башка өлкәләрдән үз йөзе, халкы, яшәү рәвеше белән нык аерылып тора. Анда әле һаман да алманнар, мажарлар бер тирәгә урнашып көн итә, ә архитектурасы готикага карый.

Румыннарны, молдаваннарны күпләр чегәннәр дип саный, бу – тамырдан хата фикер. Шул ук вакытта беренчеләренең яшәү рәвешенә чегән тәэсире биниһая зур. Румыннарга XI-XIII йөзләрдә килеп кушылган карасу-тут йөзле кыпчаклар-команнар шулай ук тышкы кыяфәтләре белән бик охшаш бит. Карпат тауларына якын җирләрдә яшәгән кыпчаклар 1227 елда католик динен кабул иткән, Маҗарстанга буйсынган һәм 1241 елгача сакланган католик епископлыгы төзегән. Дөрес, алар соңрак таралган, төрле халыклар тарафыннан ассимиляцияләнгән, әмма шушы регионда дәүләтләр төзүдә актив катнашкан. Вирҗил Чокылтан исемле ориенталист язуынча, Валах патшалары Брашов сәүдәгәрләренә бүләк иткән атаклы Бран крепосте тирәсендә элек төркиләр яшәгән.

Атаклы «Дракула» киносында илнең төркиләргә бәйле тарихы шактый ямьсезләндерелеп, күпмедер бозылып бирелсә дә, нәкъ менә әлеге фильм бу якларны күрәсе килү теләген тагын да көчәйтә. Әгәр кинодан этәрелеп китеп, Румыния тарихын өйрәнә башласаң, катлаулы сәхифәләренә кереп китсәң, кире чыга алмыйсың. Ул шулкадәр буталчык ки, аның хакында еш кына галимнәр бер-берсенә үтә каршылыклы яза. Инде халыкны калыплаштырган кавемнәрнең тәмам румынлашуы, күпчелек очракта христианлаштырылуы аркасында, ата-бабалары әлеге кавемнәргә нисбәтле галимнәр дә ил елъязмасын румыннар күзлегеннән, алар теләгәнчә иҗат итәргә тырыша. Румыния тарихын урыс елъязмачылары да, сәясәткә бирелеп, субъектив тасвирлый дип уйлыйм. Шул ук вакытта алар бу илдә бигрәк тә төрекләр калдырган елларны әйләнеп уза алмый, чөнки Тереквар (төрек бар, урыслар төрек каласы дип тәрҗемә итә), Коман, Каракал кебек төрле урынчылык атамалары һәм борынгы фамилияләр, ризык исемнәре (чорба – шурба, шулпа) Румыния белән ерактан ук килгән

мәдәни-тарихи бәйләнешләребез хакында сөйли.

Румыния гүзәл таулары белән сокландыра, син, инде дуга булып ил үзәген кискән Карпат, аның елгалы үзәннәре өстеннән очып узганда ук, кышкы аклыкка төренгән биек һәм үткер тау башларына сокланасың, шунда урнашкан күпсанлы туристик базаларга ял итәргә барасың килә. Июньнән алып сентябрь азагынача эсселек хакимлек иткән, елгалары җылы торган һәм бәяләр бик очсыз Румыниянең ял итү урыннарыннан туристлар һичбер вакыт өзелми. Алар шул тирәләрдә яшәгән, кырлар тоткан, йөзем үстергән һәм бик авырлык белән көн иткән гади җир кешесенә дә, таулар арасында йорт кына тотканнарга бигрәк тә төп яшәү чыганагы булып тора. Тирә-як Аурупа илләрендә яшәүчеләр генә түгел, румыннар, молдаваннар, чегәннәр дә хәтта кышта ялларын тау чаңгы юлларында уздырырга ярата. Таңнарда, электричкаларны тутырып, халык Карпатка агыла.

Румыния безгә Маҗарстан, Болгария кебек шактый җылы кышлы ил булып тоела, асылда алай түгел. Без барып төшкәндә, Бухарест Казанныкына караганда да биегрәк кар өемнәре эчендә утыра иде. Җитмәсә, көн җылынып китеп, бөтенләй чистартылмаган урамнарда тездән суда йөрергә, аяк киемнәрен алмаштырырга ук туры килде. Самолеттан чыккач туган тәүге тәэсирләр уңай булды дип әйтмәс идем. Беренчедән, Русиядән икәнлегемне күреп, мине генә аэропортта озаклап тикшерделәр, кат-кат бармак эзләрен карадылар, фотомны йөзем белән чагыштырдылар. Венгриядә безнең белән бер йортта торган африкалы ханым да, чит илдә яшәү хокукы булган балаларым да тикшерү пунктын беренчи проблемасыз узды да китте.

Инде ташландык җир асты юлына төшкәч, акшарлары кубарылган, буяулары коелган, сүз язарлык урын калмаган, шакшы, чүпле поезд вагоннарыннан исәрләнеп тордым. Ул безне шундый ук караусыз урамнарның берсенә илтте. Интернеттан яшәр өчен, акча да кысмыйча, өр-яңа фатир сайлаган идек. Хуҗасы молдаванка булып чыкты. Бухарестта Молдавиядән күченгәннәр күп. Кайбер молдаваннар акчаны, хезмәт хакына яшәү авыр, үз илләрендә туплыйлар да, моннан йорт алып, фатир тотучыга әйләнәләр, балаларын румын мәктәпләрендә укыталар, икенче гражданлыкка ия булалар. Монда туплаган зуррак хезмәт хакына Молдавиядә көн итүчеләр дә бар, имеш. Кыскасы, хуҗабикә уңышлы яллар теләп чыгып киткәч, шул беленде: кухнядагы батареялар өзелгән, башка бүлмәләрдәгеләрнең җылысы арттырылмаслык итеп кысылган. Аурупаның хәтта үтә байлары да җылылык һәм су тотуда кысмыр диюләре хактыр, югыйсә бездән кергән табышка бүлмәләрне тиешенчә җылытырга була.

Бухарест турында тәнкыйдирәк күзлектән сөйләсәм дә, тарихи җирләре гаять гүзәлдер. Без ял иткән көннәрдә башкала үзәгенең кешесезлеге, азсанлы музейларының бушкалыгы аеруча сөендерде. Шул ук вакытта төп урамнар, хәтта министрлыклар, хакимияткә кагылышлы башка биналар да карга батып утыра иде. Төштән соң бер нәрсә гаҗәпләндерде: тар урамнарны тәмам тыгылдырган карны кечкенә сөздерткеч техника һәм кул белән көрәп, зур машиналарга төягәннән соң, үзәк мәйданга өяләр икән. Бу да илдәге икътисади хәлнең начарлыгы белән аңлатыла торгандыр. Андагы тормышның ниндилеген күргән молдаваннар соңгы вакытта тугандаш халык белән кушылу фикереннән кайтты шикелле.

Яшәгән фатирыбыздан, урамнарның каралмавыннан канәгатьсез булсак та, ризык очсызлыгы, кафе-рестораннарда гына да ашап тора алу мөмкинлеге безне сөендерде. Җитмәсә, ялыбызның икенче көнендә шәһәрара электричкада Брашовка баргандагы күргән манзараларыбыз да вагоннар салкынлыгына чыдарга мәҗбүр итте. Ә ул безне бу ярлы илнең бик бай чегәннәре яшәгән, төрле кальгаларга, Аллаһ йортларына бай төбәгенә илтте. Кызганыч ки, кабат шул ук шакшы һәм кафелары совет заманындагыча калган, рәтсез ризыклы вокзал, әйбереңне чәлергә торган чегәннәр, атаманнарга ияреп йөргән караучысыз, йорт-җирсез, кайберләре наркоман да булган балалар каршы алды. Бер чегән хатыны, оныгыма кызыгып, әйләнде дә килде, әйләнде дә килде, ни өчендер аны үзе белән ияртергә маташты, төрле әйберләр белән кызыктырды, урысчалап сөйләшергә тырышты.

Румыниянең үзәгенә урнашкан Брашов дөньяга готик кварталлары, Кара чиркәве, Екатерина капкасы, Пояна Брашов тау курорты белән билгеле. Анда йөрү чагыштырмача очсыз. Башка шәһәрләрдәге кебек үк, көнлек, атналык, айлык юл билетлары алырга һәм транспортка теләгән санда утырырга мөмкин. Таксилар саны да бихисап, әмма алдан белешеп куймасаң, таксистлар бәяне әллә ничә мәртәбә арттыра, берәрсе төшерсә, янына килеп талаша ук башлыйлар.

Румыниядә ярты миллионнан артык чегән яши һәм, румыннардан, маҗарлардан кала, өченче урынны алып тора. Алар монда III-XIV гасырлардан бирле көн итә дип санала, шунлыктан этник румыннар белән бик нык якынайганнар, уртак гаиләләр дә төзегәннәр. Бу якынаюга аларның дин уртаклыгы да, рухи якынлыгы да булыша торгандыр.

Шул ук вакытта румыннар чегән тәэсиренә каршы торырга бик тырыша, аларның яшәү рәвешен кабул итә алмый шикелле. Чегәннәр шулай ук, бароннары җитәкчелегендә үзләренчә яшәргә омтылсалар да, хәтта чегәнчә дәреслекләрдә белем алсалар да, бүгенге көндә көчле румынлашуга биреша башлаган. Инде аларның 72 проценты гына ана телендә сөйләшә, маҗарча аралашканнары, башка милләтләр белән кушылып киткәннәре дә юк түгел.

Үзе дә асылда хәерче, нефте көннән-көн кими барган, зур табыш китермәгән Румыниядә көн иткән чегәннәрнең күпчелеге ярлыдан-ярлы. Алар бер бүлмәле фатирларда дистәшәр кеше көн итәргә мөмкин. Шул ук вакытта илнең иң байлары да – чегәннәрдер. Бу халыктан чыккан миллионерларның башкаладан сиксән чакрым ераклыкта үз шәһәрчекләре бар. Анда төзелгән сарайларның йөз миллион доллар торганнары да юк түгел, диләр.

Бай кварталларны яисә чегән бароннары йортларын кайчандыр ун ел дәвамында Сталин исеме белән дә аталган Брашовта да очратырга мөмкин, әмма туристларны аны алманнарның шәһәрләренә тиңләп чакырганнарына ышанырга ярамый – гаять тә рәтсез каладыр, ярый әле карарлык тарихи ядкярләре, синагогалары, костеллары, чиркәүләре, милли киемнәрдә дә очраган халкы бар.

Дракула замогы Румыниянең визит карточкасы исәпләнә. Безне аңа алып баручы турист моңа канәгатьсезлеген белдерде. Илебездә башка замоклар да күп, бигрәк тә Русиядән килгәннәр Бранны күрергә тырыша, диде. Икенче исеме төбәк атамасы белән тәңгәл әлеге корылма XIV гасыр ахырында халыктан җыелган акчага төзелгән, XVII гасырда берникадәр үзгәреш кичергән. Әйтүләренә караганда, тау башына урнашкан замок ишегалдындагы кое су алу өчен түгел, ә эчке яшерен юлларга илтә. Аның беренче хуҗасы Карт Мирчеда оныгы – Влад Цепеш исемле гаскәр башлыгы анда кунак булырга яраткан һәм, аның хакындагы кинодан да күренгәнчә, имеш, аны бу бинада төрекләр җәзалаган. Хәзер исә халык бу замокның хуҗасы баштан ук ул булган дип саный һәм корылмага бәйле төрле легендаларын аның исеме белән бәйли. Икенче фараз буенча, атаклы вампир каберен эзләп килгән туристлар шушы замокны күрәләр дә аңа Дракула исемен бирәләр. Борынгы заман техникасы һәм җиһазлары белән җиһазландырылган унҗиде бүлмәле замокның бәһасе бүгенге көндә кимендә йөз кырык миллион доллар тора.

Замокка күтәрелү юлында сатылган сувенирлар, рәсемнәр, фотога төшәргә дәшүче кан эчүче персонажлар анда Дракула яшәү, ул уздырган коточкыч та, серле дә, мәхәббәтле дә төннәр турында сөйли. Легенда гына дип карасак та, хәтта аны белмәгән кечкенә оныгым да замок эчендә шулкадәр тәэсирләнде ки, озак тормыйк, куркыныч, дип елый ук башлады, монда Дракулалар яши, дигән фикерне кат-кат әйтте. Чынлыкта да, Брем Стокерның «Дракула» романына (1897) прототип булган «граф Влад» үзенең кансызлыгы, катылыгы белән дан алган бит. Ул – чынбарлыкта Валахия белән идарә иткән кенәздер. Тышкы кыяфәте чибәр, кансызга охшамаган дип язсалар да, сакланып калган портретында миңа андый күренмәде, куркыныч тоелды, ә минә хатыны – гүзәлләрнең дә гүзәле инде.

Влад Цепешның кансызлыгы турында легендаларны төбәк кануннарын үтәмәгән өчен җәза алган саксон боярлары чыгарган, диләр. Алар уенча, кенәз хәтта сабыйларны рәнҗеткән, тоткыннарны үтергән, үз замогында төннәр буена мәетле бүлмәләрдә сыйланган. Браннан тыш, Сигишоара исемле уртагасыр шәһәрчегендә ул туган йорт та саклана, аның исемен йөрткән урам бар һәм бөтендөнья канэчәрләре ел да шушы калада җыен уздыра. Кенәзгә Дракула кушаматы әтисе Влад Икенчедән күчкән – ул Венгрия короле 1408 елда төзегән Драконнар орденына кергән һәм үз биләмәсендә дракон рәсемле акчалар һәм тугра ясаткан. Казыкка утыртучы мәгънәсен аңлаткан Цепеш атын аңа төрекләр биргән дип язалар. Тарихчылар Дракула Бран замогында бервакытта да яшәмәгән дип санаса да, борынгы заманнардан калган җиһазларны караганнан соң, кенәз киемнәрен күргәч, трофейлы, куркытулы бүлмәләргә, җәза урыннарына, сәяхәт кылгач, туристлар башка фикергә килә дип уйлыйм. Үзем дә замоктан бик көчле һәм төрле тәэсирләр белән чыктым.

Безнең туристлар Бранга тартылса да, гидлар чынлыкта да Влад нәселе төзегән Поенари крепостен карарга тәкъдим итә. XIII гасыр башында торгызыла башлаган корылма салынып беткәнче, ике йөз вельможа казыкка утыртылган, таудан егылып яисә эсселеккә чыдамыйча үлгән, күпсанлы коллар төзелештә һәлак булган. Влад Дракула исә төзелештә коллар урынына морзаларны файдаланган. Поенари кальгасына менеп җитү өчен, 1500 баскыч узарга кирәк, ә ул исә казыкка утыртылган маникеннар эченнән бара... Тарихтан Влад Өченче Цепешның Снагов монастыренда үлүе һәм күмелүе билгеле, әмма каберен ачып карагач, мәете табылмаган. Шуннан соң, җирдәге гөнаһлары юылсын дип, монахларның кенәз җәсәден чиркәүгә керү юлындагы плитә астына күчерүләре ачыклана.

Румыния хакында да айлар дәвамында сөйләргә була. Уфтанып кына, шушы урында өзик. ■

Мәрьям Насыйрова

# Нефтьне өчпочмакка алмаштыру нәрсәгә китерә?



Соңгы елларда кулланучыга татар милли киемнәрен, бизәкләрен, ашларын яңа, заманча форматта тәкъдим итү популярлашты. Беренче милли, хәләл фаст-фуд челтәрен ачучыларның берсе – яшь эшкуар Солтан Сафин, «Түбәтәй» проекты киләчәктә фаст-фуд юнәлешендә эшли торган эре оешмаларга көндәш була алыр, дип өметләнә.

**«КЕЧКЕНӘ ВАТАНЫМ ИДЕ»**

Мәктәп һәм студент елларында Майкл Джексон биюләре белән мавыккан, соңыннан Согуд Гарәбстанындагы иң эре нефть оешмаларының берсендә эшләгән татар егетенең милли ризыкларны фаст-фуд форматында дөньяга танытырга теләве игътибарга лаек, әлбәттә. «Балачакта андый хыялым юк иде. Абыйларым геолог-нефтьче булырга юл күрсәтте. Әти-әнием мәдәният йортында эшләде. Әби-бабайларым – укытучы һәм аш-су осталары иде», – ди Солтан, тәгам өлкәсенә очраклы килеп керүен ассызыклап.

Ул үзе тумышы белән Самара өлкәсеннән. Туган авылы Камышлыны, Самараның кечкенә генә Татарстаны, дип атый ул. «Әти-әнием мәдәният өлкәсендә эшләгәнгә, иҗади мохиттә тәрбияләндем. Балачакта иң яраткан уенчыкларым микрофон белән музыка уен кораллары иде. Мәктәптә укыганда Майкл Джексон биюләре белән мавыга башладым. Унберенче сыйныфны тәмамлаганда, чыгарылыш кичәсендә тулысы белән аның биюен кабатладым», – дип искә ала ул.

Казанга укырга керү теләге 2006 елда «Изге Болгар серләре» дип аталган лагерьда барлыкка килә. Чит төбәкләрдәге татар яшьләрен, башкаланы күрсәтергә дип, ике көнгә Казанга чакыралар. Казан дәүләт университетында булганнан соң, андагы мохитне, төрле илләрдән килгән студентларны күреп, һичшиксез, шунда белем алырга ниятли Солтан. Әти-әнисе Самарада калырга өндәсә дә, университетка геология юнәлешенә укырга керә.

Бер урында гына утырып тора алмаган, кызыксынучан егет уку белән генә чикләнми, билгеле. «Казанга килгәч, иҗади тормыш белән яши башладым. Студент еллары вакыйгаларга бай булды: баштанаяк геологиягә чумдым, Себергә барып чыганакларны өйрәнә идек. Фитнес үзәкләренең берсендә бию дәресләре алып бардым, бер төркемдә үзем дә биедем. Тормышта үз юнәлешемне таптым, дип уйлаган идем. Ләкин бер вакыйгадан соң бөтен нәрсә тамырдан үзгәрде».



### ӘКИЯТИ ТОРМЫШТА

– Укыган вакытта Кытайда практика үтү турында белештем һәм икенче елны Америка-Кытай нефть оешмасына стажировкага киттем. Шунда бер Кытай егете белән дуслаштым, ул миңа Согуд Гарәбстанындагы KAUST институты турында сөйләде. «Бу уку йортында Нобель премиясе лауреатлары үзләре белем бирә. Институт Кызыл диңгез яр буенда урнашкан. Монда уку һәм фән белән шөгыльләнү өчен дөньяның сиксән биш иленнән иң яхшы студентлар килә», янәсе. Күңелемдә шушы диңгез буенда урнашкан уку йортына бару теләге туды.

Соңгы курста Халыкара нефть оешмасына геофизик вазифасына һәм шул ук вакытта KAUST институтына да гариза юлладым. Эшкә чакыруны тиз җибәрделәр, инде чемоданнарны тутырып, очарга әзерләнеп йөргәндә генә электрон почтага KAUSTтан магистратурага чакыру кәгазе килде. Үз күзләремә үзем ышанмадым, ике атна буе икеләнеп йөрдем. Ахыр чиктә уку йортын сайладым.

Русия вузларын бетерүчеләргә анда керү кыен түгел. Мин, гариза язып, документларны җибәрдем, әңгәмә үттем, тест, резюме яздым. Укучыларның яшәү, ашау өчен кирәк булган бөтен чыгымнарын уку йорты үзе каплый һәм шактый күләмдә стипендия дә түли булып чыкты.

Ел ярым әкияти тормыш белән яшәдем. Минем фәнни җитәкчеләрем планетаны модельләштерү белән шөгыльләнүче галимнәр Нобель премиясе иярләре иде. Алар белән аралашканда синең дөньяга карашың көнләп, сәгатьләп түгел, ә минутлап үсеш-үзгәреш кичерә, – дип искә ала Солтан ул чордагы гаҗәеп кичерешләрен.

Уку тәгәлләнеп килгәндә, Согуд Гарәбстаны короле институтында яшь белгечләр өчен вакансия ярминкәсе оештырыла. «Аллаһ Тәгаләгә шөкер, миңа тагын бәхет елмайды. Бөтен нефтьчеләрнең хыялы булган «Saudi Aramco» оешмасына әңгәмәгә чакырдылар. Икенче тапкырдан эшкә алындым».

### ЗУР ПРОЕКТЛАР ӨЧЕН ЗУР КОРБАННАР КИРӘК

«Монда эшләгәндә күңелемдә студент елларыннан калган хыял йөрде. Ни өчен соң Татарстанның үз милли ризыклары белән тиз ашау системасы юк? – үз-үземә әнә шул сорауны еш бирә идем. Бер юлы, дустым Айнур Камалиев белән фитнестан кайтканда, шул турыда сөйләшеп киттек һәм бу юнәлештә үзебез эш башларга ниятләдек. Сәяхәтләр вакытында ниндидер тәҗрибә дә тупладым. KAUSTта укыганда безне фәнни яктан гына үстереп калмыйча, бизнес өчен файдалы булган белем дә бирделәр».


Ел ярым Согуд Гарәбстанында эшләгәннән соң, 2015 елда Солтан Казанга кайта. «Зур проектларны тормышка ашыру өчен, һәрвакыт зур корбаннар кирәк, – ди ул. – Билгеле, әти-әнием башта бераз куркып калды. Бу эштән нәрсә килеп чыгасы билгеле түгел бит. Шулай да: «Син нәрсә сайласаң, без шуңа риза булырбыз», – диделәр.

27 яшендә үзен төрле юнәлешләрдә сынап караган Солтан: «Без әзер булгач, һәрбер нәрсә үз вакыты белән килә, – ди. – Шуңа тормышымда ниндидер кискен үзгәрешләр булды, дип әйтә алмыйм. Хәзергә безнең максат – хәләл таләпләренә туры килгән татар милли ризыкларын Татарстанның бренды дәрәҗәсенә күтәреп, кулланучыга тәкъдим итү. Бу юнәлештә планнар шактый, әле эшлисе дә эшлисе. Аннан соң нәрсә язганын күз күрер».

Кыска вакыт эчендә уңышка ирешүнең серен Солтан Сафин гади генә, Хөсни Кәрим сүзләре белән аңлата: «Халык өчен эшләгән эшләр үзең өчен дә файдалы».



**«Фәнни җитәкчеләрем Нобель премиясе иярләре иде. Алар белән аралашканда синең дөньяга карашың көнләп, сәгатьләп түгел, ә минутлап үсеш-үзгәреш кичерә».**





## ҮЗ ЭШЕҢНЕ БАШЛАГАНДА НИНДИ ХАТАЛАРНЫ КАБАТЛАМАСКА? ЯШЬ ЭШКУАРЛАР ӨЧЕН СОЛТАН САФИННАН ҖИДЕ КИҢӘШ.

**1 «Идея бар, ничек эшләргә кирәклеге аңлашыла, башлагач, күз күрер!»**

Күпләр эш башлаганда нәкъ менә шулай фикер йөртә. Ә бизнес уңышлы булсын өчен барысын да алдан уйлап эш итәргә кирәк. Керем һәм чыгымнарны исәпләү, бизнес моделен төзү, команданың эшләү рәвешен, кемнең нәрсә өчен җавап бирәчәген алдан ук күзаллау мөһим!

**2 Әлеге проекттан сез нәрсә өмет итәсез?**

Еш кына без ниндидер эшкә кызык тоелганга, яисә дустыбыз чакырганга тотынабыз. Әлеге проектның сезнең тормыш өчен әһәмияте нинди соң? Бу эш үзегез куйган максатларга ирешергә ярдәм итәрме? Шул хакта уйланыгыз!

**3 Дусларыгыз белән эш башлыйсыз икән, максатыгыз бер булырга тиеш.**

Бер иптәшегез бер төрле максат куйса, икенчесе икенче төрлене, эшегез Крылов мәсәлендәге аккош, кысла һәм чуртанны хәтерләтәчәк. Максат бер булырга тиеш!

**4 «Дусларымны әйбәт беләм, күптән аралашабыз. Барысы да яхшы булачак!»**

Яхшы дус – яхшы хезмәттәш дигәнне аңлатмый. Дустыгызның компетентлыгы башкарачак эшенә туры килергә тиеш. Билгеле, бер-берегезгә ышану, үзара аңлашу, дуслык бар. Ләкин дустыгыз үзенә йөкләнгән эшне башкарып чыга алмаса, шактый гына уңайсыз хәлгә калуыгыз ихтимал!

**5 Дустыгызның шәхси, психологик үзенчәлекләре бергә эшләү өчен туры киләме?**

Командада, мәсәлән, әйдәп баручы лидер, яңа фикерләр, идеяләр авторы, финанс яктан тәэмин итүче яки реклама өчен җавап бирүче була. Эшнең башында торучылар бер-берсен илһамландырып, тулыландырып торырга тиешләр. Командадагы мохит тә, эшнең нәтиҗәсе дә шуңа бәйле.

**6 Партнерлар арасында бурычлар һәм вазифалар дөрес бүленгәнме?**

Бу мәсьәләләр хакында алдан ук ачыктан-ачык сөйләшү кирәк. Йөкләнгән вазифа белән мөмкинлекләр туры килергә тиеш. Уртак бизнес ачканда һәрберегезнең бу эшкә керү, чыгу шартларын да алдан ук хәл итегез.

**7 «Әйдәгез, баштан ук бөтен нәрсәне эшлик! Аннан соң булырга мөмкин».**

Эшне яңа гына башлап җибәргәндә, бөтен нәрсәгә бер юлы барып ябышырга ашыкмагыз. Үсеш адымнарын, әһәмиятеннән чыгып, бер-бер артлы төзегез.




Ләбиб Лерон




# Абитуриент көндәлеге-2

*(1979 ел, август)*


**Түземсезләнеп һәм шөбһәләнеп көткән имтихан көне килеп җитте. Календарьда – 1979 ел, 2 август. Көндезге сәгать икедә тәүге имтихан башланырга тиеш.**



*Газинур Газетдинов*



*Илдус Шаһиев*



*Фаил Шәфигуллин*

«...Актлар залына кереп утырдым. Өстәлләргә кәгазьләр куелган. Бер абый *(хәзер уйлыйм: бүгенге көндә күренекле галим Марсель ага Бакиров булмадымы икән ул?! – **Л.Л.**)* кулындагы зур конвертны ачып, имтихан темаларын укый башлады: «Габделҗаббар Кандалый иҗатында хатын-кыз образы», «Галиәсгар Камал иҗатында типлар» һәм ирекле тема – «Минем замандашым».

Икенче темага тукталасы иттем. Каралама хәлендәге язмамны акка күчерергә җыенган бер мәлдә, теге абый белән бер апа аллы-артлы яныма килеп, язганнарымны караштырып китте. Имтихан алучы апа хәтта бер хатамны («ошый» диясе урынга «охшый» дип язганмын) күрсәтеп үтте.

15:15кә барыбыз да иншаларыбызны тәмам иткән идек инде. Нәтиҗә ничек булыр? Хет «дүртле» булсын иде инде, дим...»

Шул көнне имтиханнан соң фатирга таба кайтышлый Югары Яхшый мәктәбендә бергә укыган сыйныфташым Фирдәвис Имамовны очратуым, аның авыл хуҗалыгы институтына керү имтиханын кичә тапшыруы һәм алдагысы алтынчы августта буласы турында көндәлеккә теркәп куйганмын икән...

«**3 август.** Кичке алтыда университетның (икенче корпус) 109 аудиториясендә консультация булды. Аны бер апа белән бер абый алып барды. Имтиханда билет алып җавап бирәсе икән. Бер билетта өч сорау ди: берсе – әдәбиятка, икесе татар теленә кагылышлы.

Беренче имтихан нәтиҗәсе билгеле түгел әле. Сиксәннән артык абитуриенттан алтысы иншаны «икеле»гә язган икән, дигән хәбәр ишеттем....»

**«4 август.** Университетта имтиханнан «икеле» алучыларның исемлеген күрдем. Исемлектә минем исем-фамилия юк. Сөендем...»

**«5 август.** Иртәнге җидедә университетка киттем. Имтихан сәгать тугыз тулып киткәч башланды. Имтихан уздырыла торган бүлмәгә (ул бер үк вакытта ике аудиториядә бара) кердем. Ике апа (*шул көнне үк ачыклаган идем: берсе – Флера Әкрәм кызы Ганиева, икенчесе – Алмазия Хаҗи кызы Нуриева булып чыкты. –* ***Л. Л.***) өстәл янында имтихан алып утыра иде.

Менә чират миңа җитте. Беренче сораугa җавапны Флера Әкрәмовнага сөйләдем. Ул мин сөйләгәннәрдән риза булды шикелле. Икенче һәм өченче сорау буенча Алмазия апага җавап тоттым. Менә монда чынлап торып «баттым» инде. Көчкә ерып чыктым. Имтихан кәгазенә «дүртле» билгесе куйдылар, рәхмәт төшкерләре. Миннән алда сөйләгән бер кызга (ул татар теле бүлегенә кермәкче иде): киләсе елда килерсең, дип, «өчле» куеп чыгардылар. Имтиханнан сәгать беренче яртыда чыктым.

**«8 август.** Иртән торгач, кофе эчтем дә университетка киттем. Баруга, Ралиф исемле егеттән *(Ралиф Низаметдинов бүгенге көндә Теләче районы хакимиятендә җаваплы эштә эшли. –* ***Л.Л.****)* урыс теле китабын алып укыдым. Имтихан башланыр алдыннан Фәннур абый Сафин белән күрештек. Имтиханнардан нинди билгеләр алуым белән кызыксынды. «Дүртле»ләр, дидем. Болай булгач, керәсең, диде.

Ркаил Зәйдуллин һәм Ләис Зөлкарнәев белән сөйләшеп тордым. Алар икесе дә татар теле бүлегенә кермәкче.



*Марсель Бакиров*



*Ралиф Низаметдинов*



*Флера Ганиева*

Исәнләштем. Өстәл янына килеп, билет (№50) алдым. Флера Әкрәмовна алдындагы кәгазьгә минем исем-фамилиямне язып куйды. Буш урынга барып утырдым. Билетка карыйм. Өч сорау: «1960-1970 елларда Хәсән Туфан поэзиясе», «Иярчен җөмлә кисәкләре» һәм «Морфологик анализ» (берничә җөмлә бирелгән). Билетка карадым да катып калдым. Х.Туфан иҗаты турында соңгы көннәрдә берни укымаган идем (10 сыйныф өчен әдәбият дәреслегем юк иде). Бар белгәннәремне туплап, кәгазьгә төшердем.

2 августта язган иншам да «дүртле» булган...»

**«7 август.** Университетта сәгать алтыда урыс теле буенча консультация булды. Иртәгә сәгать тугызда имтихан башлана».

Имтихан узарга тиешле 302 аудиториягә (төп бинада) кердем. Өстәл янында ике апа утыра иде. Билет (№39) алдым. Бер бик озын җөмлә әләкте. Шуңа синтаксик, морфологик анализ ясарга кирәк иде. Ишек ягында утырган апага җөмләләргә ана-

**Әгәр имтихан биреп йөргән көннәрдә көндәлек алып бармаган булсам, мин ул чактагы хатирәләрне ничек яңартыр идем икән... Барысын да исемдә саклый алган булыр идемме? Ай-һай...**

лиз ясап күрсәттем. Хаталарымны әйтте. «Үзең турында урысча сөйлә, диде. Сөйләдем. Имтихан кәгазенә «дүртле» куеп чыгарды.

Күпмедер вакыттан соң (ашханәдә капкалап алырга өлгердем), икенче корпусның унынчы катындагы 9 аудиториядә әңгәмә үткәрделәр. Урыс теленнән имтихан алган апаларның берсе (миннән имтихан алганы түгел) мәктәптә укыганда нинди җәмәгать эшләре башкаруым турында сорашты, тарихтан имтиханга ныклап әзерләнергә кушты...»

**«11 август.** Асия җиңгидән (әнием Шәргыяның бертуган энесе Рөстәм абый хатыны) хат килде. Имтиханга әзерләнәм. Тарих буенча дәреслекләр укыйм. Иртәгә кичке алтыда университетта консультация булырга тиеш...»

**«12 август.** Бүген көн яхшы күренә. Төш вакыты. Авылда урак өстедер инде. Асия җиңгигә җавап хаты яздым. Шуннан соң эштер-пештер генә бер-ике шигырь-мигырь сызгаладым:

*Ап-ак кәгазь битләренә*
*Тезелә шигырь юллары.*
*Һәрчак иңнәремдә тоям*
*Җылысын синең кулларың...*

Бу иҗат җимешен такмак дип санаган хәлдә, аның соңгы юлы – «чыктым аркылы күпер»гә яхшы мисал...»

**«13 август.** Көне буе тарих дәреслекләре укыдым. Иртәгә ничек тә «бишле» алырга кирәк. Ничек тә!»

**«14 август.** Иртәнге сәгать 6:00. Укып утырдым. Сәгать тугыз тулганда университетта идем инде. Фәннур абыйны очраттым. Имтихан уздырыласы аудиториягә кереп билет (№42) алдым. Имтихан алучылар өч кеше иде. Каралама өчен кәгазь бирделәр. Урыныма барып утырдым. Билетта өч сорау: «Бородино сугышы һәм аның нәтиҗәләре», «В.И. Ленинның «Эшчеләр сыйныфы һәм милли мәсьәләләр» дигән мәкаләсе», «1959-1961 елларда СССРда фән һәм культура үсеше».

Исемә төшереп, каралама-кәгазьгә белгәннәремне төшерә



*«Ялкын» журналы редакциясе. 1979 ел. Сулдан уңга (утырганнар): Разил Вәлиев, Роза Хафизова (баш мөхәррир), Фәния Хәйруллина, Айдар Үтәгәнов; (басканнар): Эльмира Закирова (Мәҗитова), Асия Кәримова, Хәйдәр Гайнетдинов, Фәридә Мөхәммәтшина, Рафис Гыйззәтуллин, Гүзәл Камалова*

башладым. Ярты сәгатьтән сөйләргә әзер идем инде. Татар абзыйга (*шулай дип язганмын. – **Л.Л.***) сөйләдем. Ике өстәмә сорау бирде дә «бишле» куйды. Рәхмәт әйтеп, саубуллашып чыгып киттем.

Ркаил Зәйдуллин да имтихан биреп чыккан. Аңа «дүртле» куйганнар. Ләис Зөлкарнәевкә – «бишле».

Ркаил белән газета-журналлар нәшриятына киттек. Редакциядә Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин һәм Фәннур Сафиннар белән сөйләшеп тордык. Актаныш кызы (Байсар авылыннан) Эльмира Мәҗитова *(хәзер Закирова фамилиясен йөртә. – **Л.Л.**)* очрады. Аның белән дә гәпләшеп алдык.

Кичке якта университет студентларының дүртенче тулай торагында (441 бүлмәдә) шагыйрьләр белән очраштык. Очрашуга Зөлфәт абый, Фаил Шәфигуллин һәм Фәннур Сафин белән бергә бер апа да (мин аны июль аенда Матбугат йорты лифтында очраткан идем) килде...»

Соңыннан мин бу онытылмаслык очрашу турында Ф. Шәфигуллин, Ф. Сафин һәм Зөлфәт абыйга нисбәтле мәкаләләремдә тәфсилләбрәк яздым. Әйтик, менә Зөлфәт абыйга багышланган язмадан бер өземтә: «Мин – унҗиде яшьлек егет, Казан университетына укырга керү теләге белән килгән абитуриент, яшьтәшләрем Ркаил Зәйдуллин (соңыннан – Зәйдулла), Ләис Харрасов (әдәби тәхәллүсе – Ләис Зөлкарнәй) белән бергә тарихтан соңгы имтиханны тапшыргач, кала тулай торакларының берсендә Зөлфәт абый белән очрашырмын. Имтиханнарны уңышлы тапшыру уңаеннан җәһәт кенә оештырылган кечкенә мәҗлесебезгә Зөлфәт абый каләмдәш дуслары Фаил Шәфигуллин, Фәннур Сафин белән килгән булыр... Тыйнак мәҗлес башланыр, кунакларга дип алынган коньяктан аз-маз авыз итә-итә, мәзәк хәлләр сөйләнер, шигырьләр укылыр, кунаклар безнең кай төбәкләрдән килүебезне – гәрчә матбугат битләрендә ара-тирә күренгәләгән шигырь-язмаларыбыз буенча кай яклардан булуыбызны инде тәгаен белсәләр дә – янә кызыксынып-сораштырып алгалар, шулвакыт Зөлфәт абый, Фәннур абый, Ләис һәм мин, һәммәбез бер яктан – бер төбәктәнрәк (Мөслим, Минзәлә, Бакалы, Актаныш-Мөслим) булуыбыз белән мактанып, шаярып кына масайган булып, Фаил абый белән Ркаилне үртәп, үзара көлешеп алган булырбыз, аннары барчабыз бергә, тыела алмыйча, рәхәтләнеп көләрбез... Зөлфәт абый: «Кыстати, әй, армиядәге дустың турындагы язмаң озакламый «Яшь ленинчы»да чыгачак!» – дип, миңа сүз арасында гына куанычлы хәбәр әйтеп куяр... Теле телгә йокмаган Зөлфәт абыйның сөйләгәнен тыңлап, кызыклы җирләрендә һәммәбез белән бергә көлеп, әмма күп вакыт тыенкы гына елмаеп утырган Фаил абый да, минем тарафка башы белән ишарәләп: «Әле аның бер мәзәге дә тиздән бездә – «Чаян»да басылачак», – дип, мине тагы да үсендереп җибәрер...

Бу – 1979 елның 14 августы булыр...»

Фәннур абый Сафинга кагылышлы язмадан алдагы юлларга мондыйрак өстәмә: «Кичкә таба Ркаилнең тулай торактагы бүлмәсенә өч шагыйрь (Ркаил аларны алдан чакырган иде) килеп керде: Зөлфәт, Фаил Шәфигуллин һәм Фәннур Сафин. Без (Ркаил, Ләис Зөлкарнәй, мин) тыйнак табын әзерләгән идек. Таныштык. Өстәл тирәли утырыштык. Сүз арты сүз китте. Башта кунаклар, аннары без шигырьләр укыдык. Фәннур абый тиздән «Казан утлары»нда басылып чыгачак «Татарстаным» шигырен укуы белән истә калды:

*Чын батырлар җире, диеп*
*Мактау ява барлык дустан.*
*Кайда гына, кемнәр генә*
*Белми сине, Татарстан.*

*Кара алтын вышкаларын*
*Кулларына тотып барган*
*Сабыр җанлы батыр кебек*
*Күренәсең ераклардан...*


Әйе, бу – 1979 елның 14 август көне булыр...»

Бу көнне мин, шагыйрь абыйлар килер алдыннан, тулай торакта Актаныш районының Байсар авылы егете Газинур Газетдинов *(ул соңыннан Ркаил һәм Ләис белән бер төркемдә укыды. Хәзерге вакытта Әлмәт шәһәрендә яши. Җай чыкканда очрашкалыйбыз. – **Л.Л.***) белән танышканмын икән әле. Аның белән бергә дүрт имтихан тапшырдык. Исемнәребезне шушы көнгәчә белмәгәнбез. Иртәгә авылына кайтып китәргә уйлап торам, диде.

Ул көнне, кунакларны озаткач, Ләис белән икәү Ркаил бүлмәсендәге матрассыз караватларда йокладык...»

Август ахырында, авылга кайтып, мин кабат Казанга килгәч, авылда әнием университетка укырга керүем турында хәбәр алган...

Хәзер уйлап куям, әгәр имтихан биреп йөргән көннәрдә көндәлек алып бармаган булсам, мин ул чактагы хатирәләрне ничек яңартыр идем икән... Барысын да исемдә саклый алган булыр идемме? Ай-һай... Кем әйтмешли, хәтер – тишек иләк: күргән-ишеткәннәр берничә ел эчендә коелып бетәргә мөмкин...



**ШИГЪРИЯТ**
***Сәйләннәр иленә сөйләрсең***




**ДҮРТ ХИКӘЯ**
***Сәер кеше***



**НӘСЕР**
***Кем беренче?***

# Әдәбият





*Шагыйрь Рөстәм Мингалим 1937 елның 15 августында Самара өлкәсе Камышлы районындагы Йолдыз авылында туа. Үз вакытында Казакъстанның Күкчәтау өлкәсендә тракторчы, Ташкент шәһәре заводларында слесарь, Бөгелмәдә йөк ташучы булып эшли. КДУны тәмамлагач, «Яшь ленинчы» газетасында әдәби хезмәткәр һәм җаваплы сәркәтип, Татарстан Язучылар берлегендә әдәби киңәшче була. Рөстәм Мингалим балалар әдәбиятында, проза һәм драматургия жанрларында актив эшли, киносценарийлары да бар. «Дәрт чүлмәге» исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. «Идел» журналы шагыйрьнең тууына 80 ел тулу уңаеннан бер шәкел шигырьләрен тәкъдим итә.*

## Рөстәм Мингалим

## КУЛЫМ СУЗЫП, ТАМЧЫ ҖЫЯМ УЧЫМА

***

Исәнләштек.
Елмайдың.
Мин сиңа сүз дә ялгый алмадым.
Ә син
ут сибеп,
йолдызлар чәчрәтеп
тимерне-тимергә ялгадың.
Аннан киттең...
Күптән киттең...
Инде беткән кебек идең онтылып.
Ләкин хәтеремдә
Бүген кабат яктырдың
Йолдызлар эчендә
яңгыраган
яңа җыр булып.

### УЛ ЕЛЛАР...

Яратуның күзе булмый, диләр,
була икән һәм бик зур була.
Эчендә нур була, тышында нур,
зур күзләрдә җылы нур гына!
Шул зур күзләр
салкын акыл чорына
җылы бөрки алган өчендер,
мин тормышта хәтта кеше ярын
ятратканнарны да кичердем.
Кичерүче булды үземне дә –
шулай кушты безгә ул еллар.
...Чәчкәйләрен
кара байрак итеп
китсенмени Җирдән ялгызлар?

Онытмадык шуңа аларны да,
гөнаһтыр бу – гөнаһ санасак.
Тик гөнаһсыз булыр идекме без,
әгәр берне генә яратсак?
Йөрмәдек ич берәм-берәм генә,
бергә-бергә бәхет эзләдек,
һәм яктыртып барды еллар төбен
яратуның якты күзләре.

***

Кич башланган яңгыр һаман ява,
Һаман ява, һаман туктамый.
Таш этажлар йоклый,
таш йорт йоклый,
син йоклыйсың,
Ә мин йокламыйм.
Минем бүлмә өстә, синеке аста:
ике тәрәз карый урамга.
Төне буе тәрәзәңә бәрелеп
яңгыр тамчылары уала...
Төне буе тәрәзәңә бәрелеп
минем матур уйлар уала...
Якындагы тирәк, теләсә дә,
тормыш кануннарын бозалмый:
Яңгыр тамчылары һәлакәттән
саклау өчен яфрак сузалмый.
Минем уйларымны һәлакәттән
саклыйм дисәң, сиңа авырмы?
Син бит – кеше, сеңлем. Синең күңел
уйларымны тотып калырлык.
Син йоклыйсың...
...Урының йомшакмы соң?
Каты булса, уян; тартынма.
Ал бүлмәгә менеп миндәремне,
Матрасын ал, ал син барсын да.

...Яңгыр ява, яңгыр тамчыларын
Таш стена ватып чәчрәтә;
Яңгыр ява, ишеп шыксыз тәрәз –
Тамчыларны вата, чәчрәтә...

## КИЛ

Кил яныма, кер бүлмәмә,
тормышыма, гомеремә.
Нишләрсең минем белән, дип,
беркатлы сорау бирмә.
Эш өчен дөньяда син дә
мин генә булдыммыни?
Кемнәрдәдер мәхәббәт бар,
безгә нәрсә? Юкмыни?
Синдәйне табалмам, диеп
әйтмим икән үзеңә,
Бит син миннән ишетмәссең
табам дигән сүзне дә.
Шулай булгач, кил яныма,
белешмә, сорау бирмә.
Сорашмыйча, белешмичә.
килгән идең бит җиргә.

## КАЗАН КЫЗЫНА

...Никтер,
узган елларыңны
миңа сөйләргә омтылдың,
аннан
кинәт кенә тындың...
Узган – ул миннән дә узган,
бүгенеңне сөйлә әле,
бүгенге
йөрәгеңне сөйлә.
Дөресен генә әйтсәм, иркәм,
узганыңны
сулышыңнан беләм:
синең узган –
Иделнең
былтыргы дулкыннары инде.
Былтыр исә мин Иделдән бик еракта идем.
Бүгенеңне сөйлә миңа.
Бүгенге
йөрәгеңне сөйлә
Иделнең
киләчәктәге дулкыннарын күреремә
ышанасым килә.

## БЕЗНЕҢ ДУСЛЫК

Сөю уты көчле диләр иде.
Дөрес икән...
бүген үзем тоям.
Минус 40та,
җилдә
Пәлтә төймәләрен
ычкындырып куям.
Җитте җир
Күренсә.дә,
шактый икән ара.
Соң, син, иркәм,
ник ялан баш?
Өши күрмә, кара?!
Ул да: «Кара,
өши күрмә?!»
Шулай
ике гашыйк
Барабыз
Карлы тауларның
түбәсенә басып.
Әгәр беребез
сүнсә юлда.
Чорга якты өстәп...
Кем кала?!
Ике эзне дә
илтү
синең өстә?!

## ЕЛМАЙ ӘЛЕ БЕР ГЕНӘ

Ниләр булды үзеңә,
ике кара күзеңә?
Мә кульяулык, сөрт яшеңне,
сөйлә серең үземә.
Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә!
Йөзең түгәрәк кенә,
үзең күбәләк кенә.
Керик әле бакчаларга,
йөрик бергәләп кенә.
Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә!
Гөл биреп юатыйммы,
биримме сабырлыгым?
Буйларыңа туры килми
уйларың авырлыгы...
Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә!
Акыллым, гөл генәм,
елмай инде бер генә!

## ЯРАТУГА ХӘТЛЕ

Бик яратып бардым,
бардым бераз соңлап.
Бик сагынып бардым,
бардым бераз соңлап.
«Соңламагыз!» диеп
киңәш бирә алам. –
Тормыш әнә шулай
һәм шул килеш кала.
Барсагыз да йөгереп,
минем кебек итеп.
Барсагыз да очып,
мине күпкә үтеп:
яратуга хәтле
ара шундый ерак,
яратырсыз соңрак,
сагынырсыз соңрак.

***

Аръягында син Иделнең көтәсеңдер,
Беләсеңдер минем килеп җитәсемне.
Үзем барам бүләк тә юк кулымда
Шуңа миңа бик җиңел дә һәм кыен да.
Дулкыннарны яра көймә
Тамчыларда күп төрле төс һәм тамчы сибә.
Кулым сузып тамчы җыям мин учыма.
Мең төрле тамчы бирим димен сиңа –
Тик тамчылар Иделгә тиз кабат коела.
Шуңа миңа бик җиңел дә һәм кыен да.



*Айгөл Миңлебай кызы Хәсәнова 1990 елны Киров өлкәсе Нократ Аланы районы Иске Пенәгәр авылында туган. Музыка мәктәбен тәмамлаган, 6 яшьтән бирле җырлый, 14 яшьтән шигырьләр яза. Югары белемне Казан дәүләт университетында ала. Бүгенге көндә Казан шәһәрендәге 8 гимназиядә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.*

# Айгөл Хәсәнова

## КАБАТ ЯНМАС ЙӨРӘК УЧАКТА, КҮЗЛӘРЕМДӘ САГЫШ БАР ЧАКТА…

### БУШ ХЫЯЛЛАР

Безнең үткән мәхәббәтне
Син, бәгырькәй, эзләмә:
Көзнең сагыш яфраклары
Яуды безнең эзләргә…

Янәшәңдә барырга дип,
Сагыш томаны сарса,
Сине, бәгърем, эзләдем мин
Буш хыялларым аша.

Хыялларым кошлар кебек
Китсен ерак илләргә.
Булган бар өметләремне
Бүләк итәм җилләргә.

### ПЕНӘГӘРЕМӘ

«Туган ягым – яшел бишек»,
Бу сүзне һәркем белә!
Туган якны сагынганда,
Күздән яшьләр сибелә.

Су буйлары, чишмәләре
Якын, беләм, һәркемгә!
Ул болыннар, ул басулар…
Күңелләргә ямь бирә.

### АДАШУ

Син миннән еракта,
Бик тә бик еракта,
Арада үтәлмәс юллар бар.
Сагыш, моң йөрәктә
Басылмый җырлап та,
Төзәлмәс без кылган хаталар.

Арада – киртәләр.
Кичермим мин сине –
Ышанма син юкка.
Син киттең еракка,
Мәхәббәт илендә
Мин калдым озакка.

### ДӘВА ЭЗЛИМ

Сөям сине ерак илләрдә,
Көтәм сине ачы җилләрдә.
Беләм, исмәс җилләр кирәгә…
Үткән сөю калыр күңелдә…

Чынбарлыкны аңлар өчен мин,
Ябып куйдым сөйгән күңелне,
Эзлим дәгъва, эзлим бүген мин,
Теркәп куеп өмет җебемне.

### ЗӘҢГӘР ЧӘЧКӘ АЛЫП ӨЗСӘҢ…

Зәңгәр чәчкә алып өзсәң –
Көннәр аяз булачак.
Сары чәчкә алып өзсәм –
Хәсрәтләрдә яначак.

Шул чәчкәләргә карыймын,
Белмим хәтта нишләргә.
Үз-үземне алдатырмын,
Аннан терсәк тешләргә…

Бәлки, әле таңнар атар,
Бәлки, кояш та батар.
Шул мизгелнең кайсылары
Чәчкәдәй җанга ятар?

### АЧЫЛЫГЫЗ

Нигә генә кердең күңелгә,
Сөюемнән шашып көлергә?
Ак томаннар булып уйнадың,
Җил-давыллар булып урадың…

Кабат янмас йөрәк учакта,
Күзләремдә сагыш бар чакта…
Әкрен генә сүнеп мин барам,
Ачылыгыз, уйлар, томаннан…



*Мин – Рәфыйкова Эльвира Дамир кызы. Татар һәм урыс шигъриятенә гашыйкмын. Көнемне, гадәттә, берәр шигырь укудан башлыйм. Соңгы арада урыс классик шагыйрьләрен татар теленә тәрҗемә итү белән мавыгам. Үземне шагыйрә дип әйтмим. Бары тик күңелгә килгән уй-фикерләрне язам гына.*

# Эльвира Рәфыйкова

## БАСТЫРЫЛГАН ҺАВА – ҺАВА ТҮГЕЛ...

### КАРА КИЧТӘ

Каралты түбәләр өстеннән,
Күкләрне дөм манып карага,
Кич төшә галәмнең түреннән –
Тынгысыз күңелдән моң ага.

Ярсыган күңелем ашкына –
Кош сыман иреккә, далага.
Аңлашу өмете тамчылап
Юк була таралып һавада...

Мин очам җилләрдә тибрәлеп
Мәңгелек сөюем каршына,
Яшеннәр, давыллар кичәмен –
Янымда гомергә калсынга...

### МИН СИНЕ ЯРАТАМ

Әйтелеп тә аңланмаган
Кебек һәр сүз...
Яратам дип чыланган бит
Яшьләрдән күз...
«Яратам»га соң шул инде,
И, җаным, түз...
Вакытында  әйтми калган
Өч газиз сүз...

### КАЕННАРЫМ БАШ ИГӘН

Каеннарым нигә башын игән?
Бу көзме соң моңа сәбәпче?
Көтмәгәндә юеш кары белән
Яфракларга сибә ул бәсне.

Кәүсәләрнең ап-ак тузларында
Сызык-сызык ята яралар.
Сәбәпләрен шуның аңлаткандай,
Яфраклары җиргә явалар...

### КЕМ СИН?

Төнемме син, көнемме син?
Төшемме син, өнемме син?
Әйтче, кем син? Әйтче, кем син?!
Әллә җыр син... Әллә көй син...
Әллә кем син... Әмма гел син:
Күңелдә син... Уйларда син...
Сүзләрдә син... Әмма кем син?
Ярамы син? Дәвамы син?
Йә моңмы син? Йә зармы син?
Сагышмы син? Йә ярмы син?
Сөюме син? Көюме син?
Йә, кем соң син?! Әйтче,
Кем син, әйтче, кем син?
Тик якын син... Бары бер син...
Бары бел син... миңа тик син...
Кем булсаң да кирәк бит син!

### БӘХЕТ ТАЛӘБЕ

Төшләремдә ак нур иңде миңа...
Алып килгән бәхет сәламен.
Тик иң башта бәхет диңгезенең
Әйтеп бирде катгый таләбен.

Ул диңгезнең бар ди ярларында –
Без кичәргә тиеш кыялар,
Без җиңәргә тиеш ак дулкыннар...
Ак дулкыннар ишкән тын ярлар...


### ЫШАНМАДЫМ

Сиңа бит мин ышанмадым бер дә,
Тик барыбер ачтым күңелем.
Җылылыгың  синең эретте күк
Сагыш болытларын күгемнең...

***

Яңгыры да яңгыр түгел иде...
Әйтерсең лә, синең кагылуың...
Бастырылган һава – һава түгел...
Авырайткан сине сагынуым.

Җилләр җилләр түгел – салкынлыгың...
Балкыр микән назлы кояшым?..
Бу язымда җаным синдә калды...
Инде мине генә уйларсың.



*Гөлүсә Арикеева – Саба кызы. Быел урта мәктәпне тәмамлады. «Мәктәпне үлеп яратам, бөтен теләгем – укытучы булу, – дип язган ул безгә юллаган хатында. – Шигырь язу техникасы белән сигезенчедә укыганда таныштым. Ахматова, Маяковский иҗаты белән кызыксынып китеп, үз шигырьләремдә аларның алымнарын кулланып карарга ниятләдем. Миңа ошады!»*
*Гөлүсә быел Бөтенрусия «Илһам» бәйгесендә катнашып, икенче дәрәҗәгә лаек булды. «Идел» укучыларына ул өр-яңа шигырьләрен тәкъдим итә.*

# Гөлүсә Арикеева

# СӘЙЛӘННӘР ИЛЕНӘ СӨЙЛӘРСЕҢ

## ДӨНЬЯ – АНА

Дөнья – ана, без – сабыйлар.
Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада...
Дөнья, безне каргама.

Бүген төнлә дөнья каргыш чәчте.
Ачу тоткан җаннар, тәннәр,
Ачылдылар бөек көчләр.
Дөнья чәчте каргыш,
Биреш-алыш:
Дөнья вә без.
Ачылмаган мәче күзләр,
Яуган яңгыр суын җыйган күлле күзләр
Ярымтиле карап гафу үтенделәр.

Яңгыр безне юды кайнар яшьләр суы илә,
Ләкин күпме генә тырышмасын,
Без барыбер чистарына алмас идек,
Каплаганчы тәнне кабер ташы.
Каргышлардан саклап артык башны.

Тудык кеше булып. Үстек – кеше.
Без ясаган дөнья – кеше эше.
Нигә шулай? Ник мәгънәсез? Бәхет кайда? –
Сорау бирүләрдән хәзер нинди файда?

Төзедек бит бергә яки аерым салдык.
Дөнья – пычрак?
Әллә – алтын тулы сандык?
Ышаныгыз: мин ишеттем бүген төнлә –
Ул каргады безне, җавап бирә-бирә.

Ул да туган саф вә чиста булып,
Кояшларның, болытларның кызы, улы.
Без килгәнче, ул яшәгән җәннәт өстәп...
Шулай булгач, дөньямы соң,
Әллә безме явыз – менә хикмәт!

Яшәгәннәр саен, үлгәннәр дә арта.
Дөнья туа бара, ләгънәт арта.
Каргалганнар монда бәхет күрә һәр ишектә.
Каргалмаган нарасыйлар ни ишетә?

Ни күрәләр сабый күзләр? Ни хәтерли?
Яшәсеннәр алар, берни белми.
Әле нәни җанга тап төшмәгән.
Дөнья әле балаларны өшкермәгән...

Дөнья – ана, без – сабыйлар.
Аңа күңеле балада, бала күңеле кайларда?
Дөнья килә каргарга.

## СИНСЕЗЛЕК

Синсезлек булыпмы,
жанымда эт өрә.
Ачы чынбарлык
елак күңелемне ашый.
Буш дөньямда
билгесезлек хөкем сөрә.
Юләр йөрәк
кыйнауларга карышмый.
Синсезлек...
Мин аны яктырак булыр дип өметләнгән идем.
Ә чынлыкта
Синсезлек үзе үк – өметсез.
Нык булып тоелган безнең «без»гә тидем.
«Без» коелды да төште.
Нәтиҗә: «мин» һәм «Сез».

Синнән туептыр, мөгаен,
синсезлек миңа
Бәхет китерер, дип уйладым.
Ялгышканмын.
Синнән, гомумән, туеп булмады.
Ә туймыйча, «Синсезлек» – «Син», «Сез» һәм...
Бетте!
Шулай, «Син» «Сез»гә әйләнеп кипте.

Синсезлек...
Сәер: ул синсезлек белән күпләр рәхәттә яши.
Ә миңа синсезлек ошамады.
Бу – начар гадәт.
Әйдә, ялгыш кына төсле итеп, бер күрешик –
Синсезлек югалыр иде.
Мин – канәгать.
Син...
Канәгать?!

***

Мин беләм: нигә ай шулкадәр кып-кызыл –
кояшта кызынган, көндезен, ялгызы.

Мин беләм: нигә ай кып-кызыл шулкадәр –
оялган. Кайсыдыр мактаган бик хәтәр.

Мин беләм: нигә ай шулкадәр кызарган –
Салкында, түзмәстән, җил белән үбешкән!
(Сәердер? Юләрлек, әлбәттә, килешәм!)
Нишләрсең?! Түзмәгән!
Салкында! Җил белән!
Үбешкән! Килмешәк...
«Ятратканмы җилне?» –
«Әлбәттә, берсүзсез!»
«Нигә соң ул елый,
Төн буе, өзлексез?!» –
«Ә син чык та төнлә
Урамга, салкында,
Үбеш җил белән бер,
Сәгатьләр буена!»

Мин беләм нигә ай шулкадәр кып-кызыл –
Җил белән аларның мәхәббәт бик кызык!

***

Күзләреңне йом әйдә,
Күрмә үлеп барганын бөек татарлыгыңның.
Син күрмәсәң, башкалар да
Сизмәс мәет калганын
Татар булган урында.
Татар булсаң,
Һич кызганмый бирер идең барын да
Милләт өчен,
Халкың өчен,
Илең өчен...
Ә син идең
Горур башың
Вакыт агымы каршында.
Онытасың туган телең,
Тукай хәзер кирәкми.
Теләгәннәр укысыннар шул «Котадгу белек»не,
Без бүгенге белән яшик,
Авыр рокны тыңлап көн дә.
«Күбәләк»не җырласыннар
Тик... әбиләр генә.
Татарча сөйләшү хәзер сине мыскыл итә.
Дөньяда һич татар түгел, башкалар идарәдә.
Теленә тугры булмаган
Халыкка нинди хөрмәт?!
Инкыйразның җитәчәген
Исхакый алдан күрмәк.

Рүзәл Мөхәммәтша

# СӘЕР КЕШЕ

Автобус Ташлыга борылды. Гел юл уңаендагы авыл түгел ләбаса. Район үзәгенә турыдан гына чабып булганда, көзге пычракны ерып, ничә чакрым урап изаланасы.

— Хәзер бер көтү халык керәчәк, — дидем мин, эни тутырып җибәргән юл букчасын утыргыч астынарак яшереп. — Сак бул, абзый!

Янәшәмә утырганнан бирле тәрәзәдәге тапларны җентекләп күзәткән ир уртасы башта дәшмәде. Аннары гаять шикле рәвештә:

— Теге вакытта май иде, — дип куйды. Һичнәрсә аңламасам да:

— Кайчан? — дип сорарга кирәк таптым.

Ул миңа борылды һәм, әллә төгәл вакытын искә төшерде, әллә төгәл вакытны билгеләр өчен кулайрак сүз эзләде — кыскасы, тагын күпмедер дәшми торды да:

— Күптән, — диде, ниһаять. Тагын тынып алгач, өстәде: — Шушы автобуста берсеннән-берсе сусыл, балланып өлгергән сылулар белән шаярып-көлеп, дөнья гамен гамьләп барган чак иде ул.

Мин пычрак автобуста кызлар белән чөкердәшеп утыруны бик авырлык белән генә күз алдыма китерә алдым, шулай да сер бирмәдем. Карашым белән җәһәт кенә абзыйның өс-башын капшап чыктым: әйе, тузып бетмәгән әле бу, юындырып, киендереп куйсаң, утыз-утыз биш яшьлек ярыйсы гына егеткә әверелергә мөмкин. Сәер инде үзе. Кызыксыну белдермәсәм дә (чөнки, чыннан да, кызыксынмадым), сүзен моңсу рухта дәвам итте:

— Яңа шигырь табылган вакыт. Шуны сөйләп күңелләрен күрдем: «Ары бара, бире килә — бер керә дә бер чыга! — ул кызыл фәсле малайга таңнар калдым бу кичә». Ник «а»сын әйткәч, «бә»сын әйтмисең, авторы кем, дип кызыксынды алар. Әйтмим, дип кирегә сукаладым. Ник, ну, ник, дип үз сүзен сүзләделәр. Сезнең ныгып бетмәгән саф күңелегез андый тетрәнүгә әзер түгел, дигән булдым. Абау, ул кадәр төрттермәсәң, дип чыелдаштылар. Кыскасы, ярты автобусны авызыма каратып, үземне чын-чынлап әллә кем итеп тойган бер мизгелдә шушы тукталышта әчкә узды ул. Туганнан туган абыем.

— Ташлыдамыни?

— Ташлыда.

— М-м.

— Аны ике ел элек печән өстендә һәйбәтләп ватканнар, чәчкәннәр иде. Табиблар яңабаштан җыйды: алыштырасын алыштырдылар, ябыштырасын ябыштырдылар, ямыйсын ямадылар. Нәтиҗәдә төзек кенә рәвеш алды. Дөрес, ярты ягы эшләми иде: сул аягын беркадәр өстерәбрәк йөри, сул кулы терсәктә бөгелгән килеш корышып каткан, ияге чалшайган, калын котсыз күзлек астындагы ике күзе һәрдаим яшь агыза… Башка вакыт яисә урын туры килсә, мин, шөбһәсез ки, каршына чабып, абыйны кочаклап алыр идем. Ләкин бу юлы түгел. Бу юлы… булмады. Чыраемны капюшон астына яшереп, тавышымны баса төштем. Гүзәллек һәм дәрт аңкыткан чибәрләр хозурында ничек гарип туганым янына барып сүз катыйм инде? Ул мине күрмәде. Әллә, үзем ише, күрмәмешкә сабышты.

…Мондый озын монологтан соң, күңелемдә, һичшиксез, җавапка лаек сорау борын төртте. Әмма Ташлыда кергән халык изеп китү сәбәпле, тиз генә ипкә килә алмадым, тәрәзәгә сыланмас өчен, яртылаш борылып, иңемне агай-апаларга терәдем, әйтерсең, барысын да хәзер үк ишектән кире этеп чыгарырга исәпли идем. Теге кешенең бу мәхшәрдә гаме булмады:

— Сагышлы пейзаж: кичәге мәңге яшел яфракларга сары буяу тамган, кояшның җетелеге уңа төшкән, кара-кучкыл болытлар — табигатьнең җыерылган кашы гүя, — дип уфтанды ул, нигәдер. Гап-гади итеп: «Көз җитте», — диясе урында. Әйтәм бит, сәер кеше. Мин сорап калырга өлгергәнче янә үзе сүз катты:

— Без яңадан күрешмәдек. Озакламый, гомумән, дөньядан кул селтәде ул. Җирләргә дә кайта алмадым. Хәзер миңа күпкә җиңелрәк булырга тиеш, югыйсә: ояласы, хурланасы кешем юк. Сәламәт кардәшләр генә калды. Авызыңнан

былбыллар сайрат, нурлар чәч, энекәш! Ләкин, ни хикмәт, җанга тамчы да җиңел түгел. Киресенчә, авыр хәтта. Ә автобус, шуны белмәгәндәй, һәр атна саен, һәр атна саен, һич тә юл уңаенда булмаган шушы авыл аша уза…

Эчем пошса да, аны бүлдерергә базмадым. Букчадагы йомыркаларның, помидорларның бөтенлеген тикшереп, бәлешнең мае акмаганга тулы инанган чакта абзый урыныннан торып чыгарга әзерләнә иде инде. Кенәгергә җиткәнбез икән. Чаллы ягына китүчеләр монда күчеп утыра. Кибән сыртыдай убылып төшкән җәмәгать арасында абзый инде гаип була язганда, кычкырырга ашыктым:

— Абзый, туктале! Авторы кем булды соң инде? Шигырьнең?

Ул, башына тай типкәндәй, бер мизгел акаеп карап торганнан соң, канәгатьсез төстә ияк чайкап, тизрәк юкка чыгу ягын карады.

Ник алай итте? Шагыйрьне атаса, теле корый идеме?

Сәер кеше дигәч тә.

# ӘНИ

Нәүбәттәге шаулы кичәдән соң чайкала-чайкала метрога төштем. Күтәренке рух, ләззәтле хисләр, яшьлек һәм яз тантанасы күңелдән таралып өлгермәгән иде әле. Аның каруы, ярыйсы гына татылган утлы су канга таралып өлгергән, ахры: баш авырайган, буыннар йомшарган. Салкынча сафлыктан тынчу җылылыкка кергәнгәме, утыргычка төртелүгә йокыга талганмын.

Тукай мәйданында сап-сары марҗа уятты мине:

— Станциягезне узып китмисезме?

Аңгы-миңге хәлдә тирә-юньне күздән кичереп:

— Юк, — дидем, — ахыргача кайтам.

— Күпме карап барам, — дип, оеша башлаган әңгәмәне өзәргә бирмәде ул, кургашын тамчылары эленгән керфекне янә күтәрергә мәҗбүр булдым, — сез минем улыма охшагансыз. Ул да шундый иде: маңгае, борыны, ияге.

— Нишләп үткән заманда сөйлисез?

— Үтерделәр, — диде ул, гап-гади бернәрсә әйткәндәй. Язмышына күнеп өлгергән, дип сагышлы уйладым. Корышкан иреннәр арасыннан:

— Гафу итегез, — гыйбарәсе төшеп китте.

Апа чираттагы станциядә поезддан чыкты. Карашым, чуар кешеләр арасында бераз адашып йөрсә дә, барыбер тиз эзләп тапты аны: ул текәлеп миңа карый иде. Тартынып кына кул изәдә. Өтелгәндәй, йөзне читкә бордым. Гаять кыен, оят булып китте — әле беркайчан да эчеп әнигә эләккән юк иде минем.

# ХУП

Машина йөртү таныклыгымны алып калдылар.

«Хуп», — дип мыгырдандым мин, урамга чыккач.

Көн, үч иткәндәй, якты, матур иде. Дөньяны яз баскан. Чүп савытына сыенып, мәчеләр ләззәтле мырлаша, урман тулы каеннарын телеграф баганасына алыштырган Ходай кошлары тавыш-тынсыз гына кояшта сырт җылыта. Аяк асты — болганчык көзге. Анда кәефсез берәүнең сыек йөзе чагыла. Баш өстендә нәрсә булгандыр, әйтә алмыйм, күтәрелеп карамадым.

Күпмедер кая барып бәрелергә белми аптыраганнан соң тукталышка юнәлдем. Күнегә башларга кирәк — миңа хәзер ел буе автобуста йөреп канәгатьләнәсе. Дүрт саным төгәл, эти-әни исән-сау, Җир, элеккечә, үз күчәрендә әйләнә. Ә бер ел хәзер уза ул. Эт сигәнче уза. Шулай булгач, борчылырга сәбәп бармы? Юк, һич юк.

Бар. Бар шул.

***

Ул кичтә машина кабызу ни пычагыма кирәк иде инде? Кеше шикелле аңгыраеп, телевизор карап

кына утырырга ярамыймы? Театрга барам, имеш. Премьерага. Тфү! Артка чигенгәндә бамперның нәрсәнедер үбеп алуын сиздем. Чыгып карагач, күңелсез булып китте: куак астына поскан җете кызыл Дэу Матизны сыдырганмын.

— Хуп, — дидем, муен артын кашып. Ары карадым, бире карадым, ахыр чиктә, әлләни тавыш куптарырлык мәсьәлә түгел бугай, дигән фикергә килеп, илаһка тапшырырга уйладым: — Әппәр!

Ике атнадан гаишниклар кунакка чакырды. Каршы торырга һәйбәтләп әзерләнеп баруыма карамастан, инспектор кайда, нәрсә һәм ничек булганын үзем дә белмәгән нечкәлекләрдә сурәтләп биргәч, шаһитләр күрсәтмәсен фото- һәм видеоматериаллар илә дә ныгыткач, билләһи, башны дуракка салырга уңайсызландым. Җирән эфисәргә текәлеп:

— Нишли алам? — дидем. Ул:

— Сөйләшеп кара, — дип, ишек төбендә таптанган Аллаһ колына ишарәләде. Шулвакыт җанымны якты нур җылыттымыни: күз алдымда калын күзлекле, яңагы эчкә суырылган берәү (сүсәргән портфель тоткангамы, сул ягы җилкәсе-ние белән асылынып төшкән үзенең, каешланып каткан пәлтәсе үткән гасырның утызынчы елларын хәтерләтә) гамьсез рәвештә уң табанын тупсага кашып тора иде. Мондыйларны гына күндергән бар, шөкер.

— Болай килешми бит әле, күрше, — дидем мин, тәкәллефсез төстә затлы җиләнемнең аскы ике төймәсен каптырып. — Аны иң элек үземә чыгасы иде. — Ул күзлеген борын өстенәрәк күтәреп куйганнан соң: — Икәү хәл итә алмас идекмени? — дип өстәдем.

Күршенең:

— Аны иң элек машина йөртергә өйрәнәсе иде, — дип тамак кыруыннан артыма утыра яздым. Без дә төшеп калганнардан түгел:

— Аны парковаться итәргә өйрәнәсе иде!

— Сез ник мине мыскыл итәсез? — дип борын сеңгерде ул.

— Кем мыскыл итә? — дидем, чирканып.

— Сез. Әле менә.

— Уема китермәдем.

— Машинаны урнаштырып куя белмисең, дигегез.

— Йөртә белмисең, дигәнеңә җавап иде ул.

— Дөресе шул бит. Бәрдереп качарлык булгач.

— Ник аны адәм рәтле итеп куймадың соң? — дип җикеренүгә күчтем.

— Сез тагын башладыгызмы?

Берничә мәртәбә шулай сүз башына әйләнеп кайткач, кызуымны басып:

— Хуп, — дип килештем. — Күпме кирәк?

— Нәрсә күпме? — дип төшенмәгәнгә салышты күрше.

— Мин сиңа чыгымнарыңны артыгы белән кайтарырга риза. Кирәк сумманы хәзер үк бирәм. — Бер тын дәшми торганнан соң фикеремне җөпләп бетердем: — Ә син гаризаңны кире аласың.

Шушы мәлдә аның ни кичерүен тоярга теләп күзләренә чумдым. Ләкин ике төпсез чоңгылда нинди җеннәр котырынуын белү яисә аңлау барыбер хәлемнән килмәде. Бераздан үзе ачылды ул: куаныч кузының бәгырь төбен кыздыруына чыдый алмыйча, авызын ерып җибәрде; калын шәмәхә ирене бүселеп төште; күзлек кысасы өстенә үрмәләгән куе кашлары тартышып куйды:

— Юк.

— Нигә? — дидем мин, шактый шомлана төшеп. Хәзер бик килешле буласы сарыклар һәм бүреләр турындагы гыйбарәне тел очында әйләндерсәм дә, ахыр чиктә, кайсыларының — тук, кайсыларының исән булуын җәһәт кенә исәпләп чыгара алмаганга, гадиләштерергә иттем: — Нигә?

— Сабак булыр.

— Х-хуп, — дидем мин.

Сүгенгәнче шулай дип куюы мәслихәт.

Көне генә, үч иткәндәй, шәп иде шул. Алда, үч иткәндәй, экияти гүзәл, кызу, аллы-гөлле, авыллы, шашлыклы, пляжлы, кызлар белән туйганчы сайрашып чыгарлык яп-якты төнле җәй бар иде! Иң кәттәләнер чакта, үч иткәндәй, шундый хәлгә тары инде, йә? Инспектор мәхкәмәгә алып барганда күңелсез уйларда чайпалдым.

Казый эшне коры тотты. Чүкечен сукканчы, өметле күзләремне төбәп:

— Башка төр җәза бирмисезме соң? — дип сорап карадым. Аның:

— Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексында юл-транспорт һәлакәте булган урынны калдырып киткән өчен йөртүчене бер елга яисә ел ярымга машина йөртү хокукыннан, яисә ундүрт тәүлеккә ирегеннән мәхрүм итү каралган, — дип чәйнәп каптырганын көчкә йоттым.

— Кая һәлакәт булсын ул? Тырнак эзе, — дип карыштым әле.

— Монда җинаятьнең нинди дәрәҗәдә кылынуы түгел, ә, гомумән, кылынуы мөһим.

— Алайса, ике атнага утыртып куегыз.

— Утырта алмыйм. Сез положительный гражданин.

— Ник алай?

— Характеристикагыз яхшы.

— Хуп, — дидем мин.

Көне генә, үч иткәндәй... хәер, үзегез беләсез.

***

Башта гаять кыен булса да, иялəшенде тагын. Дөнья — шул ук дөнья икән, кара йоккан тәрәзәләр аша карамаганда, яктырак, түгәрәгрәк тә булып күренә хәтта. Табигый, быел машина сирәгрәк ватылды, бензинга акча азрак тотылды, штраф түләмәдем — ул җәһәттән, күрәсез, «хокуксыз калу» мине чак кына черегән бай итми калды әле.

Юлларымны күрше белән кисештермәскә тырыштым, аны һич күрәсе килеп тормый иде: ул уңга борылганда, мин һәрдаим сулга салуладым, ул каршыга килгәндә, мин һәрдаим ботинка бавын бәйләргә чүгәләдем. Ботинкам баусыз булганда да. Теге көннәрдәге бәхәсен, миңа иң күңелсез чакта шылтыратып, оятсызларча страховка номерын сорап алуын, Халыклар бердәмлеге көне белән котлап открытка җибәрүен искә төшерүгә бизгәк тотучанга әйләндем. Подъездан чыгуга иң беренче аваз итеп аның борын сеңгерүен ишетермен төсле иде.

Бөтен документация һәм кануннар буенча үземнең хаксызлыгымны аңлаган көе, шушы оешып бетмәгән Аллаһ колының хәлемә кермәве, чигенмәве эчемне пошырды, күңелгә корт кертте: тәкъдимемә күнсә, ни югалта иде инде ул? «Эш» папкасына теркәлгән... гаризасын гына.

Ләкин минем өчен иң авыры — җете кызыл Дэу Матиз янынннан сабыр гына узып китү булды. Төн уртасында кайтаммы, таң тишегеннән китәмме, үзегемдә утырган җен чәчрәп чыгып, гаделлек даулады: һичкем юк, давай, тәгәрмәчен тишәбез! Һичкем күрми, давай, көзгесен ватабыз, үзем шухерда торам... Аның зиһенне эретерлек татлы сүзләренә ышанып, ымсындыргыч-кыю киңәшенә колак салсам, шунда ук истирахәт хисләр кичереп, язмышымнан мәңге разый калырга тиеш идем. Бер ел буе кабахәт уйлар бәгыремне талкыды. Бер ел буе сынатмадым, түздем. Күршене шул рәвешле кичерүем — әйе, нәкъ менә кичерүем! — мине үз алдымда көчле итте, бөек итте.

***

Баш чатный. Колак тонган. Авызга мәче йомышлап чыккан сыман.

Бүген шукадәр күңелсез хисләр кичерер өчен, кичә никадәр күңелле хисләр кичерергә кирәк булды икән?

Вакыйгалар үсешен яңартырга тырышып карыйм, әмма челпәрәмә килгән бербөтен көннең аерым-аерым кыйпылчыклары гына табыла: «права»ны кире алдым, аннары — театрга... юк, рульгә утырмадым — бизелгән... спектакль?.. мәктәп укучылары язган этюдлар... гримерный...

Суыткычны ачкан идем — бушлыкта адаштым.

Иреннәр бер-берсенә ябышып каткан.

Салкын душ искә китергән арада тиз генә кибеткә — әйрәнгә томырылдым: хәзер ул гына коткарса...

Мин рәт-рәт тезелешкән машиналар арасында алпан-тилпән йөргәндә, уянуга ук нерв системасыннан тулы мөстәкыйльлек алуга ирешкән бәбәкләрем куак астына поскан Дэу Матизга тәгәрәде. Йөземнән мизгел эчендә кан качты. Калтырана-калтырана кесәмдә капшана башладым. Ачкыч очында җете кызыл буяу тузаны күреп аһ иттем. Капотка, сүзен дөрес чамалап бетерсәм, зур-зур урыс хәрефләре тырналган иде: ХУП!

# ЮЛ ЧАТЫНДА

Поезд, томанга чумгач, тынып калды. Таң күзенең беренче нурлары үлән очында мәмрәп утырган чык тамчыларына, төн күләгәсеннән йөзен ачкан агачларга, йортларга төшәргә ымсына иде инде. Сизелер-сизелмәс итеп кенә юкә балы кушылган салкынча саф һавадан исереп егылырлык иде.

Иртә — көннең кыз чагы...

Автобус тукталышында мине җирәнлеге уңып бетмәгән көрәк сакаллы карт кар-

шы алды. Базык гәүдәле. Яланбаш үзе. Коңгырт җиләне астыннан ап-ак күлмәк чабулары күренеп тора.

— Исәнмесез, — дидем, тартынып кына. Сәламемне алып:

— Поро эр, — дип җавап кайтарды ул.

Бу сүзләр минем өчен буш аваз иде, билгеле. Исем китмичә, эскәмиягә елыштым. Таныш түгел бәндә белән сүз алышырга теләгем булмавын карт тоеп бетермәде, ахры:

— Кая барасың? — дип сорады.

— Чаллыга, — дидем, иренеп кенә.

— Бүген ул автобус булмый.

Ирексездән авыз читем ерылды:

— Сез дә шуны көтәсез түгелме соң?

— Юк.

— Бу юл — Чаллыга гына.

— Юл бер җиргә генә ята алмый. Ул һәр тарафка илтә.

Мин, ни әйтергә белмичә, сабырланып, хәтта, мөгаен, югалып калдым.

Шәһәр иләһи тынлык кочагында иде. Ерактагы бер ишегалдында зелпе ботакларының әледән-әле дымлы асфальтны тырнап алуы да килешле халәтне бозмый, тынлыкның үзгә бер яңгырашы булып кына ишетелә иде…

— Кенәгергә кайтам мин, — диде карт. — Чаллы юлында кала.

— Чирмеш авылы бит ул.

— Шуннан?

— Татарча әйбәт сөйләшәсез, диюем генә.

— Син дә әйбәт сөйләшәсең ич, — диде ул, сынап карап.

— Татар булгач, — дидем, гадәттәгечә. Ләкин тавышым, нишләптер, киеренке булып чыкты.

— Әлбәттә.

Хәтердә гөлт итеп мәрхүмә абыстай әбием сөйләгән риваять кабынды. Алай да, хатирәләремне чит-ят кеше алдында әчке киемдәй чыгарып салырга ашыкмадым.

Безнең авылны да чирмешләр нигезләгән. Теге заманнарда каберен кабергә калдырмыйча сөрсәләр дә, халык хәтереннән сөрелмәгән — ындыр артындагы басуны бүген дә «Чирмеш зираты» дип йөриләр әле. Аннары авылга татарлар килеп урнашкан һәм… ирен тидерүгә җан савыктырыр шифалы суын, таяк төртүгә яфрак ярдырыр юмарт туфрагын, тутырып карауга күңелне гөл итәр гүзәл табигатен башка бер кавем белән бүлешергә теләмичә, төп халыкны елга аръягына куып та җибәргәннәр. Шунда мөһаҗирләр безне яман каргаган да әле, имеш: «Бөлмәгез дә, баемагыз да!»

Бу хәлләр хакыйкатькә ни дәрәҗәдә якындыр, белмим. Ләкин кесәмдә акчаның озак тормавын фәкать шушы каргыш белән бәйлим соңгы арада.

Табигый, үземне баскынчылар затыннан итеп күрсәтәсе килми иде. Шуңа күрә май каптым. Картның әчкә баткан күзләренә, җыерчык сыдырып төшкән йөзенә, тормыш суты кипкән иреннәренә бактым. И, гомер-бакый эт типкесендә йөреп, беркайчан да рәхәт күрмәгән бичара халык! Аларның бүгенге хәле дә безнекеннән мең кәррә аяныч лабаса. Җанга әллә ничек иде…

— Синең маңгаеңда язылган, — диде ул, уйларымны бүлеп. Һәм бармагы белән каш арасына кагылды. Аннары йөзен саба җиленә куеп, беравык ләззәтләнеп торды: — Кук Юмо сулышы… Тоясыңмы?

Буялмагандыр бит, дип маңгаемны капшаган арада тыкрыкта район авылларын гизәргә чыккан автобус борын төртте. Йөрәк, ниһаять, йомарламлы учтан котылган коштай, канат җилпеп куйды. Шикле карттан шомлануым шул дәрәҗәгә җитте ки, аның хозурында калмас өчен җир тишегенә керергә дә риза идем. Әмма автобуска сикереп менәргә әзерләнгәндә генә, карт:

— Аманлыкта! — дип үзе «ПАЗ» ишегенә ябышты.

Рәхәт булып китте…

Отыры шәһәр уянды, куак асларында посып яткан тузан шәүләсе акрынлап агач ябалдашларына үрелде, иңгә кунды, чәчкә орынды. Бераздан көн киерелеп үк җибәрде.

Ә мин юлаучы машинага утырып Чаллыга якынлашканда кояш сүрелеп бара иде инде. ■

*Февраль-апрель, 2017*

«ИДЕЛ БИТ УЛ, КИҢ БИТ УЛ»

2017 РОССИЯДӘ ЭКОЛОГИЯ ЕЛЫ

Гөлназ Мәхмутова

# БАЛ КОРТЫ

*Хикәя*

– Әнекәй генәм, әле һаман җыенып чыгып китә алмаганнар икән, төш җитә бит инде, – дигән ачулы сүзләреннән соң артка әйләнеп карасам, инде ул ишектән кереп тә китеп бара. Бары, җилфердәп, итәк чабуы гына күренеп калды. Безнең дәү әни шундый инде ул! Ачуы килсә, йөрәгеңә үтәрлек итеп әйтә дә, синең җавабыңны көтеп тә тормыйча, кереп китә. Калганы үз эшең, уйла, нәтиҗәсен яса, диюе аның.

– Алып бир әле, улым, дуганы? Әйдә, булмаса, бер әйләнеп кайтыйк печәнлекне, – диде дәү әти, ат җигә башлап.

Ел да шулай. Печәнгә төшәр алдыннан, дәү әтием белән бергәләп, чабылачак җирне карап кайтабыз.

Әнә көн инде кыздыра ук башлады. Дәү әнием бер дә юкка ачуланмаган икән шул! Мин эссегә чыдый алмыйча, утырган җирдән ышыкланыр урын карый башладым. Дилбегәне җиңелчә каккалап барган дәү әтием көлемсерәп куйды да:

– Нәрсә, улым, башыңны кояш кыздырамы? Әнә шул яфракны түбәтәең эченә куй. Табигать ул мәрхәмәтле, үз баласына ярдәм кулы сузарга һәрвакыт әзер! – дип, атны туктатты да, юл кырыенда үсеп утырган шактый дәү әрекмән яфрагын өзеп алып, миңа сузды. Чыннан да, аны башка япкач, бераз рәхәт булып китте.

Күктә тургай сайрый. Ат әкрен генә юырта. Шуңа арбаның үзенә бер төрле күңелле шыгырдаган тавышы кушыла. Мин юл кырыенда күренеп калган күгәрчен күзе, миләүшә, канәфергә охшаган кызыл төстәге чәчәкләргә сокланып барам. Шунда, исемен дә белмәгән аеруча матур чәчәк күреп, дәү әтиемә туктарга куштым. Ат туктауга, арбадан җиңел генә сикереп төштем дә чәчәккә үрелдем. Аны өзеп алып исни генә башлаган идем, ни күрим – таҗ арасында бал корты! Ул башы белән чумып, нечкә арт аякларын чәчәк таҗына терәп, нектар суыра иде.

– Дәү әти, кара әле, бу бит безнең бал корты! Бал җыярга дип кая хәтле килгән!

– Шулай шул, улым. Бал җыю аларга да җиңел түгел. Ләкин алар шөпшәләр кебек ялкауланып ятмый. Матур кәрәз үреп, балны мулдан тутырып куялар! Шифалы бал кешеләргә файда китерсен, диләр.

Мин чәчәкне саклык белән генә арба төбенә салынган печән өстенә куйдым. Бал кортының күңеленә бу бик хуш килмәде күрәсең, чәчәк таҗыннан чыгып, нәфис канатларын җилпеп очты да китте. Аның безелдәгән тавышы колагымда шактый вакыт яңгырап торды әле.

Атыбыз, таныш юлдан уңга борылып, болынга да килеп җитте. Бу безнең печән чабылачак Сафия аланы иде. Печәннең куе булачагына куанган дәү әтием, зур-зур адымнар белән атлап, аланны аркылыга-буйга иңләп чыкты. Күк йөзе чалт аяз. Күзгә күренмәс биеклектә тургай сайрый. Кинәт кайдадыр самолет гүләгән тавыш ишетелде. Аны эзләп як-якка карангалап торганда, баш өстеннән очып та үтте. Куркыныч булып китте. Никтер ул мин кинода күргән самолетны хәтерләтте. Бу самолет та кара төстә, җитмәсә.

Дәү әтиемнең йомшак кына итеп:

– Әйдә әле, бахбай, атлый төш, өстеңә кигәвен урынына самолет куна бит! – дигән тавышын ишеткәч, айнып киткәндәй булдым.

Кичен йокыга китә алмыйча азапландым. Әллә каян кара самолет килеп чыгар да минем өскә төшәр кебек.

Иртән бал корты безелдәгән тавышка уянып китеп, сикереп үк тордым. Ачык калган форточкадан кергән икән. Әллә бүлмәдәге чәчәкләрне күреп, бал җыярга уйладымы икән? Тиз генә сикереп тордым да ишегалдына йөгереп чыктым. Борыныма тәмле төтен исе килеп бәрелде. Дәү әтием белән дәү әнием, умарта өстенә иелеп, үзара мыдыр-мыдыр нидер сөйләшә. Менә бер ояны, икенчесен, өченчесен ачтылар. Аннан кабат беренче ояга килделәр. Аларның үз-үзләрен тотышыннан нидер булганын аңлап алдым. Келәт почмагына элеп куйган битлекне алып, мин дә алар янына киттем. Мине күргәч, дәү әтием ояга ишарәләп күрсәтте дә:

– Әй улым, улым! Бу оҗмах кортларына да көн бетте... Нинди тырыш, уңган бит алар! Балны бирәү дә бал корты сыман ясый алмый бит, югыйсә. Болай да аларның гомере бик кыска, нибары бер сезон. Шуларны кырларга агу сибеп агуламасалар соң... – дип куйды. Көч-хәл белән аякларын селкетеп, кире аркан яткан бал кортларын күргәч, йөрәгем жу-у итеп китте. Мескенем, кояш белән торып, ул да болынга очкандыр, бүксәсен тутырып чәчәк балы алып кайтырга ниятләгәндер... Әй, самолет, килмә син безнең як кырларына-тугайларына! Сипмә син җиһанга үлем агуын!

Чәчәк таҗларына чык тулган. Мин генә түгел, дәү әтием белән дәү әнием дә, хәтта бал кортлары кунар чәчәкләр дә тавышсыз-тынсыз гына елый иде.

**Ленар Шәех,**
*шагыйрь, филология фәннәре кандидаты*

# ЯКУТ КИҢЛЕКЛӘРЕ ЯҢГЫРАШЫ

Татарстан китап нәшрияты төрки халыклар арасындагы бәйләнешләрне ныгыту буенча нәтиҗәле һәм дәвамлы эш алып бара. Шул максаттан, 2015 елда махсус «Төрки әдәбият» сериясе оештырылды. Беренче булып Кыргызстан Республикасының халык шагыйре, прозаик, тәрҗемәче, күренекле җәмәгать эшлеклесе Омор Солтановның «Йолдызлы төннәр» җыентыгы басылды. Бу китап шагыйрьнең Бишкәк шәһәрендә узган 80 яшьлек юбилеенда, тантаналы төстә Омор агага тапшырылды.
Ниһаять, икенче китап табадан төште. Ул «Күзге яңгырлар» дип атала һәм Саха (Якутия) Республикасының халык шагыйре, прозаик, публицист Наталья Харлампьева шигырьләрен үз эченә ала.




*Наталья Харлампьева һәм Ленар Шәех «АЛРОСА» алмаз чыгару компаниясенең штаб-фатирында. Саха (Якутия) Республикасының Мирный шәһәре. 22 октябрь, 2015*

Наталья ханым – тулаем иҗади шәхес кенә түгел, ә җәмәгать эшлеклесе дә: Якутия Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Республика Башлыгының мәдәният мәсьәләләре буенча киңәшчесе.

Бүгенге көндә ул – егермедән артык шигырь, проза һәм публицистика китаплары авторы. Шигырьләре урыс, казакъ, татар, украин, инглиз телләренә тәрҗемә ителгән. 2016 елда аның якут һәм инглиз телләрендәге «Азия Ана» китабы Лондонда дөнья күрде.

Тәнкыйтьчеләр билгеләвенчә, ул, шагыйрь буларак, мәхәббәт һәм гражданлык лирикаларында көчле. Якут әдәбиятына кечкенә поэма

жанрын кертүче буларак та санала. Минемчә, Наталья Харлампьева шигырьләрендә, беренче чиратта, милли рух өстенлек итә. Ул үзенең халкы, төркилеге белән горурлана:

*Мин – көчле хатын-кыз.*
*Мин – якут.*
*Яшимен елмаеп һәм балкып.*
*(«Мин – көчле хатын-кыз...»)*

Кызына багышланган «Туган телем» шигырендә телләр белүнең өстенлеге күрсәтелсә дә, күңелдәге иң нечкә хисне, иң тирән тойгыны бары ана теле генә бирә алачагы көн кебек ачык:

*...Сагышыңны, милли тойгыңны да,*
*Җан түреңнән аккан моңыңны да*
*Син якутча, тик якутча җиткер!* –

ди ул.

«Әнием истәлегенә», «Оныкка багышлау» шигырьләрендә үткәндә калган бәхетле мизгелләрне сагыну белән янәшә киләчәккә алып барган өмет ачык чагыла. Ана, шул ук вакытта әби кешенең бу дөньядан китүе, лирик геройның тулаем шушы вазифага керешүе, ягъни, әни булудан тыш, дәү әнигә дә әйләнүе гомернең узуын, буыннар алмашуын һәм моның өзлексез, туктаусыз агыш-үзгәреш булуын күрсәтә.

*Гомер – елга,*
*Бөек елга.*
*Гасыр арты*
*Гасырларны*
*Үз артыннан*
*Алып китә,*

– дип яза шагыйрә «Гомер – елга...» шигырендә.

Күләмле «Азия Ана» һәм «Борынгы төрки хатын-кызлар турында триптих», шулай ук «Гоби даласында төш» әсәрләрендә тирәндә күмелеп калган тамырларга кагылу, аннан яшәүгә, «саха» дигән халыкны яшәтүгә көч алу, әби-баба рухыннан сабырлык, акыл сорау күренеше укучыны да үз асылы турында уйланырга этәрә. Чыннан да, кискен глобальләшү шартларында без милли йөзебезне саклый алабызмы? Кемнәр без? Нинди максат белән бу җирдә яшибез?

Наталья Харлампьева халык һәм табигать, кеше һәм әйләнә-тирә мохит бергәлеген, шул нигезгә корылган гореф-гадәтләрнең буыннан-буынга күчеп килүен дә искәртә. Ни өчен борынгы йолалар онытыла? Чөнки ике арадагы җанлы элемтә югала. Табигать һәм кеше якынлыгын ул болай күрсәтә:

*Күренмәс, тере*
*Бәйләнеш белән*
*Алар бәйләнгән –*
*Көч һәм эш белән.*
*(«Каты салкыннан...»)*

Табигать шагыйрәнең күңел, мәхәббәт лирикаларында да киң урын били.

*Минем юлдашым – яңгыр,*
*Минем дустым – сары көз...*
*Тирә-якта – бары көз...*
*(«Якты дөньяда – яңгыр...»)*

*Минем алда – кара моңсу урман.*
*Буран дулый. Караңгы төн. Айсыз.*
*(«Әйтерсең лә безнең йөрәкләргә...»)*

Шагыйрәнең һәрчак яктылыкка, яхшылыкка омтылуы, яманлыкны, явызлыкны кире кагуы, әлеге тискәре көчләргә каршы көрәшүе аның күңел сафлыгын, ихласлыгын, ихтыяры нык булуын, барыр юлының турылыгын күрсәтә.

*Төннәрен дә, көннәрен дә*
*Кулымда каләм нык*ка,
*Үзгәрми ышаначакмын*
*Гаделлек, яхшылыкка,*

– дип яза ул.

Һәр каләм иясенең иҗади кыйбласы булырлык хак сүзләр бу!..

Әлеге китапны укып, татар укучысы тагын бер яңа шагыйрь ачар, күптән онытылган төрки тамырларын тояр, хис-кичерешләрен алыс* якта урнашкан киң якут киңлекләре кимәлендә яңартыр, дип ышанып калам!




* Алыс (гомумтөрки сүз) – ерак.



# Наталья Харламьева

## БЕР ҖЫР БУЛЫП, ЮЛЫҢ ДӘВАМ ИТӘР, ТУГАН ТЕЛЕҢ КИЛӘЧӘККӘ КИТӘР…

### КӨЗГЕ ЯҢГЫРЛАР

Кай тарафка карасаң да,
Офыкны каплап алган –
Нигәдер, көзге яңгырлар
Бу елда соңга калган.

Шыпырт кына килде алар,
Җылытып суык җирне.
Әллә бу соңаруларда
Бер ният бармы, серме?

Яңгырлар килде еректан,
Җилләргә куна-куна.
Туган җирем туңып куйды,
Бәхетле булып кына.

Тәрәз төбемдә ишетәм
Тып-тып яңгыр тамганын,
Кышка калган уҗымнарның
Уй-йокыга талганын.

Алда суыклар көтелә,
Иңнәрен бөгә урман.
Көзге яңгыр моңнарында
Җир ябына ак юрган.

### ЧҮЛДӘГЕ ЮЛ

Елга юллары кипкән,
Чиксез сагыш – офыкта.
Ничәнче гасыр инде
Җилләр уйный комлыкта.

Ком тузаны эченнән
Бернәрсә дә күренми.
Ә җаным яңгыр булып
Коеп яварга тели.

Чүлнең кайгылы рухы
Еландай шуып кача.
Күңелем елга булып
Аксын иде, ичмаса.

Чүл рухын аңлый алмыйм,
Кумыйм да комнар аша.
Ул тантана итә дә
Аннары ыңгыраша.

Казакъ дус элеккечә
Тарта моңлы кубызын.
Күз алдымда – сары чүл,
Ә барыр юлым озын.

* * *

Якты дөньяда – яңгыр.
Пекинда да, Питерда да,
Якутскта да ул бер.
Яңгыр җиргә җәелә,
Җиңел кульяулык булып,
Юеш учлары белән
Сөяргә дип омтылып
Сукбайларны чәченнән...
Пәрдә шикелле яңгыр
Сибелә дә чәчелә...
Тирә-якта – сары көз,
Дөньясында – бары көз.
Ак томан, пыскак яңгыр –
Аңа һәр тарафта да,
Һәр җирдә урын бардыр...

Алтын яфраклар оча
Җәйге шатлык өстеннән,
Җәйге бәхет өстеннән... –
Ни калды җәйге көннән?..

Минем юлдашым – яңгыр,
Минем дустым – сары көз...
Тирә-якта – бары көз...

* * *

Мин – көчле хатын-кыз. Мин – якут.
Яшимен елмаеп һәм балкып.
Берәү дә кулымнан алмады,
Чанама тәүге юл салмады.
Берәү дә таягын бирмәде,
Ярдәмен күтәреп килмәде.
Аллага шөкер, дим, әле дә
Калганмын мин шушы хәлемдә.

Тырыштым, ихтыяр белдердем,
Үземнең атымда җилдердем.
Өлешкә тигәнне сайладым,
Иҗатта яшәдем, кайнадым.
«Бөеклек» чире дә йокмады –
Кыргый хис тамырда туктады.

Әйе, мин – беркатлы, самими.
Кешеләр: «Син үтә гади, – ди, –
Илһамлы акылың астарак,
Чәчеңнән дә хәтта кыскарак...»

Әйе, мин – гап-гади бер якут.
Яшимен елмаеп һәм балкып.
Барысын ишетәм дә күрәм,
Җаныма кояштан нур үрәм.
Ә болай яшәве рәхәт тә,
Куркыныч та кебек, әлбәттә:
Мең үлеп, мең кабат терелеп...
Һәм тыштан таш кебек күренеп...

* * *

Син мине дәшмәскә өйрәттең,
Язылган сүзләрне күрмәскә;
Күңелсез халәтне яшереп,
Табигый ярсуга
Күңелне бирмәскә.

Син мине сак сөю кулында
Коточкыч упкынга терәттең.
Өметсез,
          имансыз,
                    канатсыз,
Бәхетсез бичара
Булырга өйрәттең.

* * *

Каты салкыннан
Агач сынганда,
Буран бүредәй
Котырынганда,
Аннары чиллә
Җан куырганда –
Тилгән шикелле
Өстә торганда;
Күзгә җил җанга
Боз каплаганда,
Суык яңгырлар
Канатланганда,
Борынгы бабам
Монда көн иткән.
Күп кирәкмәгән –
Булганы җиткән.
Ә явыз көчләр,
Серле көй көйләп,
Аны дугадай
Бөгәргә теләп,
Үзсүзлеләнеп
Бөтерелгәннәр –
Бер юк булганнар,
Бер терелгәннәр.
Ә якут бабам
Бар дип белмәгән,
Кыланышларын
Бер дә күрмәгән.
Табигать-Ана
Аңа дус булган,
Юраганнары
Һәрчак юш булган.
Күренмәс, тере
Бәйләнеш белән
Алар бәйләнгән –
Көч һәм эш белән.

## ТУГАН ТЕЛЕМ

*Кызыма*

Тормышыңда яңа очрашулар
Булсын дисәң, чит телләрне өйрән.
Пушкин теле, бөек Шекспир теле –
Иксез-чиксез, колач җитмәс тирән.
Ләкин күңелдәгеn, үзеңнекен
Бары туган телең җиткерәчәк.
Ул – бердәнбер.
Сине анаң кебек,
Якын итеп, сөеп, үз күрәчәк.

Шуңа
Йөрәктәге серле хисеңне дә,
Бәхет тулы айлы кичеңне дә,
Мәхәббәтне, яшерен сөюне дә,
«Мин яратам сине!..» диюне дә,
Сагышыңны, милли тойгыңны да,
Җан түреңнән аккан моңыңны да
Син якутча, тик якутча җиткер!
Туган телгә нокта куелмаган.
Тел, нәселдән килгән әманәттәй,
Сиңа кадәр җиткән – җуелмаган.

Анда гел табигатьтәге кебек:
Урман шаулый, ага елга-сулар...
Кайгылардан саклар туган телең,
Авыр чакта ярдәм кулын сузар.
Бер җыр булып, юлың дәвам итәр,
Туган телең киләчәккә китәр...

* * *

Аңлый алмыйм, нигә төшкә керә:
Яшел хәтфә кебек үләндә
Урман эчендәге алтын бия
Колыны белән йөри үзәндә.

Кояш төсендә ул, җиңел, нечкә,
Йә уйный да җан-фәрманга җилә,
Йә колыны җиленәнә килә,
Колакларын сагайта бу бия.

Гаепледәй, һаман искә алам,
Бу төш җанга мәллә камыт үргән?
Гүя бермәл кеше бәхетен мин,
Качып кына, чынбарлыкта күргән.

*Якутчадан Ленар Шәех тәрҗемәләре*

Нәбирә Гыйматдинова

# КЕМ БЕРЕНЧЕ?

*Бәян*

-1-

Латыйф төркемнән аерылып читкәрәк китте. Чү, нинди галәмәт бу?! Кемдер нәкъ зират уртасында «шедевр» бастырган: бронза сын шундый зур һәм биек ки, ул хәтта кояшның үзен каплап тора кебек иде. Кызык, туганнар каберлеге микәнни? Һа, нинди «туганнар» ди! Башкисәрләр шулай кылана: алар үлгәч тә дөньяны колачлап ятмакчы була.

Халык берәм-берәм таралса да, ир кузгалмады, чекерәя-чекерәя «һәйкәл»не тикшерде. Килбәтсез адәм сурәте кайсыдыр ягы белән аңа таныш иде. Киң маңгай, очлы ияк, кабартма бит аңа берәүне хәтерләтте.

– Дамир! – Латыйф капка ябып маташкан егеткә кул изәде. – Кил әле, энем, кил!

– Шөкер, җыештырдык, – диде Дамир, тирләгән маңгаен сөртеп. – Артыннан илереп еламыйлар. Малае белән әллә ни аралашмаган. Картлыктан дару уйлап тапсалар икән! Йөз ел яшәр иде, бәлкем.

– Тәмам фәйләсуфка әйләндең, энем. Йә, ни хәлләрдә син? Сакчы вазифасы килеште, тәнеңә ит кунды.

– Үртәмә инде, Латыйф абый! Шушы җир асты патшалыгының директоры без.

– Аның сакчыдан кай җире ким, энем. Үстең, хәйран үстең. Кайчан гына син йолкыш малайны сәләмәдән аралап юындырдым, киендердем, ашаттым. Тик син, эреләнеп, абзаңны оныттың, энем!

– Онытмадым, Латыйф абый! Сез гел истә.

– Ярар, мин болай гына. Үпкәләп түгел. Булышчыларың кайда? Түрә башың белән капка япмасаң ни!

– Зират яңа гына ачылды. Оешып кына киләбез. Кабер казырга бер үзбәкне яллыйм пока. Моның чын хуҗасын күргән юк. Хәзер бит алар ачыктан-ачык эш йөртми, ярдәмче-фәләннәр аша гына идарә итә. Салым түләмәс өчен ахрысы. Билгесез түрәнең ялчысы ни ди, монда иманлы кешеләр генә җирләнергә тиеш, ди. – Дамир бүлтәйгән корсагын сыпырды. – Эш күп, ун көндә биш килога ябыктым.

– Иманлы кеше дисеңме, энем? Әнә-ә, теге «һәйкәл» кырына да шундый бәндә күмелдеме?

Баягы кызыксыну һаман кимемәгән иде.

– Андамы? Буш әле ул, Латыйф абый. Чирме икән инде, мода микән, бүген «калын кесәлеләр» үзләре исән чакта ук зиратта җир сатып ала. Байлар нәрсә генә кыландырмый! Менә бу агаебыз барысын да шаккатырмакчы бугай, миллионнарга төшереп сурәтен койдырган. Кран белән көчкә илалла урнаштырдылар. Берәүсе көлә, брат, ди, башына карга кәкәй итсә – сөртерсең, ди. Түләсәләр, сабынлап юарбыз, мәйтәм.

– Исеме кем?

– Документлар буенча – Сәлимов.

– Кем, кем?!

– Себер бае, ди. Быел Казанга күченеп кайткан, ди.

Латыйф «һәйкәл»гә табан ыргылды. Ул якынлашкан саен сын тагын да зурая гына бара иде. Ир тынга капты. Әгәр янәшәсеннән йөгергән Дамир беләгеннән тотып өлгермәсә, «Сәлимов»ның очлы тимер түфлиенә абынып, маңгаен тишә иде.

– Уф, Ислемай, миннән уздырмакчы булдыңмы?

– Танышыгыз мәллә, Латыйф абый?

– Танышым. – Ир тешен шыгырдатты. – Кайчан үлә, ди?

– Кем, Латыйф абый?

– Сәлимов дим!

– Алла белсен! Үлсә, сезгә белгертәм, ант мәгәр. Рас яхшы танышыгыз икән.

– Ә нишләп һәйкәл турында миңа әйтмәдең, куян колагы?!

– Бәй, зираттагы һәр яңалыкны сезгә җиткерергә мени? Ул сезгә ни хаҗәтемә соң, Латыйф абый?

– Бүген иртән шылтыраттың бит әле!

– Малае үтенде. Сез аның этисе белән бергә эшләгәнсез икән.

— Насыйров миндә сатучы иде. Күп урлады, ата карак иде. Яңа зиратка ничек эләкте ул, ә?

— Улы Сөббух белән дуслар без, Латыйф абый. Аңарда акча бар.

Капкага юнәлгәндә Латыйфның авызыннан өч кенә сүз «очты»:

— Иртәгә гәпләшербез, энем!

«Һәйкәл» аны тимер йодрыгы белән аркасына төя-төя озатты кебек. Тормыш ул — ярыш, кем билгеләнгән сызыкка беренче килеп җитә, шул җиңүче санала. Моңарчы Латыйф беренчелекне бирмәде, көндәшен чакрым ераклыкта калдырып, алга үрмәләде. Әйе, үрмәләде, чөнки җиңәм дип яшәүләре авыр, көн-төн көрәшә-көрәшә йөрәк ите ашала иде. Менә сиңа мә! «Мин — беренче» дип, тантана итеп гомер көзенә якынлашканда гына Ислемай кушаматлы Ислай Сәлимов финишка атылсын әле! Нинди хурлык! Латыйф та дөньяның бу ягын исәпләгән иде анысы... Көннәрдән бер көнне җир чираттагы кунагын «мәңгелек йорты»на кайтарып җибәрәчәк иде. Әмма ир Ислай сыман алдан ук ерак сәфәргә әзерләнмәде.

Эчтән бүртеп кабарындымыни, аңа әвен хәтле машинаның киң утыргычы тарайды. Утыргыч кынамы, бистә урамнарына хәтле кечерәйде. Ислай Сәлимов «һәйкәле» акылын тараган иде, ачуы җиһанга сыймаган ир турларында кукрайган «Ока»ны әз генә тибеп очырмады. Һай, шушы әрсез журналистлар, балга сырышкан чебен төсле, атна саен килә дә килә. Ә тимер капка, гадәттәгечә, бикләнмәгән: Керпе Газизҗан коттедж тирәсен җыештырганда аны тутырып ачып куя. Янәсе ишегалдын җилләтә. Агайның сәер гадәтләре хисапсыз иде: өченче ай инде йөзен сакал-мыек «бизәгән» бер хәерчене ашата. Хәер, монда алар Латыйфның анасы белән берләште: табында ни-нәрсә кала — карчык савытка тутыра да: «Мә, Алла колына илт», — ди. Хәерче дигәнең картны чатта гына көтә, өй янында уралмый. Хуш, тамагын туйдырсыннар, тик йортка гына ияләштермәсеннәр.

— Газҗан абзый! — Латыйф чәчәкләргә су сипкән картка кычкырды.

— Ни йомыш? — диде тегесе, ризасыз тавыш белән.

— Утын мунчасы якканмы?

— Ыһы, яккан. Иртән генә саунада юындың кана, хуҗа малай. Ике сәгатьтә бетләдең мәллә?

— Зираттан мин. Чайканам.

— Чайканасыңмы, юынасыңмы — ихтыярың тозлы кыяр. Шау-шау су түкмә, түлке. Атнакич Бибиҗамал апа арулана.

Әгәр хезмәтче кырлы-мырлы сөйләшсә, бер генә хуҗа да түзмәс иде. Латыйф та «түзми», эченнән генә Керпенең энәләрен «чүпли», әмма «җәза» шуның белән генә чикләнә, тыелып калуның сәбәбе — энисе иде. Үзсүзле, киребеткән мыжык Газизҗан карчыкка искиткеч зур юаныч иде. «Нигезем» дип авылын сагынып сыктаган анасы шушы Керпене, ни гаҗәп, яратты. Алар икесе ике туфракта яралса да, бер-берсе белән бик тиз уртак тел тапты. Сәгатьләр буе гәпләшә үзләре, ләкин сүзләре кимеми, иртәгә дә кала, һәм аннан соң да «тел чишмәсе» саекмый, төптән ургып ташый иде. Латыйф, кирәк икән, энисе хакына биш Газизҗан ялларга риза иде. Хәлбуки карт болай да биш кешене алмаштыра, ул эшкә батыр, кай арада себерә, кай арада үлән кыркый, кай арада мунчага ут элә, кышкы айларда исә һавадан ук учына чүплимени, ишегалдындагы мәйданга сыңар кар бөртеге дә кундыртмый иде. Ялгыз иде ул, бистәнең иң соңгы урамында бәләкәй генә иске агач өйдә яши, байлар төзегән «хан сарайлары» белән чагыштырганда аның ызбасы тавык кетәклеге хәтле генә иде. Бер комсызы, җиренә кызыгып, картны «кетәклегеннән» сөрмәкче булган иде дә, Латыйфның каты кулына эләкте. «Газҗан абзый, мин сиңа яңа торак салдырам, таштан», — дип озак үгетләде ир, әмма хезмәтче: «Монысы да минем гомеремә җитә», — диде.

Чәчәкләрне коендырган картны ул тиктомалдан гына тиргәп атты:

— Кисәтә-кисәтә арыдым, Газҗан абзый! Һич тыңламадың, ә! Киренең дә киресе син! Ничә раз «Калай консерва савыты»н капкага якын куйдырма дидем!

— Хи-хи, хуҗа малай. Әкәшкә машинасыннан хурланасыңмы? Латыйф әфәндебезнеке диярләр дисеңме? Синең ише кәттә халыкның аңа утырмаганы эткә дә мәгълүм. Бар, йөртүчесен орыш!

— Көн саен... чирәм таптап, — дип мыгырданды ир.

— Нәсел агачыгызны «киендерәләр» кана. Анда ничәмә ничә ботак та, ничәмә ничә япрак! Һәркайсында адәм исемен чәписе ди. Әнкәң, маладис, хәтере шәп! Җиде буынын саный.

Соңгы елларда халык шәҗәрә дип егылды. Латыйфның танышлары да ясатты аны, гаҗәп, берсенең дә төп-тамырында ярлы-ябагай юк, барысының да нәселе ханнарга яисә морзаларга барып тоташа. Ә риясыз әнисенең һаман авызны ерткан коры кашык: алар батрак кавеме. Бабалары байга бил бөккән икән... Кәҗә генә асраганнар икән...

Латыйф бүтән «Керпе»не әрләмәде.

— Әни кунак өендәме? — диде.

— Шунда, шунда, хуҗа малай.

Монда да дүрт тарафтан җил исә, ишек ябылмаган иде. Әнисенең тавышы көр, туксан яшьлек карчык димәссең дә, иренми, мавыктыргыч итеп сөйли.

— Мине кияүгә димләгән җегетнең текмә ызбасы янтайган ие, кызым, ярты тәрәзәсе пыяласыз, катыргы кадакланган ие. Кышкы төннәрдә ярыктан җил өрсә, чәчләр бозланып катыр ие. Озак мантымадык без, кызым.

Ул эчкә кермәде, кире борылды. Көрәк тотып кабер казымаса да, пакьләнергә кирәк иде. Кесәсеннән документларын бушаткач, киемнәрен идәнгә ташлады. Аларга теге «һәйкәл» исе сеңгән кебек иде. Юынып, чиста күлмәк-чалбар киеп өенә чыкканда хатыны аш бүлмәсендә каһвә эчә иде.

— Насыйровка ник барасы иттең соң, Латик, — диде хатын, бармагын ялый-ялый. — Уф, тырнагым сына! Кичә генә игәүләтеп буяткан идем. Кайчан пешекчегә тиендерәсең, Латик җаным? Насыйров әшнәң идеме?

— Синең ун соравыңа каршы бер генә сорау: миңа ашарга бирәсеңме?

— Поминкада сыйламадылармыни?

— Татарда андый гадәт юк! Пешекчене син кудың, хәзер үзең эзлә! Кстати, кунак өендә әниләргә чәй оештырдыңмы?

— Абау, баскычтан бер мен, бер төш. Аягым сызлый!

Хатын аның алдына табагы белән кыздырган бәрәңге этте. Ул тозсыз иде. Ир, суыткычтан кара уылдык белән май алып ипи телеменә сылады.

— Әнигә тавык итеннән шулпа пешер, Рәдифә. Токмач кисеп!

— Төшке ашны сезнең рестораннан гына китертәбез, Латик!

— Әнине уртак казаннан ашатма, диләр. Ул авыл карчыгы!

— Фи, шул авыл карчыгын күкләргә чөяләр, чистый. Ай саен гәзитләрдә аның яшьлек хатирәсе, ай саен! Бәлки туктатырсың, Латик?

— Туктатмыйм, — диде Латыйф. — Мин хәлле кеше, акчам кыштырдамаса, аны ике метрдан да танымаслар иде. Әнә, Гаҗҗән абзый хакында өч җөмлә сырламыйлар, чөнки тишек кесәсендә җил уйный. Ә бит аның бабасы Казан мәчетендә указлы мулла иде, ди. Мәдрәсәдә шәкертләр укыткан, ди. Әнигә кысылма, рәхәтләнеп үткән тормышын сөйләсен. Аның хатирәләре, Гаҗҗән абзыйдан гайре, икенче юаныч. Авыл дип кенә сыкранмасын.

— Дус-иштән оят, Латик! Сез — ярлылар токымыннан ич. Шәҗәрәгезне яңабаштан эшләт. Ерак бабагызны һич югы, алпавыт дип төзәттер.

— Ялган була ул, Рәдифә.

— Учларына күбрәк акча сонсаң, ялганнан да чынбарлык туа, Латик.

— Кит, саруымны кайнатма! — Ир авызындагы ризыгын йотар-йотмас урыныннан кузгалды. — Хан оныклары бүген урамда хәер теләнәдер, шәт. Миндә дә аксөякләр каны ага, дисең. Ник соң син, аучы, үз ишеңне ауламадың, ник хәерче оныгына ябыштың? Әле кеше аертып! Гаилә бозып!

Яшь хатынына болай ук каты бәрелми иде Латыйф. Зираттагы тамашадан соң, чын мәгәр, баш мие селкенгән иде. Ул өченче катка күтәрелде. Җылытылган зур террасада кышкы айларда да әкәмәт озын гөлләр үсә, аларның ботагы беләк калынлыгы, алар барысы да ят, бу туфракта тамырланмаган, ерак илләрдән кайтартылган иде. Исемнәрен атасаң — телең сынар. Әллә ниткән рипсалислар, адиантумнар. Әнисе дә, авыл төсе дип, балчык чүлмәккә яран гөл төрткән иде, бу әкәмәтләр зәхмәтле сулыш өрдемени, аны бик тиз каралтты. Үз итмәделәр! Табигатьтә дә көчленеке замана. Әмма беләктәге көч белән масаерга ярый микән? Чуерташ хәтле генә шартлаткыч бәр, мәгърур таулар да ишелә. Акыл белән хәйлә — иң зур көч. «Без кем!» — дип кукраешкан бу баһадир гөлләрнең дә, әнә, яфраклары шиңгән. Дымга тилмерәләр. Күр, туфраклары чатнап ярылган. Ялкау хатын су сибәргә иренә.

Латыйф ачык тәрәзәдән генә Газизҗанны чакырмакчы иде, туктап калды. Карт кунак өеннән аның әнисен җитәкләп чыгып килә иде. Димәк, шәҗәрә тәмам. Карчыкның башында

вак-вак чәчәкле яулык, өстендә балаитәкле күлмәк, аягында әлеге дә баягы тула оек белән кызыл эчле галуш. Латыйф аңа ниләр генә алмады: йомшак чүәк, чигүле итек, әмма әнисе: «Миңа үземнеке җайлы», — дип, һаман резин сөйрәде.

Артыннан Рәдифә дә менде. Латыйф бер гөлләргә, бер аңа күз ташлагач, шелтәләп:

— Ялкау, — диде.

Хатын:

— И, атна элек кенә сипкән идем лә! Бигрәк нәзберекләр инде, — дип акланмакчы иде, ир җимерелгән чыраен тагын да җимереп:

— Син бүген чәй эчтеңме? — диде.

— Рәхмәт, эчтем, Латик.

— Алайса шул җиткән!

— Нәрсә җиткән, Латик?

— Сыеклык дим, сыеклык! Атна буе авызыңа су капма хәзер!

Латыйф дөбер-шатыр аска төшеп китте. Ишегалды янындагы баскычта аягын салып маташкан әнисен җиңелчә генә култыклады:

— Башың әйләнеп егылма. Гаҗҗән абзый секунд эчендә кая эреде соң ул?

— Теге гәзиттәге балакайның үкә дигән нәмәстәкәен этешә. Кабынмый, ди. Улым, гаражыңда биш машина, шуның берсен бир шул балакайга, садака дип. Җәфаланмасын үкәсе белән.

— Әй, әни, әни! Бигрәк беркатлы җан син. Андый зур садака булмый. Миллиардер да базнат итми моңа. Берәр нәрсә җайларбыз анысы.

— Аллаһ бәндәнең күңелен тар кылса, ул энәсен дә жәлләр, мәгәр киң кылса — ул ярты дәүләтен дә өләшер. Атаңнаң атасы, ягъни синең бай бабаң Нотфулла утыз чакрымдагы Нарат Елгадан, улым. Авыл тулаем янгач, диләнкесеннән агач кистертеп крәстиәннәргә алтмыш йорт тергезә, тегермәнендә капчык-капчык он тарттыра, халык ачтан үлмәсен дип. Шушы юмартлыгы өчен Аллаһ аңа бишләтә түли: и уңа ул көздә иген, и уңа. Йөз олау белән көнен-төнен ташыйлар, амбар-келәтләр түбәсеннән тула.

Латыйф кисәк кенә карчыкны бүлдерде:

— Нинди бай, әни-и?! Син ахрысы киленең такмагын такмаклыйсың! Безгә мондый уйдырма кирәкми, безнең төп — хәерчеләр төбе! Ничек бар, шулай калсын, әни!

— Шаулама, улым. — Әнисе як-ягына каранды. — И Ходаем, янгылыш ычкындырдым. Сәвитнекеләр ишетмәде микән, улым?

— Әни, җүләрләнмә! Совет власте таркалганга биш былтыр. Син бүген капитализм чорында яшисең!

— Алай да шыпырт, улым. Ышан заманага, бүген алдын, иртәгә артын күрсәтә. Сәвитең тып итеп кайтып төшәр. Эрвәлүтсиә бабаңны аттырган әнә. Әбиең Әбзәлия өч яшьлек малае Гыйздулла белән безнең авылга качмаса, син дә тумас идең, улым.

Ир әнисе янәшәсенә чүгәләде.

— Әни, уян әле, уян! Син өнеңдә дә төшләнәсең!

— Аптыратма, үз акылымда мин, улым. Сүзем дә дөрес.

— Алайса нишләп безнең нәселдә батраклар гына дип алдыйсың, әни-и?!

— Монысы да лыпырдады, хәзергеләр берниемә ярамый, төкерек белән ябыштырып кына ясыйлар, элгәреләр чыдамрак ие. — Карчык таягы белән галушына төрткәләде.

— Чүплеккә бәрсен Гаҗҗән абзый. Әйт кенә, мин сиңа йөз пар сатып алам. Көн дә берсен ки, әни.

— И улым, әрбир исраф итәләрмени! Очына чүпрәк бөкләсәм, таманлана ул. Ни сөйләсәм дә — минем сүз, улым. Каенанам Әбзәлиянең васыяте шул ие, ярлы булып кыйланыгыз, төп-тамырларыгызны тирән яшерегез, иту сәвит җелегегезне суырыр, дияр ие. Әбиең, мәрхүмкәем, Нарат Елгасын күрергә тилмереп үлде. Кем дә тимәс ие инде үзенә. Кара халыкка каенатам иллә дә булышкан ла.

— Әти дә куркак куян идеме, әни?

— Атаңмы? Алар түбән очта, без югары очта торгач, аралашмадык. Мине этиеңә күршеләр димләде. Биш айдан елгага батты Гыйздуллам. Аның күкрәгендә куян йөрәкме, аюныкымы типкәнен кем белгән ди, улым.

— Алай икән... — диде Латыйф, күңелсез генә. — Мин соң, мин кемгә охшаган, әни?

— Син тач Нотфулла бабаңдыр, улым. Тырышып нинди дәүләт төзегәнсең.

Бу «дәүләт»нең зурлыгын үлчәгәндәй, карчык муенын әле уңга, әле сулга борды. Әмма иңе чакрым, буе чакрым биләмә һичничек тә аның күзенә сыеп бетми иде. Әрсезлек ярты бәхет, диләр. Заманында Казан белән чиктәш бистәдән иң шәп җирләрне эләктерде Латыйф. Аның пулатыннан ханнар көнләшерлек!

— Минем белән булашып, эшеңне онытма, улым.

— Утырыйк әле, әни.

Искитәрлек хәл, әнисе янында ул үзеннән-үзе тынычлана, гүя тылсымчы олпат ирне кечерәйтә дә, сихри сукмактан гына балачагына кайтарып җибәрә иде. Менә бит, хәтта ки зираттагы килбәтсез «сын» да каядыр югалды. Билгеле, кабат сураер ул, ләкин бу мизгелдә Латыйф аның турында уйламый. Әйтерсең карчык ябык кына гәүдәсе белән әлеге зәхмәттән ышыклый иде. Олыгая-олыгая бер хакыйкатькә төшенде ир: хатының, балаларың, туган-тумачаң, әшнәләрең синнән йөз чөергәндә, җир йөзендә берләнбер тугры җан — Анаң кала икән. Канатсыз фирештә икән ул. Рөхсәтсез-нисез колхоз атына атланып чапкан малайга ферма мөдире камчы белән селтәнгәндә әнисе аркасын куйган иде:

— Әүвәл миңа сук, Шакир! Мин гаепле, мин начар тәрбияләдем.

Шук-шаян Латыйф әзме елатты аны, әзме! Ул түккән күз яшьләре өчен түлим дисәң — дөнья малы да җитмәс иде. Малай ант итте, әни, үсим генә, мин сине җәннәттә яшәтәм, диде.

— Эссе, өйгә керик, әни!

— Керербез, улым. Биш машинаңда да уптым чапмыйсың ла.

— Син тагы берсен бүләк ит дисең инде. Карарбыз, әни, карарбыз, яме?

— И энәсеннән җебенә хәтле сораштыра балакай. Мактый, матур сөйлисең, әби, ди.

Болар буыны — хәйләсез буын, минем тирәмдә күбрәк үз файдалары өчен бөтереләләр дип уйламый. Латыйфның да әнисе кебек беркатлы буласы, сабый бала сыман итәгенә башын куясы килде. Һай, күңел төпкелендә кимсетелгән-кагылган малай үрсәләнә! Оял, Латыйф, ир башың белән җебемә инде!

— Әни, Ислайны хәтерлисеңме? Кушаматы Ислемай иде.

— Заһидулла төпчегенме? Хәтерләмәскә ни! Сез ике кием бер чабата идегез, улым.

Теге малай тәки сине җиңеп, зар түгә, ә Латыйф! Тәки аны тыймыйсың!

— Әни-и, мин сине елатырлык кына этлек эшләсәм, Ислай карт-корыга ләгънәт укырлык зыян салды. Аның һәр эшәке гамәлен авыл миннән күрде. Ислемай, хәйләкәр төлке, үз карасын гел миңа якты бит! Бәнахакка тукмалдым мин, әни-и!

— Беләм, улым...

Ирне, гүя берьюлы йөзләгән корт чакты.

— Ничек беләсең?!

— Заһидулла төпчеге һәр кырын эшен сиңа сылтады шул, улым.

— Соң инде, соң... — Латыйф әле һаман сабый өммәтендә иде. — Нишләп соң мине яклап буран дулатмадың, әни-и?

— Бибиҗамал бала-чага өчен талаша дисеннәрмени? Кеше көлдереп теге. Ил-көндә булмаганны теге, әстәгъфирулла. Яшьтән кыйналганга күрә нык та син, улым. Әнә нинди дәүләт иясе үзең. Тау хәтле мал-мөлкәтең, Нотфулла бабаңнан кайсы җирең ким?

— Ә-ә-әй, — дип сузды ир. — Бигрәк мәрхәмәтсез заманда үстек без. Гел гаепсезгә тотып ярдылар. Укытучылар да усал иде, «надан, сарык бәрәне» дия-дия, башны тактага бәрә-бәрә укыттылар. Кулларында уклау кадәр указка, дәрестә әз генә кыймылдасаң да, шап сыртыңа! Өйгә елап кайтсаң, тагын берне өстиләр. Бүген балаларга тырнак очы белән дә чиертергә ярамый, өстеңнән жалу сырлыйлар.

— Авылга рәнҗемә, улым. Элгәрене җилгә элеп киптер, ди борынгылар. Ислай дустың белән күрешкәлисезме?

— Күрешәбез. Әле иртән генә зиратта очраштык, — диде Латыйф, «елак малай»дан көчкә аерынып.

— Нәрсә ди, улым?

— Дәшми, тик акаеп тора.

— Син аны кичер инде, улым. Берүк дус яшәгез.

— Киңәшеңә рәхмәт, әни. Әйдә, эсседән ми пешә. — Латыйф карчыкны бүлмәсенә озатты. — Хәл җый, әни. Хәзер киленең җимеш суы эчертер. Рәдифә!

Йорт бик зур, тавыш урмандагы кебек хәтәр яңгырый иде.

— Янамы әллә? Ял итәргә ятам гына, син акырасың! — дип, гәүдәсен или-или, залдан яшь хатын чыкты.

-2-

«Бер үк дус яшәгез...» Яшәмәгән кая. Башлангыч сыйныфта ук аларга «Агылый»

белән «Тагылый» дигән кушамат тактылар. Укулары да бер чама иде: икесенең дә көндәлеге «берле»ләр белән чуарланды. Укытучы Нәҗибә апа, җенләнеп:

— Шушы аңгыралар киләчәктә безнең өстән нәчәлник булыр, — дип әле Латыйфның, әле Ислайның колагын борган иде. Дусты үчле иде, Нәҗибә апаның урындыгына нәзек кадаклар какты. Ул «а-а-а» дип сөрән салгач, директор йөгереп керде. Гаепле кешене бик тиз «ачыкладылар», бу — Латыйф иде. Директор аны кичкә кадәр кабинетында — почмакта бастырып тотты. Югыйсә малай: «Мин түгел!» — дип сәгать буе шыңшыды. Иртәгәсен дуслар әүмәкләшә-әүмәкләшә сугышты, тик берсе дә җиңмәде, көчләр тигез иде. Латыйф озак үпкәләмәде, буа ташып, анда үрчеткән балык Сөлчә елгасына аккач, кармагын күтәреп, Ислайларга чапты. Беренче ярыш дәрте яр буенда уянды: кем күбрәк кызылканат каптыра? Латыйфның кечкенә чиләге тула язган иде инде, көнләшүеннән шартлаган Ислай аны суга болгап атты. Монысын да кичерде малай. Бала чакта кинә сакламыйсың икән ул. Буй тарткач кына икесендә ике төрле холык икәнлеге беленә башлады. Күмәк хуҗалык рәисе һәр йортка печән җире бүлде, үсмер Латыйф шуны өч көндә кыркымыш тай ясады. Ә Ибрай калышты һәм гарьлегеннән дустының аягына чалгы белән кадады. Яра чиләнеп озак төзәлмәде.

Беркөнне Ислай мескен генә тавыш белән:

— Әти кәҗәне базарга илтеп сат, ди. Миңа иптәшкә бар әле, Агылый, — диде.

— Мин бәрәңге сабагы урам бит, Тагылый.

Дустының күзеннән яшь бөртеге сытылды:

— Әти чирләде, бүлнискә салмасалар, үлә, ди. Юлга акча кирәк, күп акча. Үзем генә кәҗәне өч чакрым ничек аппарам инде, и-и…

Жәлләде Латыйф, ярар, диде. Төш вакытында бер көтү кәҗә тал ышыгында ял итеп ята иде.

— Әнә, безнеке! — дип Ислай таза гына сөтлебикәгә ташланды. Яшьтиләр аның мөгезенә бау чорнадылар. Тау да җиңел генә этелер, мәхлук хайван исә аягын терәсә, һич кузгатырлык түгел, Ислай көчәнә-көчәнә баудан өстерәде, арттан Латыйф куалады. Яна-пешә күрше авыл базарына җиттеләр. Өлгер халык иртән үк урын җайлап урнашкан, кайсы мактый-мактый тозлы кәбестә, кайсы коймак сата, ә каз-үрдәк, сарык-бәрән кебек эреле-ваклы «тере тауар»ны иң кырыйга — юл буена тезгәннәр иде. Малайлар әлсерәгән кәҗәне буш казыкка бәйләде.

Ислайның күзе терекөмеш кебек базар тирәли «йөгерде»:

— У-у, монда сәүдә шәп гөрли, иеме? Карале, Агылый, бу авылда безнең карендәшләр яши. Алардан кабарга берәр нәрсә теләнәсе иде. Кәҗәкәйдән тиз генә котылмасак, ачтан үләбез, иеме?

Корсакта унлаган бүре улый иде, Латыйф сөенеп:

— Сөтлебикәне дә аппарабызмы? — диде.

— Һи, тиле баш! Ул ниемә ди! Мин генә әлдертәм. Мине көтмә, сорасалар — сат! Бәясе — алты тәңкә.

Хикмәт икән ул сату эше! Кәҗәне мөгезеннән алып тоягына хәтле тикшерәләр, чаярак әби-апалар хәтта ки җиленен дә капшап-капшап карый. Әмма берсе дә «алам» дип сикерми иде. Арыды малай, ичмасам Ислай да озаклады, моңарчы җитез аяк авылны өч кат урар иде. Шулай, өмет шартлап өзелгәндә генә алар янына әби белән бабай килеп басты.

— Ни атлы син, улым? — диде карт.

— Латыйф, — диде малай.

— Кайсы авылдан?

— Сөнчәледән.

— Кәҗәңә күпме сорыйсың, улым?

— Алты тәңкә, бабай.

— Безгә насыйбы шулдыр, атасы, — дип сүзгә карчык та кушылды. — Духтырлар сиңа кәҗә сөте эч, диләр, үпкәңә файдалы, диләр.

Латыйф тиярен учына йомарлаган гына иде, шунда ук «җир астыннан» Ислай «баш төртте».

— Уф, карендәшләрне тапмадым, адаштым, Агылый. Кая, бир акчаны!

Өч көннән авылның иң зәһәр хатыны Самирә Латыйфларга килеп керде. Малай келәт баскычында пычак кайрый иде. Самирә карчыга төсле әнисенә очып кунды да, теле белән «чукырга» кереште:

— Бибиҗамал, кемне азындырасың син?! Малаең зимагур синең! Кәкре кул, ата карак ул! Кәҗәмне урлап саткан бит, кәҗәмне!

— Ни сөйлисең, Самирә? — Әнисе агарды-күгәрде. — Акылыңдамы син, и Ходайгынам!

— Бик тә акылымда! Базар кодаларга барган идек, күршеләре Гыйләҗ бабайның карчыгы и

мактый, и мактый. Сөнчәледән кәҗә алдык, сөте тәмле дә, куе да, ди. Андук сизендем, багыйм әле, мәйтәм. Минем кәҗәм! Колагындагы киртләч тамгасы да шул ук, валлаһи!

— Ай, дөрес хәл түгел бу! — дип әнисе үз туксанын туксан иткәч, «усал карчыга» корбаны Латыйфның җилкәсенә «тырнагы»н батырды:

— Менә үзеннән сора, Бибиҗамал! Чатнатып мин — Латыйф, Сөнчәледән, дигән!

— Улым, хакмы, нахакмы? — Әнисенең тавышы зәгыйфь һәм мескен иде. — Әйт, улым?

— Әйт, угры, әйт! — Самирә малайны ябык җилкәсеннән дырылдатты. — Хәзер икесенең берсе: йә төрмәгә яптырам, йә тиененә кадәр акчамны кайтарасың!

— Ислай бит... у-ул... безз-неке, диде. — Латыйф тотлыкты. — Ак...ча да аңарда.

— Вәт җирбит! Әле туганымның малаен буклый! — дип өстендә кагынган «карчыга»дан әнисе аны йолып алды да:

— Әйдәгез, әйдә! — диде.

Өчәүләшеп тыкрыктан гына Заһидулла абзыйларга киттеләр. Латыйф шаккатты: үләргә җыенган йорт хуҗасы исән-сау, ат җигә иде.

Әнчек төсле ләң-ләң өргән Самирәгә ул, усал гына:

— Авызыңны япсана! Ни эш, Бибиҗамал? — диде.

— Гайбәт куып йөрүләре уңайсыз инде, Заһидулла абзый. Самирә ни ди... Улыңнан кәҗәмне урлап саттыргансың, ди. Ислай шаярган ахры, Заһидулла абзый.

— Әй, син! — Ата кеше чыбыркы сабы белән генә тәрәзәгә шыкылдатты. — Чык!

Латыйфның күкрәгенә укмашкан авыр таш уалды: ниһаять ул иркен сулады. Менә хәзер Тагылый үзенең гаебен танып, аны зур бәладән коткарыр. Әлбәттә, алдакчы дусты җәзасын да татыр. Атасының кулындагы чыбыркы, әнә, елан кебек сызгыра.

Ислай чыкты, ишегалдындагы халыкка елмаеп:

— Саумысыз?! — диде. Исәнләшә, әдәпле янәсе.

— Без әлегә сау, пычык борын, сау! Өченче көн Латыйф белән базарда болгандыгызмы, йа?

Малай исенә төшерергә тырышкандай, колак артын кашыды.

— Ә-ә... Мин беркайда да болганмадым, эти. Сыер көтүе көтеп арыгач, кичтән үк печәнлеккә менгән идем, төшкә тиклем йокланылган. Әнинең лапаста сыер сауганын да ишетмәдем.

Мондый борылыш көтмәгән Латыйф җан ачысы белән кычкырды:

— Чеп-чи ялган! Без синең белән икәү базарга кәҗә аппардык! Кәҗә безнеке, булыш, дидең. Әти чирләде, дидең. Аннары үзең туганнарыңны эзләп киттең, безне калдырып!

— Син нәрсәдер буташтырасың, малай. — Заһидулла абзый кулындагы чыбыркысы белән Латыйфка селтәнгән кебек тоелды. — Буташтырасың, да-а. Ул авылда безнең чыбык очы туган да яшәми. Йә, хатыннар, мин печәнгә киттем.

Аналы-уллы өйгә кадәр сүзсез генә атладылар. Самирә урам ярды:

— Ыштубы кәҗә акчасын китерегез!

Тиктомалдан юешләнгән борынын лаш-лош суырган малай әнисенә күтәрелеп карарга курыкты. Хәзер ул мең кәррә: «Минем гаебем юк», — дип кабатласа да, аңа ышанмаслар иде. Шунысы гарьләндерде: хәйләкәр Ислай аркасында баштанаяк карак буявы белән буялды. Сабын белән юсаң да, бу кара агармаячак иде. Моңа бит әле бүтәннәре өстәлеп торды. Авылда нинди генә кыңгыр эш эшләнсә дә, тикшерми-нитми генә Латыйфка сылтадылар. Аңа кыенның төрлесе эләкте: атауда Карга Сираҗетдиннең ата казын суеп, көлдә күмеп пешергәннәр. Карга малайны урамда очратып, койма буендагы кычытканда аунатты. «Син генә сад-бакчадагы кыяр түтәлен чистарттың», — дип Колга Хөснетдин урак очырды. Мәгәр тисә, муены киселә иде.

Әнисе барыбер кәҗә акчасын илтеп бирде. Ир баланы да тетрәндерерлек моңсу күренеш бүген дә онытылмый: искә төшеп, әрнетә иде. Әнисенең зур бәйрәмнәрдә генә бәйләгән кәшәмир яулыгы белән шуңа төс күлмәге бар иде. Юклык вакыты иде шул! Алар сандыктан чыкты. Аларга «ияреп» кызыл эчле галуш та чыкты. Күзе яшьләнгән әнисе яулыкны кат-кат иснәде, кат-кат битенә куеп алды. Күлмәген күкрәгенә кысты. Аннары өчесен дә төреп, базарга китте. Соңыннан, хәлләнгәч, Латыйф аңа нинди генә асыл яулыклар кайтармады. Тик әнисенең берсенә дә күңеле ятмады.

— Элгәресе атаң бүләге иде, улым, — диде.

Ислай җәй буе дустыннан качып йөрде. Сагалады аны Латыйф, тотса, билләһи, кәҗә өчен «кәҗә мае»н сыгачак иде.

Август азагында Латыйфны мәктәпкә чакырдылар. Директор бүлмәсендә Ислай да утыра иде.

— Бер тычкак сыер бөтен көтүне буклый, ди. — Директорның сөйләм теле үтә дә «халыкчан» иде. Малайларга үтемлерәк булыр дигәндер, күрәсең. — Ә сез көтүдә икәү! Икәү! РОНО җыелышында йөзем кызарды, өлгереш буенча безнең мәктәп иң артта! Сезнең аркада!

Тартар — теленнән табар, ди. Латыйф үз башына мәктәп хуҗасын «төзәтте».

— Сабир, Илдар, Бәрис, Гаязлар бездән дә начаррак укый әле! Ник аларны орышмыйсыз, апа?

Апаның әллә ничә ачу кылы берьюлы чыңлап, колакны тондырды:

— Бәдретдинов, кәкре кул, чәпчемә! Син мәктәпкә генә түгел, авылга да бер бәла. Балиглык яшен генә уз, сине төрмә көтә!

Хәер, ярсыган директор тиз сүрелде һәм өстәлдәге кәгазьләрне әвеш-тәвеш китереп тынычлангач, кабат ягымлы укытучы роленә күчеп:

— Егетләр, исәнләштекме соң без, ә? — диде. — Мин сезне тиргәргә дип дәштермәдем, егетләр. Казанда сигезенче сыйныф тәмамлаган балаларны профессиональ училищега җыялар. Күп төрле һөнәрләргә өйрәтәләр анда. Өч тапкыр ашаталар, тулай торактан урын да бирәләр. Барасызмы димим, кистереп әйтәм: барыгыз! Чөнки мин сезне койрыкларыгыз белән «тугыз»га күчерттермим. Әйбәт характеристика язам. Монысы гарантия, егетләр!

Малайлар бер-берсенә караштылар. Директор сүзен тагын да куәтләп:

— Әти-әниләрегез белән үзем сөйләшәм, ризалашмый хәлләре юк, ике йортта да белемсез-нисез әрәмтамак асрамаслар, — диде. — Берсекөнгә мәктәп машинасы Чистайга тауарга китә. Аннан Казанга якын. Димәк, ярты билет бәясе безнең хисаптан диик.

Әнисе, билгеле, бу хәбәрдән урталай сыгылды. Канаты да ныгымаган бердәнбер сыңар кошчыгы оядан оча, и Ходайгынам!

— Улым, авылда да шөгыль муеннан. Мәктәптә укымасаң укыма, әйдә, җәмәгать көтүе көтәрсең, — дип, ана кеше Латыйфның киләчәген иңенә чыбыркы аскан килеш күрсә, малай киресенчә, үзен сыер-сарык тирәсеннән ераккарак җибәрде. Казан аның өчен хыял бишеге иде. Рәхмәт, директор апа, сез Латыйфтан түгел, Латыйф сездән котыла!

— Әни, — диде үсмер, — ниткән көтү? Сыеры аксаса да кеше мине гаепләячәк! Казанда миңа берсе дә йодрык ашатмас, әни!

— И бала, бала! Зур кала — зур урман, анда ач бүреләр мыжлапмы мыжлый. Тамагы тук, өсте — бөтен булыр ди директор, юмалый инде, юмалый. Мәптекләре дә кыл Казан уртасында, ди. Алай да безгә туган тиешле Кәшиф бабаңның әдрисен ал әле, улым.

Кәҗә маҗарасыннан айнымаган Латыйф машина әрҗәсендә дустының ияк төбенә берне ямаган иде, тегесе, беләктән умырып тешләде. Әрҗәдә икәү пыр тузып сугышты. Шофер Камалетдин кабинадан сүгенеп кычкыргач кына тындылар да, яңадан якага яка ябыштылар. Камалетдин түзмәде, Чистай башында сугыш чукмарларын куып төшерде. Вокзалга кадәр узыша-узыша йөгергәндә, һәркайсы «мин беренче булып билет кассасына басарга тиеш», — диде. Ярыш дәрте аеруча Ислайны җилкендерде бугай, ул вокзал мәйданында Латыйфны аяк чалып екты... Нәтиҗәдә, алар эткәләшкән-төрткәләшкән арада, Казан автобусы борын төбендә генә төтен бөркеп кузгалып та китте.

Җәй җылысы сүрелгән, август төненең салкыны сөякне туңдыра иде, авылдашлар, ничарадан бичара, урамда кара-каршы куелган сәләмә агач эскәмиядә кунарга мәҗбүр иде. Өшесәләр дә, йокланылган икән. Әүвәл Латыйф уянды. Таң беленә иде инде. Ислай борын сызгырта... Фью, фью... Йокысы тирән моның, дип уйлады Латыйф һәм әкрен генә аның җирдә аунаган сандалиенең берсен тактадан гына әтмәлләгән бәдрәфнең тишегенә илтеп салды. Ибрай торганда ул «изрәп йоклый» иде. Малай сул күзен кояш нуры сыярлык итеп кенә ачып, дустының ничек сыңар аяк киемен эзләвен әчке бер кинәнү белән карап ятты. Базарда аңардан кәҗә саттырган хәйләкәр төлке дә нәкъ менә шулай читтән генә күзәтеп көлгәндер.

— Әй, тор әле, тор, Латыйф! Һаман йокы бүсәсең, монда сандали юк! Уң аякныкы! Күрмәдеңме?

— Ник иртүк бимазалыйсың? — Латыйф сузылды-киерелде, янәсе ул әле генә уянып маташа иде.

— Сандали диләр сиңа! Юк, диләр!

— Нинди сандали, Ислай?

— Аяк савыты, аңгыра!

– Җеннәр яшермәде микән? Шундадыр әле.

Ислай түше белән әллә ничә тапкыр эскәмия астын «себерде». Әйтерсең сандали энә, иелеп кенә карасаң – күренми иде.

– Э-э… Беркайда да юк! Э-э… – Үсмер тузанлы кулы белән битен каплап үксергә тотынды. Еларсың да шул. Бүген, мөгаен, Ислай Сәлимов алмаш-тилмәш затлыдан-затлы ун-егерме пар туфли киядер, аларның барысы да чит илдә тегелгәндер, ә теге хәерче заманда, авыл баласы өчен гап-гади сандали да әкияттәге «алтын башмак»тан артык иде.

Латыйф башка аны кызганмады. Кәҗә мажарасы өчен бу әле аз, бик аз, аннан битәр, әнисенең рәешкә генә бәйләгән соңгы яулыгына тамган күз яше белән чагыштырганда, чүпнең дә чүбе генә иде ул. Ләкин моңарчы үз хәйләсеннән үзе шәбәргән, ялганлаган саен батырайган Ислайның капыл гына мәлҗерәп балавыз сыгуы бәгырьгә тиде. Латыйф сандалины барып алмакчы иде (аска ук батмагандыр, шәт), иртән үк вокзалга агылган халыкның күбесе кысталган кебек туп-туры бәдрәфкә чапканын күргәч, кире уйлады.

Хәерчегә җил каршы дигәндәй, җәлпәк борынлы иске автобус ватылып, кичкә табан гына шәһәргә килеп җиттеләр. Вахтер аларны ишек төбендә үк тоткарлады.

– Кая турыладыгыз, үскәннәрем?

– Безне шушы училищега укырга җибәрделәр, апа, – диде Латыйф.

– Кабул итү бүлмәсе ябык, эш сәгате тәмам, үскәннәрем. Иртәгә килегез, яме?

Ислай юри титаклап вахтер каршысына чыкты:

– Апа-а, безне урамда кыйнадылар. Минә аягымны имгәттеләр. Аяк шеште, сандали сыймый.

Мәрхәмәтле хатын:

– Әй, балалар, авылданмыни сез?! Сак булыгыз! Казан бандитларыннан рәхим-шәфкать көтмәгез. Кунарга урыныгыз бармы соң? – дигәч, Латыйф бистәдәге Кәшиф бабайның адресын күрсәтмәкче иде, Ислай тагын алдашты:

– Юк шул, апа җаным.

– Әй, балалар! Әти-әниләрегез сезнең өчен ут йотадыр, ичмасам берәрсе озатмаган да бит. Кайгырмагыз, урам чатындагы бишенче санлы тулай торак училищеныкы. Беренче катта минем кебек үк сакчы Вәлидә апагызны табарсыз. Аңа, Фирая апа берәр бүлмәдә төн кундырырга кушты, диярсез. Иртәгә завуч рөхсәт кәгазе бирер үзегезгә, законлы урнашырсыз, Алла боерса.

Әйбәт кенә төн кундылар. Документлар кабул итеп утырган марҗа хатын вахтер апалар кебек ягымлы түгел, дорфа гына бер кемсә иде, урысчасы каты-коты Ислай аның ни-нәрсә сөйләгәнен аңламый, шуңа күрә сүз саен:

– Нәмә ди бу түти? – дип, «бөек туган теле»ндә ипилек-тозлык сукалаган дустының беләген чеметте. Марҗаның хәбәре аяктан егарлык иде: төркемнәр тупланган, ә менә аш пешерүчеләр һәм тегүчеләр әзерләүче кызлар группасында укучыларга кытлык икән.

Дусларның авыз-борын салынды.

– Хурланмыйча аш пешерүчегә укыйбызмы соң, Агылый! Һөнәр, имеш!

– Шуңа бит мин марҗага, иртәгә хәтле уйлашыйк әле, дип документларны бирмәдем, Тагылый.

– Нәмә уйлыйсың монда? Безнең Казанда туган сыман бабай сыңары яши, Агылый. Адресы кесәдә.

– Синең базарлы авылда да яшиләр…

– Казанда точно, Агылый! Аның белән киңәшәм мин. Училище шушы гына микән? Башта синең туганнарың белән күрешик, аннары минекеләр белән, ярыймы? Без бит инде гел бергә йөрербез, ә Латыйф?

– Әйдәле, тулай торактан биштәрләрне алыйк, Ислай.

Биштәр дигәнең арыш капчыгыннан теккән «хәерче төенчеге» иде. Сораша-сораша Әмәт бистәсен эзләп барганда Латыйф колагын сагайтты: Ислай асфальтка үкчәсен бәреп атлый иде. Шык-шык, шык-шык… Шунда юлдашының аягына күз төште: дусты ак босоножки кигән иде.

– Ни бу, ә? – диде малай. – Ни бу?

– Сукыр мәллә син?! Аяк савыты.

– Хатын-кызныкы ла ул!

– Булмагае соң! Вахтер апаңның бүлмәсе ачык иде, кидем дә куйдым.

– Карак! – Латыйф букчасы белән Ислайның аркасын «кашыды». – Болай урлашсаң, иманыңны көярләр. Калада халык усал, ничту авылда.

Шөкер, Кәшиф бабайларның бистәсе биек-биек йортлар артына гына поскан иде. Хуҗа зур тагаракта шешәләр юа иде. Әлбәттә, ерак туганын танымады.

— Кем малае дисең? — дип, төпченә-төпченә генә хәтере уянып, Латыйфны кочаклап алды. — Мин авылдан киткәндә әнкәң Бибиҗамал тол иде, балакаем. Маладис, тәки ялгызы гына җегет солтаны үстергән икән.

Ислай ата каз кебек муенын сузып тагарак тирәсендә бөтерелә иде.

— Әй, картлач, сездә бер шешә ничә сум?

Бабайга исеме белән дә эндәшми, әдәпсез!

— Унике тиен, балалар, — диде аксакал, шөкер «картлач» сүзе өчен ачуланмады.

— Һи, сездә кыйбат икән. Безнең кибетче Нәкыя апа тугыз тиеннән генә җыя.

— Син кем малае соң әле, улым? — Хуҗа әрсез кунакны әле генә абайлаган кебек тоелды.

Ислай өчен Латыйф җавап бирде:

— Заһидулла абзый аның атасы, бабай.

— Төсе-бите белән каптыр Габдеригә охшаган шул. Бабасының иллә дә кулы кәкре иде, — диде Кәшиф карт, пышылдап кына. Аның йөзендә Ислайны өнәмәү билгесе күренде. Алга таба хәллләр тәгәрәп еларлык булды. Дусты капйот төсле табындагы ризыкны ашыга-ашыга авызына «озаткач», уф, тирләдем, ишегалдында җилләнәм, диде. Аның белән бергә хуҗаның өр-яңа читеге дә «җилләнгән», баскыч төбендә бавы өзелгән босоножкилар гына ауный иде.

— Ерак китмәгәндер, тотып измәсен изәм! — дип гайрәтләнгән үсмерне бабай тыйды:

— Кире кайтса да, урланган малның бәрәкәте юк, улым.

Бистәдә җиде тәүлек кунгач бабай сакалын сыпырып:

— Син, Бибиҗамал малае, Казанга нинди ният белән килдең инде? — диде.

— Укырга, Кәшиф бабай!

— Һе, укырга икән, бар, укы!

Латыйф дустын көтә иде. «Киләм» дигән кеше, әнә, суга батты. Мөгаен, калкымас та ул, ни йөзе белән картның күзенә күренсен, ди, карак!

— Ислай югалды бит, бабай. Туганнары кайсы урамда яши икән, әйтмәде дә ичмасам, — дип хәсрәтләнгән энекәшен Кәшиф карт өметләндереп:

— Казан — зур авыл, табарбыз, улым, — диде. — Аның Гаптери бабасы ягыннан карендәше Сафа үзәк Колхоз базарында чүп-чар җыештыра. Дустың аларда түгел микән? Сафа белән без атна саен күрешәбез, ул миңа бүтилкә малайлары караштырып куя. Белешермен, ярыймы, улым?

Базардан карт кәефсез генә кайтты.

— Кем әле теге малай? Ислай дисеңме? Әһе, шул Ислай атлы елгыр гүпчим дә югалмаган, тәккә хәсрәтләнәсең, улым. Бүтилкә белән дуслашкан дустың, шешә белән, әһе. Һәй, эчми инде, эчми! Бүтилкә җыеп, пунктка тапшыра ди. Моннан ары сиңа «җемелдәвекләр» артмас, энекәшкә бирәм, вчүтеки туган баласы бит, ди Сафа кордаш. Бирмәсә соң! Аннан гына бөлмәс, Кәшиф!

Бу хәбәрдән Латыйфның эче янды. Кара син, ә! «Гел бергә йөрербез, Агылый», имеш.

— Бабай, шешәдән ни табыш инде, — диде ул, үз-үзен юаткандай.

— Алай димә, улым. — Карт эчтәге ялкынны тагын да дөрләтте. — Тиеннән тәңкәләр үрчи. Пинсәмә әйбәт кенә өстәмә ул, Аллаһ рәхмәте. Син яшь әле, сабагыңа бар, вакыт әрәм итеп иптәшеңне юллама да, улым.

Нинди «сабак»?! Көнләшүеннән төн йокысы качкан үсмер бу хакта уйларга да теләмәде. Уку качмас, җәренгә керер… Ә анда хәтле акча эшләп аласы… Әнә бит, тиеннән тәңкәләр үрчи ди карт. Ислайның кесәсе сәмәннәр белән тулгандыр инде. Рас базардагы бабасы да булыша. Их сине, беркатлы Латыйф! Дустыңның хәйләкәр төлке икәнен оныттыңмыни, ә?!

Ул картка тагылды. Беренче көннәрдә «шешә уңышы» бик сыек булды. Кәшиф карт, аягым сызлый дип, ташбака тизлеге белән генә хәрәкәтләнә, шуңа күрә Латыйф кәсептәшеннән аерылып шәһәр үзәгенә китте һәм… уңды. Хуҗа аның капчыгына карап тел генә шартлатты. Чынлап та, тиеннәр өстәлә-өстәлә тәңкәгә әйләнә иде. Кулда кәгазь акча кыштырдаганда алтын тавы үзеннән-үзе өскә авар кебек иде. Әгәр ялкауланмаса, пыяла шешәләр үзләре аңа каршы йөгерәчәк. Әйе, шулай. Ул Ислайны узарга тиеш. Сүзсез генә игълан ителгән ярышта Латыйф җиңәчәк!

— Син — сабак баласы, укуга сүрелсәң — әнкәңә жалу язам, — дип куркыткан картны ул ант суы эчә-эчә ышандырды:

— Ант менә, икенче елга кил, диләр. Быел урын юк, диләр.

Бабай бүтән бәйләнмәде. Латыйф аның эчпошыргыч ялгыз тормыш тукымасында матур бизәк сыман чигелде. Ашау-эчү — уртак, кәсеп — уртак, кич белән һәркем акча саный.

— Үзәктә шешә мыжлаган, һәр чүп савытында өчәр-дүртәр. Анда кибетләр дә күп. Әйдә, минем белән Кәшиф бабай, — дигәч, карт:

— Рәхмәт, улым, — диде. — Син яшь тай. Мин карт алаша. Үзең генә юырт инде син.

Көнәнә бишәр тапкыр пунктка табышын илткән үсмер пычрак шешәләрне Казансу елгасында чайкый иде, берсендә арттан гына аның башына суктылар. Ул йөзтүбән егылды, ләкин аңын җуймады, борылып, кем һөҗүм иткәнен дә күреп өлгерде. Ислай! Куып кына тотар иде, түбәсеннән типкән «кан чишмәсе» муенына акты. Балыкчылар «ашыгыч ярдәм» чакырмаса, моның ахыры, мөгаен, фаҗига белән тәмамланыр иде.

— Синдә тимер баш икән, — диде табиб. — Шампан шешәсе белән сыйлаганнар үзеңне. Пыяла кисәкләрен чүпләдем. Миең селкенмәгән, яраңны тегәбез. Вакыты белән төзәлер.

Төзәлде, билгеле. Еллар арты ел үтте. Аратирә, бигрәк тә һава торышы бозылганда, баш сызлады. Былтыр ул төнлә авыртудан уянып яра урынын капшаган иде, пыяла ватыгы тишеп чыкты! Ул, күрәсең, сөяк белән тире арасында кысылып калган иде.

«Шешә бизнесы» шуның белән төгәлләнде. Озакламый илдә «коры закон» кабул ителде. Урамнарда кырынмаган-юынмаган ир-атлар күбәйде, «бомжлар» дип аталган бу йортсызнисез сукбайларга Латыйф сәерсенде. Авылда агай-эне җир җимертеп эшләгәндә хәерчеләр иртән үк чүп савытында казына һәм, ни гаҗәп, аның кебек үк буш шешә савытлары өчен егылып үлә иде. «Төсле металл кабул ителә» дип койма-баганаларга ябыштырган белдерүләр күптән инде Латыйфның күзен кыздыра, ә аңа бу шөгыль таныш, чөнки мәктәптә тимер-томыр җыйдыртып интектерәләр иде. Ул адрес буенча база тирәләрен әйләнде. Халык нәрсәдер ташый иде. Хуҗа бабайдан белеште: хәзинә «алтын тавы»нда икән. Таудан да биек Самасыр чүплеге икән ул.

— Анда ни генә юк! — диде Кәшиф карт. — Самавыр дисеңме, табак-савытмы, киемсалыммы! Көн саен машина белән ташыйлар! Төсле металл, улым, кыйбат нәрсә. Иске телевизор, иске радиоалгычны сүтсәң — хәйран үзе.

— Әйдә, бабай, шунда киттек! — Үсмернең йөрәге җилкенде. Менә кайда ул акча!

— Ай-һай, улым! Минем кылтый-пылтый аяклар белән ерак тәпиләрсең микән? Миңа җитәр, улым. Бутилкәдән дә гарык. Син хәзер шомардың, ташкаланы аркылыга-буйга айкыйсың. Борис ышпана да мактый үзеңне. Пләмәшең Казанда судагы балык сыман йөзә, ди. Каян ул синдә мондый әрсезлек, Ходайның рәхмәте!

Борис күрше егете иде. Карт аңа «Ышпана» дип кушамат таккан икән, димәк, юкка түгел, аның берәр кыңгыр эшен беләдер. Ә күрше абый, киресенчә, Латыйфка ошый, күрше абый кыю һәм тәвәккәл, нәкъ менә шундый ир-егет дөньяның сыртына атланып чаба да инде. Борис белән алар тиз дуслашты. «Ышпана» каядыр командировкага киткәндә, аның аю хәтле этен үсмер ашатты. Маквайр башта, ятсынып, аңа өргән иде дә, Латыйф тавык сөяге ыргыткач, койрыгын болгап: «Соң, әйдә, танышыйк», — диде.

Таш астында үскән шәһәр малайлары шешә җыючылар белән вакланмаса, «тимерчеләр»не исә күз уңыннан ычкындырмады. Латыйф беренче каршылык белән шул чакта очрашты. Болар инде Ислайдан да арттыра, болар үтә дә кансыз үсмерләр иде. Әйе, алар авыл малаен кыйнамады, бары тик: «Атна ахырында фәлән йорт ишегалдына безнең өлешне китерәсең», — дип шарт кына куйды. «Табан ялтыратсаң, кайда яшәгәнеңне күрдек, бабаң белән икегезне дә муеныгыздан асабыз», — дигән янаулардан соң ничек яшәргә ди. Ярыкка гына чумар идең, таракан түгел. Авылга таяргамы? Әнисен хәсрәт утында көйдерергәме? Укыйм дип алдаш та, тып итеп кайтып кер, имеш!

Беркөнне Борис:

— Ну-ка, җегет, әйт, нишләп кинәт кенә сөмсерең коелды әле? — диде.

Латыйф:

— Мине бандитлар талый, — дигән иде, күршесе кычкырып көлде:

— Ну даешь, җегет! Синнән акча каеручылар вак-төяк урам шпаналары гына, крутойлар синең ишеләр белән кул пычратып, дәрәҗәсен төшерми, кибет баса, банк баса, машина урлап сата, так что, не вешай нос! Давай, адрес, разборкага үзем барам.

— Ышпана белән ышпана сугышамыни, абый? Карга күзен карга чукымый, диләр.

— Кем «ышпана?»

— Син, абый. Кәшиф бабай шулай ди.

— Вот әкәмәт күрше! Кемгәдер картлык акыл белән, кемгәдер ялгыз гына килә икән. Сиңа бер мәзәк сөйлимме? Мәскәү урамында «Запорожец» белән «Волга» бәрелешә. Иске арбаның хуҗасы олы гына яшьтәге абзый икән. Моны дүрт крутой уратып алган. Сәләмәсе-ние белән бергә юл кырыена тәгәрәтәбез дигәндә генә абзаң:

— Сабыр итегез, туганкайлар. Минем улым — кош-корт фермасы башлыгы, хәзер рация аша чакыртам, ул сезне бәхилләтер, дигән. Крутойлар, вот, безгә повезло, хәзер моның улыннан акча да савабыз, тавык боты да кимерәбез дип сикерешкәндә, ике микроавтобуста килгән омончылар егетләрнең дүртесен дә асфальтка егып, шәп кенә тукмаган. Соңыннан улы әтисен битәрләп:

— Сине күпме кисәтергә була, мин кош-корт фермасы директоры түгел, мин «Бөркет» отряды начальнигы, — дигән. Так что, энем, мин дә шпана түгел, «Куркынычсызлык хезмәте»ндә эшли сезнең Борис Азатович!

Гайрәтле күрше юлбасарларны ничек бастыргандыр, өркетепме, йодрык иснәтепме, билгесез, тик шунысы мәгълүм: моннан соң төнлә дә урамда сызгырып йөр, сиңа беркем дә бәйләнмәячәк иде. Борисның игелеге моның белән генә чикләнмәде: Кәшиф карт тиянадан гына фани дөнья белән бәхилләшкәч, егет тиз генә документ ясатып, Латыйфны бабайның йортына пропискага керттерде. Аның яшереп саклаган акчасын да ул тапты. Бүлешәбез, димәде, яшь дустының исеменә саклык кассасына салды. Кәшиф карт: «Теге ышпана ник сине якын итә икән?» — дип аптырый иде, бу сер дә ачылды. Латыйф ике тамчы су кебек Борисның энесенә охшаган икән… Мәрхүм энесенә… Димәк, ул, күршесе өчен бер үк вакытта мәңгелек яра да, бер үк вакытта язмыш бүләге дә иде. Бөркет канаты астында, җил-яңгырдан ышыкланып яшә дә яшә генә! Ләкин Ходай күпсенде шул, күпсенде… Абый кеше мәхәббәт чире белән авырый башлады. Әлеге терелүе шикле чирне аңа хатын-кыз йоктырды. Колгадай озын буйлы, кәкре аяклы кызга өйләнгәч, Алып ир күзгә күренеп юашланды, күзгә күренеп тәбәнәйде. Аны танырлык түгел иде. Кисәк кенә өстенә ауган бәхеттән исергән (йорт аныкы, акча аныкы!) Латыйф ике җенес мөнәсәбәтен аңларлык дәрәҗәдә җитлекмәгән иде шул! Яратам, диде Борис һәм вәссәлам! Бактың исә, мәхәббәт адәм баласын акылдан яздыра икән. Җен төсле ямьсез «колга», нәтиҗәдә, йорт-җирен саттырып, ирен үзе белән җәһәннәм читенә — Владивостокка ияртеп китте. Шунда да Борис яшь дусты турында кайгыртып калдырды.

— Син сату-алуга хирыс, Латыйф, — диде. — Башың эшли, әйдәле, бабайның акчасына киоск ал. Бүген алар модада. Дөрес, дистә еллардан соң зур-зур кибетләр йотар үзләрен, ә син анда хәтле ныгыйсың әле. Сиңа беренче мәлләрдә Яким агай булышыр. Аңа миңа ышанган кебек ышан. Мә, мин картлачка хат кисәге сырладым. Күзлеген киеп, җентекләп укысын! Миннән кайнар сәлам тапшыр!

Дөя сыман аркасына бөкре «утырткан» Яким агай хатны укыгач сузып-сузып уфырды:

— У-у-уф! Ну Борис шайтан! Үземнең бөкрем генә аз иде, тагын берсен чәпәде. Сиңа ничә яшь, малайка?

— Унҗиде тула, — диде Латыйф.

— Күсәк икән. Синең яшьтә без немецлар белән сугыштык. Кара-каршы. Сез — сыек буын шул. Ну, Борис үтенгән икән, тыңларга кирәк. Киоск этмәлләдек, ди. Аны минем исемгә рәсмиләштердек, ди. Анда нәрсә сатарга җыенасың, малайка?

Егет җилкәсен генә сикертте.

— Ага, белмәмеш! Ну, Боря шайтан, бөкре өстенә бөкре… Йә, зарланып кемгә файда? Син ипигә көйлә, малайка. Ул көндәлек ризык, аны анасы да, баласы да ашый. Икмәк заводы белән опять таки мин договор төзим. Давай, акча!

«Дөя» үрмәкүч төсле төрле якка пәрәвез җебе сузган, аның әшнәләре күп, кайсына гына сүз катса да, кире бормыйлар иде. Ай ярым дигәндә урам чатында киоск калыкты, ул әллә ничә адымнан ук тәмле күмәч исе таратып, авыздан сулар китерә иде. Чынлап та, ипи — табын патшасы икән, кич кеше эштән кайтканда аңа чиратка тезелә иде. Яким агайның, әйтерсең шәхси сәүдәсе, куанычыннан йөзе нурланып балкыды. Хәер, Латыйфта аның хезмәтен бәяләрлек кенә акыл бар иде: табышның өчтән бер өлеше агайның кесәсенә «чума» барды. Иренмә, эшлә дә эшлә генә! Әмма алда куркыныч «җанвар» сагалый, ул исә — солдат хезмәте иде. Монда да «Дөя» чарасын күрде: типсә — тимер өзәрлек күсәкне чирләшкәгә чыгарттырды.

– Синең кирза итек туздыруыңа караганда, бәндәне ашатуың файдалырак, – диде.

Беркөнне Яким агай учын учка шапылдатты.

– Үрчибез, малайка! Кассада акча черетмә, тагын янәшә ике киоск куябыз! Быел җәй эссе килә, су белән туңдырма сатабыз! Үтемле әйбер! Халык кырылып алачак!

Халык «кырылып» өлгермәде шул. Төнлә кайсыдыр адәм актыгы өч «нокта»ның да көлен күккә очырды. «Кем ут төртте?» – тауардашы кәгазьгә исем-фамилиясен яза-сыза эзләгәч, исемлекне ертып ташлады.

– Минекеләрдән шикләнмим. Мине дошманнарым да ихтирам итә, чөнки аларга да, дусларга да игелегем тиде. Көндәшләр хәттин. Яманлык теләмәгән көндәшләр кирәк ул. Син сөрсемәсен өчен. Алар сине гел тонуста тота, ялкауланырга ирек бирми. Арбага җигелгән ат төсле буласың син, тыныч кына йокламыйсың, тәртә комачауламый. Йә, малайка? – Агай егеткә текәлде. – Син ничә дошман үрчеттең инде?

– Әлегә чәчәм генә ахрысы, Яким агай. Тиздән шытар инде алар, – диде Латыйф. – Элек бер дустым белән эз-мәз чәкәләшә идек. Бүген Казанда ул. Сәер инде үзе, мин сөялгән куакка чыпчык кунса да, бик әшәке итеп көнләшә.

«Дөя» бөгәрләнгән кәгазь кисәген тезенә җәеп тигезләде.

– Мә, яз! Исеме кем? Кайда яши?

– Ислай – хәйләкәр төлке. Сездән дә шома гына ычкыначак.

– Синең авылдашың туганда без хәйлә капчыгын туздырып, кырык тапкыр типчедек, малайка.

Тиздән егетнең шиге расланды: Яким агайның «хәйлә капчыгы» ертык иде.

– Җегетләр иснәнде, якташың чиста, – диде агай. – Киосклар янган төндә больницада яткан, белешмәсе кулында. Ул сиңа сыек көндәш, әлләни эш майтармый, ди. Туган тиешле урам себерүче абзыкае белән Колхоз базарында ике точка ачкан, ди.

Зур авыл – Казан Латыйфны әрсезлеккә өйрәтә, ул көн арты көн үткенләнә, әгәр егет тауардашына аркаланып җебеп утырса – киләчәктә дәрья буйлап йөзгән көймәсенең комга терәлүе ихтимал иде. Үз чиратында Латыйф «разведка» ясады: киоск каршындагы биш катлы йорттан кыяфәте белән авылдашы Фазыйлә остабикәгә охшаган карчык ипигә йөри, кайчакта егет аңа садака итеп бавы белән клиндерләр тоттыра иде.

– Улым, кичләтә генә кисугыз (киоск!) тирәсендә унынчы фатирдан Әндри малайлары буталды. – Менә кем шаһит иде! – Ходай кичерсен берүк, шуларның кулы уйнады ахры.

Абыйлы-энеле «түмгәкләр»не таный иде Латыйф. Туганда ук, үсмәгез дигәндәй җилкәләренә авыр таш асып аска чүгәләткәннәрмени, алар икесе дә бәләкәй буйлы иде. Бәрәңге бакчасы казып, печән чабып буын ныгыткан егет «түмгәк»нең кечкенәсен эләктереп култыгына кыстырды:

– Әйдәле, минем машинада гәпләшик, карга баласы! Тыпырчынма, сугып канатыңны сындырмыйм! Бу нәрсә? – Латыйф аның борын төбендә йөз тәңкәлек кәгазь акча селкеде.

– Акча-а-а!

– Әһе, дөрес. Моңа тау хәтле туңдырма бирәләр. Җәй буе рәхәтләнеп яла да яла!

«Түмгәк» күзен ялтыратып акчага үрелде.

– Чү, ашыкма! – Латыйф аның маңгаена чиртте. – Бармагың пешмәсен! Әүвәл әйт, киосკларны кем яндырды?

– Шешә белән крәчин алып килгән абый кушты. Мин бит шырпы гына сыздым.

– Нинди абый кушты? Аның белән кайда каркылдаштыгыз, карга баласы?

– Базарда. Ул безнең энидән җимеш саттыра. Мишка абый, саран тәре, шул акчага фифирус алды, энидән качып тарта.

Һай, Яким агай ни хәтле генә ямаулы «хәйлә капчыгы» белән мактанса да, аны кәкре каенга терәткәннәр иде. Гаҗәп, ялгышын төзәтеп, Ислайның арт сабагын укытасы кеше Латыйфның үзен эт итеп сүкте.

– Кәнитил кеше икән син, малайка. Матри, дөньяны тәртипләп яшәмәсәң, алга табан бер эшең дә уңмас. Авылдашың белән арагызны җайла! Бар базарга, икәү җимешләп чәй эчегез!

– Әтәч белән төлке кайчан бер табында сыйланган ди!

– Кирәк икән – чүт-чүт үбешәсең дә, малайка! Йә, хәзер мәгънәсез сугыш башлыйкмы? Әгәр малайларны җибәреп аны дөмбәсләтсәк, ул безгә йөз этен өстерәчәк. Нәтиҗәдә безнең бөтен көчебез үчләшүгә китәчәк.

– Ул гаепле, ул чыгымнарны түләргә тиеш!

– Аның хәтле үк бөлмәдек әле без. Яким абзаң алдын-артын карап эш итә, страховка акчасы

ничава гына булды. Мин сине ярты юлда бәреп кенә калдырыр идем, Бористан яхшысынмыйм. Ул мине үлемнән коткарды, ике бандюгадан аралап, пычак астына керде. – Хисләнгән тауарише тиз айныды. – Давай, мәлҗерәмик, малайка! Универмагның өч бүлеген арендага сорадым. Все-таки түбә астында ышанычлырак. Давай, өч-дүрт кибетче сайлыйк!

Аның заманы шундый иде, әрсезләр кулланучылар җәмгыяте карамагындагы кибетләрне кысрыклап, төрле зурлыктагы, төрле төстәге «шырпы тартмалары» кордылар. Алар тәртипсез рәвештә кайсы тукталышта, кайсы урам чатында урнашып, шәһәрнең килеш-килбәтен генә боза иде. Һәрберсенең шәхси хуҗасы… Хәер, тартмаларның күбесе ишелде, күбесе янды, чөнки «көндәшләр» үзара корал теле, ут теле белән «сөйләште». Дистә-дистә еллардан соң, әнә, хакимият үзе аларны төбе-тамыры белән йолкып атты. Эчендә машина белән әйләнерлек супермаркет байлары да аларны таракан урынына сытты.

…Латыйф Яким агайны тыңлады, тик Ислай белән чәй эчмәде. Башына кәпәч киеп, муенын якасы белән каплап әллә ничә тапкыр Колхоз базарын урады. Монда җиләк-җимеш сатучылар бер-берсе белән таныш иде. Ислай өченче көн генә Ташкенттан тауар кайтартып складка бушаткан икән. «Ике-өч урам шпанасына акча бирсәң – моның җимешләрен шәп кенә «куыралар» инде», – диде ул. Үч белән өретелгән бу мәкерле уй, бәлки, төнлә соңгы адымга этәрер дә иде. Яким агай чуртым да сизмәс! Арттан кемдер иңбашына кагылды:

– О-о, синме соң, Латыйф?

-3-

Сүзе кыска иде: «Кил!» Җавап көтмәде, телефон төймәсенә басты. Ул боерса, һавадагы кошлар да очып төшеп учына кунарга тиеш кебек иде. Дамир сәгате-минуты белән килеп җитте. «Кунак йорты»нда аулак иде, Латыйф егетне шунда алып керде.

– Һәйкәлне нишләтәбез, энем? Мәшәкате күп, әйеме?

– Ниткән мәшәкать, Латыйф абый! Су сибеп үстерәсе түгел. Хуҗасын көтеп тик күгәрсен.

– Син, энем, элек мине күз карашымнан аңлый идең. Аңгырайдың, энем. Ул галәмәт сынны йә шартлатабыз, йә берәр чокырга күмәбез.

Дамирның күзе акайды.

– Менә бу төштә мин сезне точно аңламыйм, Латыйф абый!

– Кем соң ул, Сәлимов?! Кем?! Атаклы кешеме, яисә бөек юлбашчымы?

– Кем дип… Миңа ни. Сезгә дә ни. Ишегалдыгызда кукраймаган, бернинди зыяны тими.

– Тия, энем, йөрәккә тия! – Латыйф йодрыгы белән күкрәген төйде.

– Кичә үк зиратта кәефегез кырылган иде, мәйтәм. Ниндидер сын өчен ярсымагыз инде, Латыйф абый!

– Энем, минем белән бәхәсләшмә, яме! – Хуҗа терсәге белән өстәлгә таянды. Дамир аның күзендә тәгәрәгән яшен ташыннан өркеп, яртылаш урындыгына сеңде. – Әйдә, киңәшик. Шартлатсак – тавыш куба, трактор белән сөйрәтсәң – эзе кала. Нишлибез? Төйибез! Иң җиңел юл!

Егет җилкәсен турайтты.

– Сез… сез… Латыйф абый һаман шул икән: үз дигәнегезгә ирешмичә тынычланмыйсыз. Кыйбат бит ул һәйкәл! Миллион сумлык бит ул!

– Кайгырма, барлык чыгымнарны да каплыйм мин, энем. Анысы кысыр хәсрәт синең өчен. Сәлимов тузынса, «мә» диярсең.

– Әйе, сез егетләрдән сынны юк иттерәсез, ди. Әйе, полиция мине апкитеп яба, ди. Кызык кеше сез, Латыйф абый!

– Шыңшыма, энем! Япмаслар!

Латыйф кесә телефонын кабызды.

– Алло, аэропорт кассасымы? Чәршәмбегә Дамир Хаҗиев исеменә Мәскәүгә билет кирәк. Рәхмәт! Ишеттеңме, энем? Ун ел элек аягыңдагы шешне кистергән идек, тагын авырта, каһәр. Тиз арада табибларга күрсәтергә, ди. Клиникадан фәлән көнне, фәлән сәгатьтә кабул иттеләр дигән белешмә ал.

– Сызламый ла аяк…

– «Сызлый», энем, үтереп «сызлый»! Нинди аңгыра соң син?! Бу сиңа алиби!

– Бәлки моны зират хуҗасы белән килештерербез, ә, Латыйф абый? Зур гына акча белән бәхилләтеп, мәйтәм, ә, Латыйф абый?

Ул иренен очлайтып егетнең битенә өрде:

– Өчәү белгән сер дөнья сасыта, энем! Әңгәмә тәмам. Әллүр Мәскәүгә!

…Рәдифә «кунак өе»нә табан килә иде.

– Латик кадерлем, теге адәм баласы кем иде ул? – дип, хатын аңа сарылмакчы иде, ир аны иплэп кенә тотып кәнәфигә аударды:

– Өч кенә минут дәшмә! Ардым!

...Тормыш итәргә яраксыз курчакка аны беркем дә ирексезләп өйләндермәде. Авылда гомер кичергән әнисе, шәһәрдә һава алмаштырды ахрысы, кан басымы күтәрелеп, башы авыртты. Беренче хатыны Наилә – Латыйфның уң кулы – «әнкәй» дип өзелсә дә, иртә-кич гаилә бизнесы белән мәшгуль, өйдә аны «ай күрде дә, кояш күрде» иде, шуңа күрә Латыйф шәфкать туташы яллады. Ягымлы һәм тәмле телле Рәдифә күбәләк төсле гел карчык тирәсендә бөтерелде. «Бибиҗамал әбекәй уянып саташа», – дип коттеджда кунган төннәр дә ешайды. «Торып йөгерәсе булса – чабатаңны кичтән үк киеп ят», – дигән борынгылар. Ир алданды: кыз дигәнең бик тәҗрибәле «балыкчы» иде. Кармакны йөрәк уртасына хәтле ташлап, Латыйфны җиңел генә каптырды. Наилә бу хәлләрдән соң өч бүлмәле фатирга күченде. Башта ир канәгать иде. Тыныч кына шаулаган гомер диңгезендә ап-ак күбеккә төренгән дулкыннар чайкалып аның җанын иркәләде. Тик ир яшь хатыннан бик тиз бизде, чөнки язмыш, уңлы-суллы яңаклап бер хакыйкатькә төшендерде: «Өр-яңа тормыш башладым дип ялгышма, агай-эне! Артыңда – яшәлгән еллар... Алар гамәлдән сызылмый...»

Тыйнак шәфкать туташы теләгенә ирешкәч, үзгәрде. Моңарчы иңennән кочып:

– Бибиҗамал әбекәем, мин сине яратам, – дип сайраган «сандугач» карчыкның ишеген дә ачып карамас булды. Хәер, эше дә «куәтле»: оясын «киңәйтте», ә ул зур түнтәрешкә тиң иде. Якты, иркен бүлмәне биләде, йөзәр меңлек карават, ортопедик матрас, ефәк тышлы юрган-мендәрләр алдыртты. Өч кием шкафына озын һәм кыска чәшке туннары эленде. Кыскасы, акча йорттан шарлавык кебек акты. Һәр тиенен тир түгеп тапса да, Латыйф хатынын кысмады. Янәсе вакланмый, янәсе эредән суктыра. Әнкәсе, рәхмәт яугыры, Рәдифәнең кыланмышларына бер дә аптырамады, әнә, күр, Газизҗан карт белән ничек «җеннәре» килеште.

Түземсезләнеп арты белән кәнәфиендә «биегән» хатын уйга баткан ирдән туеп:

– Әй, син, – диде. – Мәрткә чумдың мәллә? Нәни генә үтенечем бар иде сиңа, Латик!

– Шәт, дүрт туныңны да көя тапамагандыр? Өч ай элек кенә чит илдә ял иттең, шәт, шоколад төсендәге тәнең тире салмагандыр? Иренеңне кичә генә кабарттырган идең, шәт, ул шиңмәгәндер?

– Үртәмә инде, Латик! – дип ыңгырашты Рәдифә. – Бу үтенеч синең өчен чүп кенә, Латик. Әниең сыман мин дә үзем турында әсәр яздыртыр идем.

Ир салкын гына:

– Яздырт, – диде. – Әни тын алганда син сөйлә!

– Кемгә? Тәҗрибәсез журналист кызгамы? Юк, Латик, мин берәр танылган язучы белән танышам. Кем язган – Фәлән Фәләнов үзе язган, дисеннәр! Мин калын китап бастыртам. Сурәтләр белән! Ялтыравык кәгазьдә. Нәшрияттан бәясен белештем, өч миллион чамасы, ди.

– Шуннан?

– Утырып шумаган, яме! Акча бир!

Латыйф шаркылдап көлде.

– Китабыңны бүлекләп эшләт инде син. Беренче кисәгендә архивларда казындырып, аксөяк нәселеңне барлат.

– Барлатсам соң! Без синең төсле батрак орлыгыннан яралмаган!

– Менә, менә! Бүген батрак оныгы акчасына типтерәм дип тә өстәт. Икенче кисәгендә училищеда ярым-йорты укыгач, дару исемен дә танымыйм дип, медицина өлкәсендәге уңышларың белән мактан!

– Саран син, Латик!

– Акча яңгыр түгел, күктән яумый. Өч миллион табыш китерер өчен Наилә апаң куна-төнә ресторанда эшли!

– Харап икән! Уртак бизнесыгыздан өч тиен кызганасың. Әнкәңә дигәндә ул күктән ява әнә! Авыл хатыны гәзиткә язарлык нәмә корган соң әле?

Латыйфның ачу кибәне ишелде.

– Мине үстергән, мине!!!

Шөкер, мондый бәхәсләр йөрәккә үтеп сызландырмый, чөнки яшь хатын бармактагы сөял кебек, дару сөртсәң – төбе-тамыры белән корый, ә менә күзен тасрайткан сын кичәдән бирле ни сук, ни кыйна, ни бәр – күңелдән китмичә газаплый иде...

Ислай, Ислай... Базарда ул җилкәгә орынган иде.

– Бәй, нишләп минем биләмәмне таптыйсың, Агылый?!

Латыйф дустының чыраена карамас өчен башын аска иеп (кул кычыта, их, авызына чәписе иде!):

— Ничек синең биләмә әле бу? — диде.

— Шулай, Агылый. Тиздән мин аны сатып алам! Сораудан качма, безнең тирәдә ник чуаласың?

«Синең ипи шүрлегеңне җимермәкче идем», — димәкче иде Латыйф, чын мәгәр, гәүдәгә ул Ислайдан шәбрәк, сугышкан тәкъдирдә, һичшиксез, җиңәчәк иде. Ләкин базар уртасында көч сынашу ахмаклык иде.

— Кайгымны әйтмәкче идем. Кайсыдыр бәдбәхете киоскларны яндырды.

— Ай-яй! — Әйтерсең үзе бәлага тарыган, Ислай шундый да кызганыч кыяфәт ясады ки, аны кочаклап: «Елама, авылдаш», — дияргә генә калды. — Ай-яй! Ә бездә нинди исәп белән йөрисең соң, Агылый?

Ислай баллы су дип ничә тапкыр аңа эрем төнәтмәсе каптырды, ә Латыйф, хәйләсез җан, чыраен сыта-сыта «эчте». Бу юлысы ул иренен каты бөрде.

— Аптыраган, дускай. Рас син базар хуҗасы, миңа урын хутламассың микән?

— Оһо! Нәфесең зур синең, Агылый! Бар, искерәк киемнәреңне киеп кил. Үзбәкләр белән капчыклар ташырсыз!

— Колагың саңгырау бугай, дускай. Мин синнән сәүдә урыны сорыйм.

— Гафу, бер Казанга ике тәкә башы сыймый. Базарда бигрәк тә. Монда мин генә баш, мин генә түш, — дип кәперәйде Ислай.

— Соң, баш белән түш бул да тор! — Латыйф уенны дәвам итте. — Минем тауар белән синең тауар чәкәләшмәс.

Ислайның йөзе каралды.

— Вәт хәерче сыңары! Синең максатың ачык: мине кудыртып, базарны кесәңә тыгарга хыялланасың! Ычкын моннан!

Латыйфның да каны кызды. Авылда бәнахакка гаепләнү, кәҗә сату, Казансу ярында баш тишелү, ниһаять, ут ялмаган өч киоск ташкын төсле эчтән актарылды. Кизәнеп тондырам дигәндә генә, Яким агайның кисәтүе кулны богаулады. Хак, җәнҗал куптарсаң, ул мәңге тынмаячак, иң шәп үч — «Латыйф — бай» дигән данга ирешү иде. Егет көчәнеп кенә елмайды:

— Җә, Ислай, кабарынма. Шаяртам бит. Үземдә дә эш муеннан. Шәһәрдә кибет челтәре җәелдерәм. Кафе-ресторан ише нәрсәләр дә ачармын дим.

— Ха-ха! Бетең беләнме? Киоскларың һавага очкан!

— Акчага әверелеп кире төште алар. Икеләтә страховка түләделәр.

— Мин сине барыбер уздырам, мин — беренче! — дип төкерек чәчкән Ислайның ул битеннән чәбәкләде:

— Зинһар, дошманлашмыйк, Тагылый. Бер-беребездән яратып кына көнләшик!

Яким агай кебек биш остаз биш яктан тукыса да, каһәр суккан тел «оясында» тик кенә ятмый шул, хушлашып ике-өч адым атлагач та, Латыйф дустын мыскыллап:

— Риза, син беренче булырсың. Койрыктан санаганда, — диде.

Тычкан җиде кат җир астында кыштырдаса да колагын торгызган карт мәче — Яким агай аның базардагы маҗараларыннан хәбәрдар иде.

— Их сине, тагын арагызны боздыңмы? — диде ул.

— Биш былтыр бозылган ара бүген генә бозылса икән, — дип сукранды егет. — Сөякләрен сындыра идем дә... Син каршы бит, Яким агай.

— Егерме дүрт яшьлек күсәк! Һаман йодрык белән масаясың. Сәүдәдә көч түгел, акыл белән хәйлә кирәк. Ну, давай, ярышыгыз! Ахыр чиктә кайсыгыз шаккатырыр икән.

Ислай шаккатырды, Ислай! Картлач исән булса, әлеге дә баягы вәгазен кабатлар иде микән? «Көч кулланма, акыл һәм хәйлә белән җиң...» Никадәр генә күперенсә дә, Казанда дусты мантымады. Алдап-йолдап төзелгән дәүләтнең нигезе тиз чери. Ислайны базардан сөрделәр, һәм ул сәүдә нокталарын ябып, Себергә юл тотты. Күрәсең анда иркенләп канат җәйгәндер, бай ди бит, Себер бае, ди. Тимер сынга миллионнар ташлагач, димәк, «акча бездә бер букча». Бу мәшәкатьләрдән соң шымчы егетләр ачыклар: кайсы урамда, йортта яши икән Сәлимов дус.

...Газизҗан карт өйдән савыт тотып чыга иде, уйлана-уйлана атлаган Латыйф әз генә аңа бәрелмәде.

— Тагын теге хәерчегә аш илтәсеңме, Гаҗҗан абзый?

— Кертеп кенә тукландырыр иек тә ди Бибиҗамал апа. Син ни бит...

— Мин ни шул, ни! Тормыш түгел инде бу! Кыш нишли ул? Берәр документы бармы, сора. Картлар йортына урнаштырырмын, — диде ир, һәм күңел-

ле генә сызгырып гараж ишегенең ачкычын борды. Аның танышы шәһәр читендә йортлар төзи, хуҗалыгында йөк машинасы да, кран да җитәрлек, «һәйкәл операциясе» өчен аңардан да кулайрак кеше юк иде.

...Иртән аны телефон чәрелдәп уятты.

– Латыйф Гыйздуллович, бетте баш, калды муен тырпаеп! Зираттан берәүнең сынын урлаганнар, – дип колак ярып үкергән «аю»га ул тыныч кына:

– Дөнья җимермәсәнә, – диде.

– Җимерерсең дә! Һы, сез ышыкта җилләнәсез, барысын да миңа аударасыз да! Мин – ярдәмчегез, мин – җаваплы. Дамир дигән егетне директор итеп билгелә, дидегез. Ә ул – сарык бәрәне Мәскәүдә икән! Нишлибез, Латыйф Гыйздуллович?! Һәйкәл аякланган дияргәме?

– Соң тап инде берәр сәбәп, Илһам! Җилкәңдә нәрсә анда, башмы, әллә чатнаган чүлмәкме?

– Иң яхшысы полициягә хәбәр итәм!

– Нинди полиция, ахмак! Оешмас борын зиратта гауга кузгатыйкмы?! Тыныңны кыс! Һәйкәл өчен Дамир сиңа акча китерер, хуҗасына түләрсең. Хуш!

Аяк очына гына басып бүлмәгә якынлашкан Рәдифә ишек яңагына сөялде.

– Ник акырасың, Латик? Тавышың бөтен өйгә яңгырый.

– Ә син тыңлама, йокла!

– Кемнеңдер һәйкәленә акча түгәсең, ә миңа шымытыр, – дип, хатын авызын турсайтты. – Карале, Латик, без синең белән загста язылышмадык, әгәр мине ун миллион белән бәхиллләтсәң – синнән аерылам.

– Синең бәяң – шалкан бәясе, тутый кош.

– Алай димә, Латик. Мин сиңа бер сер сатам. У-у, кыйбат ул!

– Сереңне үзеңдә генә сакла, – диде ир, хатын белән сүз көрәштерү җүләрлек билгесе иде.

Ә кич белән Рәдифә аңа урталай бөкләнгән кәгазь тоттырды.

– Мә, җылы кулына тапшыр, диде.

Латыйф укыды да исәнгерәйде:

– Син бу адәмне каян беләсең, кызый?

– Әйтмим, – диде хатын. – Сереңне үзеңдә генә сакла, дидең ич.

-4-

Ислай Сәлимов аны иртәгә «Балкыш» ресторанына очрашуга чакыра иде. Димәк, хәбәр ирешкән... Тик шунысы кызык: Латыйфтан ник шикләнә ул? Илһам ычкындырганмы? Юк, егет авызына су каба беләә. Менә табышмак!

Гәрчә, күрешү сәгать унбергә генә билгеләнсә дә, ир, киенеп-ясанып ресторанга китте. Ул беренче булырга тиеш! Монда да шайтан котыртып ярыш дәрте уята иде. Ул иң почмактагы аулак өстәлне сайлады. Официант урталай бөгелеп:

– Сезне ни-нәрсә белән сыйлыйк? – диде.

Латыйф сарык итен вак кына турап пешергән мантый ярата иде. Шуны дүрт өлеш китерергә кушты. Сәгать теле әкрен генә текелдәп минутлар санады. Унбер тула... Ресторанда кеше аз, югыйсә тирә-якта ничәмә-ничә оешма, ничәмә-ничә офис, илдә кризис диләр дә, пыяла савыттагы ашларын җылытып ашыйлар. Чү, Газизҗан карт тамагын туйдырган урам хәерчесе керә! Бичара, теләнеп җыйган акчамны затлы урында туздырыйм дигәндер. Ул да адәм баласы, таудан түбән тәгәрәсә дә, ниндидер уй-ният белән тереклек итеп маташа.

Йөзен сакал-мыек басып, күзе генә күренгән хәерче туп-туры аңа табан теркелдәде.

– Иптәш, син миңа комачаулама, – диде Латыйф. – Әнә, дистәләгән өстәл, берсенә җайлап урнаш. Мин кунак көтәм!

– Көтәсеңме? Рәхмәт! Сәгать кыл унбер! – Хәерче лап итеп аның каршысына утырды. – Танымадыңмыни?

Латыйфның түземлеге төкәнде:

– Күч дим, абзый, башка өстәлгә күч!

– Кычкырма, бу – мин!

– Ну, әрсез эт! Аша, әйдә! – Ул хәерченең алдына тәлинкәсе белән мантый этте. – Түлке тиз-тиз капкала!

Адәм заты учына йөткерде:

– Салкын судан тамак шеште, каһәр. Ашыйм әле, яме? Карын ачты. Бибиҗамал апа нихәлләрдә? Авылны сагынмыйммы? Коттеджың шәп, анаңны кадер-хөрмәттә яшәтәсең. Маладис син, Агылый.

Кем бу адәм, йә? Кем?! Латыйфка һава җитмәде, ул официант егеткә:

– Җиләткечләрнең дүртесен дә кабызыгыз, – диде.

– Хуҗа әйткәч малайлар чатыр чаба, иеме, Агылый. Ресторанның да шәп, өчесендә дә тәртип. Беренче хатыны Наилә уңган синең, Агылый.

Латыйф ярдагы балык сыман авызын ачып һава «йотты» да:

— Гаҗҗән абый сиңа аш белән бергә минем йорттагы хәлләрне дә ташыган икән, — диде.

— Ул түгел, Агылый, аны тиргәмә.

— Син махсус сакал-мыек үстереп, сәләмә кидеңме соң, Ислай? Хәерче ролен әйбәт уйныйсың тагы.

— Валлаһ, мин шыр ялангач, Агылый. Дөньяда иң куркыныч зат кем дисеңме? Хатын-кыз! Аңардан саклан син. Минеке иреннән аерылган, кызы бар иде. Ул, Себердә бай туганым нефть башлыгы, экияттәге кебек баербыз, дигәч, шайтан котыртты. Ике-өч елда акча көрим дә, Казанга кайтып синең борыныңа чиртәм, дидем. Алдады, хәерсез хатын. «Туганы» — яшь сөяркәсе икән моның, дыңкылдатып артыма типтеләр. Вәт шул, Агылый.

Латыйф, кытыкланагандай, күкрәген уа-уа көлде.

— Утыз ел — күп вакыт. Син микән дип шикләндем башта. Хәзер ышанам, син генә шулай матур экиятләр сөйлисең. Бу юлысы нинди этлек эшләргә җыенасың, йә? Олыгаябыз бит инде, туктат, Ислай!

Кунак тәлинкәсен күтәреп ялады.

— У-у, тәмле пешергәннәр!

— Ачка киселгән Себер бае! — дип үртәде Латыйф. — Йә, дәвам ит! Әкиятеңнең азагы ни белән бетә икән?

Ислай тураеп аркасын урындыкка терәде.

— Соңгы елларда кедр чикләвеге саттым. Ачлы-туклы яшәсәм яшәдем, ну һәр тиенемне саклык кассасына салдым. Сынга как раз җыелды.

— Ник аны Казанга китердең? Себердә урын әзмени?!

— Синең бәбәгеңә арыш кылчыгы кебек кадалсын, дидем! Үч итеп эшләдем! — Ислайның төймә күзе нәфрәт белән тулды. — «Мәңгелек йорт»ка мин беренче әзерләндем, беренче! Синең аңа акыл җитмәде, Латыйф! Шәп җирдә булачак минем кабер. Син дә, йоклама, шуннан ал! Тик син икенче, бел!

— Чү, кабарынма күркә! — диде Латыйф, һәм үзенең тәлинкәсен дә аңа табан шудырды. — Тәмле икән, аша.

— Сынны кире куйдырт, Агылый. Аны син генә урлаттың.

— Урлау дип атала микәнни бу? Зиратны тимер-томырдан чистарттырдым мин.

— «Мин?!» Кем соң син ул хәтле?

— Зиратның чын хуҗасы — мин, — диде Латыйф.

Ислайның сакал баскан ияге дерелдәде.

— Корт чаккыры, ник ул монысын әйтмәде икән?

— Мине шымчыларың күзәттемени?

— Шымчы синең түшәгеңдә, Агылый. Миңа кияү сымаграк кеше бит әле син. Кәнтәй хатынымның Рәфидә исемле кызы сиңа оялаган. Ул миңа телефоннан һәр адымыңны сөйләп торды. Ә монысын яшергән, елан!

— Иснәнеп өлгермәгәндер. — Латыйфның сатлыкҗан хатынга исе китмәде. Сораган акчасын тоттырырга да: «Дүрт ягың кыйбла! — диярга кирәк. Ислай белән дә сүзсез генә хушлашырга вакыт. Хуш! Язмыш, кылган әшәкелегең өчен йөзе белән түләткән икән, Тагылый. Хәрәм кайчандыр бер эчеңне тишә икән шул.

Ул тормакчы иде, кинәт кенә башы чыңлады. Зың-зың... Әллә кайдан — хәтер төпкеленнән бер малай сөрән сала иде:

— Ба-а-а-та-ам!

Үзе бит бу, үзе! Язгы ташу белән ага! Тәнеңне куырырлык су аска суырам дигәндә генә берәү күлмәк җиңеннән эләктерде... Ул чакта Латыйфны Ислай коткарган иде. Гаҗәп, җүнле-башлы йөзә дә белми иде Агылый. Икесенә дә җидешәр яшь... Икесе дә яр буенда кочаклашып елашкан иде... Ә бүген Ислай бата... Тормыш диңгезенең дулкыннары аны төпкә сөйри...


Латыйф шымайган кунакның алдына төргәге белән акча ыргытты:

— Һәйкәл өчен өстәмә. Гафу ит, яме? Бүтән күрәшмик. Син чәчтараштa сакал-мыегыңны кырдыр. Төзәтен, юын. — Ул салфеткага саннар язды. — Иртәгә шушы телефонга шылтырат. Минекеләр сиңа бер кибет бинасы күрсәтер. Шунда яңадан эшеңне оештыр. Үләргә ашыкма, яме?

— Нич... ничек ал... лай? — Ислай көтелмәгән тәкъдимнән каушап тотлыкты. — Мин... мин гомер буе таш белән атканда, син аш белән атасыңмы, Агылый?!

— Балачактагы ташу исеңдәме? Бүген мин сине коткарам, Тагылый...

*2017 ел*



**ИЖТИҺАД**

*Яшәүче яшәргә тиеш!*



**СӘХНӘ АРТЫНДА**

*Башкортстан җырчылары гади...*




**СӘЛӘТЛЕЛӘР МӘКТӘБЕ**

*«Халкымның тагын да грамоталы булуын телим»*

# Мәдәният

*авыл һәм рух*

Гөлүсә Шиһапова

# Мунчәлием, син минем йөрәк тибешем!

Чүпрәле районы Мунчәли авылының биш гасырлык тарихы бар. Татар җәмәгатьчелегенә шактый зыялыларны биргән төбәк тә әле ул. Әдәбият һәм тел галиме Нурмөхәммәт Хисамов, шагыйрь Рәмис Аймәт, Русия һәм Татарстанның халык артисты Алсу Гайнуллина, җырчы Алсу Әбелханова һәм башка талантлы шәхесләр әлеге авылның суын эчеп үсә.
29 июльдә Мунчәлидә гөрләп «Авыл көне» узды. Быел ул милли гореф-гадәтләрне саклау ниятеннән, Мунчәли авылы мәчетенең егерме еллыгына багышланды. Шунысы да мөһим, авыл үзе дә 510 еллыгын билгеләп үтә.




**МАТУР ЙОЛА КҮРШЕ АВЫЛЛАРГА ДА КҮЧКӘН**

«Авыл көне» күркәм традициягә әверелгән, авылда алтынчы ел рәттән уздырыла торган Мунчәли укулары белән башланды. Чараны фәнни-гамәли конференция дип кенә түгел, ә дини җыен, дип тә атап була. Беренче тапкыр 2012 елда бөек татар драматургы Туфан Миңнуллинга мемориаль такта ачканда үткәрелгән. Шул вакыттан башлап, Мунчәли укулары һәр елны оештырыла. Темасы да һәр елны үзгәреп тора. Быел «Мәхәлләнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге»н барладылар.

Әлеге чарада танылган язучылар, галимнәр, укытучылар, студентлар,





күренекле артистлар, журналистлар, Казан, Чуашиянең, Сембер, Нижгар һәм Мәскәү өлкәләренең дин әһелләре һәм җәмәгать эшлеклеләре, шулай ук Мунчәли һәм тирә-юнь авылларыннан кунаклар җыелган иде.

Мунчәли укуларын уздыру идеясе белән беренчеләрдән булып Илмир Расыйх улы Измайлов чыга. Шунысы да игътибарга лаек, Илмир әфәнде – Мунчәли авылы тарихы китабын төзегән шәхес тә. Хәзер менә икенче китап басмага әзерләнгән. «Бу чаралар – халыкны берләштерү, аларны тамырларына кайтару, нәселләре турында уйлануга этәрә торган күр-

## Җәлил хәзрәт Фазлыев: «Авыллар яшәсен өчен өч әйбер сакланырга тиеш: дин, җан, нәсел».

кәм бәйрәмнәр, – ди ул. – Динебезне, милләтебезне һәм мәдәниятне үстерү үрнәкләрен күрсәтү буларак, Мунчәли укуларының дәрәҗәсе елдан-ел күтәрелә, масштабы киңәя бара. Яшьләребезнең әхлагын, дөньяга карашын тәрбияләүдә динебезне, аның нигезләрен, милләтебезнең гореф-гадәтләрен, тарихи истәлекләрне өйрәнү, бүгенге көндә дә мөһим мәсьәлә булып кала бирә».

Авылда, чыннан да, бик күп эшләр башкарылган. Беренче укулардан соң мәчетне тәртипкә китергәннәр. Мунчәли укулары үз кысаларында гына калмаган: укуларны үткәргәннән соң, бу матур йоланы күрше авыллар да үз итеп алган. Һәрбер авыл андый укуларда үз үзенчәлеген күрсәтә. Укуларның файдасы бар: яшьләр дингә тартыла, мәчеткә йөри.

Мунчәли укулары тәмамланганнан соң, халык намаз укырга кереште, аннары кунакларны Корбан ашлары белән сыйладылар. Чараның икенче өлешен Чуашиянең Урмай авылыннан килгән данлыклы «Мишәр» эстрада-фольклор ансамбле башлап җибәрде. Мәктәп балалары да, җыр-бию белән, килгән кунакларның күңелләрен күрде.



### ИСТӘЛЕКЛЕ МӘЧЕТ

Менә егерме ел дәвамында Мунчәли мәчете рухи көч, иман нуры белән авыл халкын үзенә тартып тора. 1997 елның август башында мәһабәт Аллаһ йорты сафка баса. Мәчетне ачу



тантанасында мөфти Госман хәзрәт Исхакый да катнаша. Беренче имамы – Вәлиулла хәзрәт Габдуллаҗан улы була. Хәзер исә авылның бер иман йорты аның әтисе хөрмәтенә Абдулла мәчете дип йөртелә. 2005 елдан биредә Нәсыйх Габдрахман улы Садыйков имам-хатыйп була.

Мәчеттә егерме ел буе азан әйтелә, намаз укыла, балалар да мәчеткә теләп йөри. Коръән укучы балалар булуы да куандыра. Шуны әйтергә кирәк, Мунчәли укулары беренче тапкыр үсмерләрнең Коръән уку осталыкларын тикшерү белән башлана. Коръәнне дөрес итеп укый да белергә кирәк бит. Максатлар бер була, чөнки Мунчәли укулары да динне куәтләү, балаларны дингә өндәүне максат итеп куя бит. 2016 елдан мәчетне имам-хатыйп Рәис Габдуллаҗан улы җитәкли.





## ТУФАН МИҢНУЛЛИН ФАТИХАСЫ

Мәҗлестә Туфан Миңнуллин рухына багышлап дога да кылдылар. Татарның классик драматургын Мунчәли авылында зур хөрмәт белән искә алулары юкка гына түгел. Чөнки Туфан ага Мунчәли авылын бик якын иткән, аеруча аларның сөттән ясалган корт ризыгын бик ярата торган була. Авыл көне исә беренче тапкыр 2008 елда үткәрелә, анда әдип үзе дә катнаша. Авыл халкына ул әлеге бәйрәмне туктатмаска, бу өлкәдә эшләрне дәвам итәргә кирәк, дип фатихасын биреп калдыра. Мунчәли укулары – халыкның Туфан Миңнуллин сүзләрен истә тотуына бер мисал.

Шунысы да игътибарга лаек, Туфан Миңнуллин – авыл мәктәбен төзекләндергән шәхес тә. «Мунчәли авылында беренче тапкыр булып, искереп беткән агач мәктәпкә кергәндә, аздан гына идән астына төшеп китми калган идем», – дип язган иде Туфан ага үзе дә. Халык депутаты авыл халкына заман таләпләренә туры килердәй белем йорты төзергә ярдәм итә.

2009 елның 20 маенда халык җыены карары белән Т. Миңнуллинга «Мунчәлинең мактаулы



гражданы» дигән лаеклы исем бирелә. 2012 елда авылда мәктәп бинасын төзүгә, авылның фәнни-мәдәни мирасын саклап калуга зур өлеш кerткәне өчен, мемориаль такта да ачыла.

Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Айрат Җәлалов билгеләвенчә, Туфан Миңнуллин әсәрләре авыл сәхнәсендә бик теләп уйналган, халык та яратып тамаша кылган. Аның әсәрләре хәзер дә сәхнәдән төшми. Мунчәли укулары кысаларында Туфан Миңнуллинны искә алу чарасында Камал театры артистлары да катнашты.

Кичәгә драматургның кызы Әлфия Миңнуллина да килгән иде. «Әти, чыннан да, гомер буе халык өчен эшләде, татар мәнфәгате белән яшәде. Сезнең аны шулай зурлап искә алуыгызга зур рәхмәт. Әтинең рухы шаттыр», – дип сөйләде Әлфия ханым.

Килгән кунаклар, бөек драматургыбызны хөрмәтләп, мемориаль такта янына чәчәкләр салды.

**Драматург Туфан Миңнуллин Мунчәли халкына заман таләпләренә туры килердәй белем йорты төзергә ярдәм итә. 2009 елда аңа «Мунчәлинең мактаулы гражданы» дигән исем бирәләр.**

**«БРЕНДЛАРНЫ ТАНЫТАБЫЗ»**

Мунчәлинең 510 еллыгына һәм Авыл бәйрәме үткәрелүгә ун ел тулуга багышланган чара Мәдәният йортында дәвам итте. Җырчы Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге ТР фольклор музыкасы дәүләт ансамбле һәм танылган артистлар катнашында концерт булды.

«Татарлар төрле җирләргә сибелеп яшәсә дә, аларның Ватаны бер, – диде Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрид Фәиз улы Мифтахов. – Туган якларыбызга кайтып, дини бәйрәмнәр үткәрү, тамырларыбызны барлау, авылдашлар белән күрешү – бик күркәм күренеш. Кайвакыт, алар нәрсәгә кирәк соң, дигән сорау туа. Мондый чаралар ярдәмендә без татар тарихын өйрәнәбез, авылларыбызны саклап калу өчен өлеш кертәбез. Дини җыеннар, авыл халкы белән очрашу шул төбәктән чыккан шәхесләрне барлау, күренекле кешеләрне искә алу белән үрелеп бара. Шулай итеп, без авыл аша хәзерге күренекле шәхесләрне дә яңа яктан ачабыз, бәлки, яңа исемнәрне дә тудырабыз. Бу бит район үсеше, аны таныту өчен генә түгел, дәүләт өчен дә зур, әһәмиятле эш».

Чүпрәле районы башлыгы Александр Шадриков та сүз алды: «Туган якны яңартып, без Русияне яңартабыз, аякка бастырабыз, дигәннәрме әле? Мунчәли авылы бу яктан чын мәгънәсендә изге эшләр башкара. Үз туган ягын үстерүгә өлеш керткән, милләтенең иминлеге өчен янып-көеп яшәгән кешеләрнең безнең арада булуы – зур куаныч».

Мунчәли авылы ике герой – Нурулла Фазлаев һәм Габдулла Сабирҗановларны биргән авыл да. Мунчәли мәктәбендә татарның билгеле каләм әһелләре – Шәрәф Мөдәррис, Зәки Нури, челтерәп аккан чишмә тавышлы опера җырчысы Венера Шәрипова да белем алган. Халык ул исемнәрне күңел түрендә йөртеп, искә ала. «Мунчәлием, син минем йөрәк тибешем!» дип халык юкка гына әйтмәгән шул.

«Тарихны өйрәнү, гореф-гадәтләрне яңарту, шәҗәрәләрне барлау, Мунчәлидән чыккан күренекле шәхесләр турында мәгълүмат туплау максатыннан Авыл бәйрәме оештыра башлаган идек, – диде район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Айрат Җәлалов. – Мондый чаралар Мунчәлидә үскән, моннан чыккан кешеләр өчен очрашуга мөмкинлек тудыра. Авыл көне Мунчәлинең саф һавасын сулап, яшь чакларны искә төшереп, әби-бабаларның каберләрен зиярәт кылу, үз тамырларыңны искә алу өчен аеруча әһәмиятле. Мишәр авылында мондый бәйрәм үткәрелүе – икеләтә шатлык. Шулай итеп, без брендларыбызны, үзенчәлекләребезне башкаларга танытабыз, аларны тагын да үстерәбез».

Халыкны бергә тупларга, берләштерергә, читтә йөргән якташларны кайтарырга, туган якка булган карашларын үзгәртергә һәм бергәләшеп авылны сакларга, якларга, үстерергә кирәк. Моның өчен укулар оештырыла, авыл тарихы языла, авыл бәйрәмнәре дә уздырыла. Мунчәли авылы – моның матур үрнәге.



Рамилә Нотфуллина

# НУРМЫЙ БАБАЙ ИГЕЛЕГЕ



Фото Мәннановларның гаилә архивыннан алынды

Алтмышынчы еллар урталарында Теләче районы Олы Нырсы авылына Башкортстаннан Нурмөхәммәт Мәннанов кайтып урнаша. Һәм... Олы Нырсы, Кече Нырсы, Бичер авыллары янәшәсендәге Изгеләр зираты, Изгеләр чишмәләрен тәрбияләп, тазартып торырга алына.

Лаеклы ялга чыккач та авылга кайткан Нурмөхәммәт бабайга җирле халык, үз итеп, Нурмый бабай дип тә эндәшә. Ул кайткан мәлдә «Зөлката» зиратында (Изгеләр зиратын шулай дип тә атыйлар) тәртипсезлек хакимлек итә: агачлар ауган, инеш басмалары бик начар хәлдә... Нурмөхәммәт бабай берүзе, беркемнән дә ярдәм сорамыйча, зират тирәли баганалар утыртып, әйләндереп койма тота. Кешеләр биргән хәер-садака акчасына ул буяу сатып алып, зиратның киртәләрен буяп чыга. Изгеләр зиратын череп ауган агачлардан арындыра. Нырсы урманыннан агач үсентеләре алып төшеп, рәт-рәт итеп төрле агачлар утырта. Алар бүген бер җеп белән сузып утыртылган кебек каршы ала. Нурмөхәммәт бабайның игелекле куллары чишмәләргә дә юл ача. Язгы ташу вакытында төшкән пычрак, агач ботаклары, ләм һәм вак ташлардан чишмә суларын чистарта ул. Ни гаҗәп, үзенә игътибар иткән өчен рәхмәт белдергәндәй, Изгеләр зиратында кошлар сайрый башлый, инешкә кыр үрдәкләре янә очып килә, чишмә сулары ишәя.

Нурмөхәммәт Мәннанов чыгышы белән Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авылыннан. Өйләнгән, биш бала – бер кыз, дүрт ул үстерә. Хәзерге вакытта балалары Мәскәү, Уфа шәһәрләрендә, Төркиядә яши. Әтиләренең дини белемле, Коръән сүрәләрен яттан белүе турында уллары Рәшид, Мәлик тә искәртә: «Коръән сүрәләрен укып кына калмыйча, аның мәгънәсен белүе һәм башкаларга да шуның асылын җиткерергә омтылганын хәтерлибез, – дип сөйли алар. – Уфада яшәгәндә, дини бәйрәмнәрдә әти еш кына мулла кебек өстәл түрендә догалар укый иде. Бәйрәмгә килгән кунакларга, туганнарга шул догаларның мәгънәсен аңлата иде. Аннан соң, бергә-бергә тәмле ризыклар ашап, тәм-томнар белән күңелле итеп чәй эчә идек». Нурмөхәммәт абый яшь чагында ике-өч класс мәдрәсә тәмамлаган булган. Бу аңа, гомер буе гарәпчә китапларны аңлап укырга мөмкинлек биргән.

Изгеләр зиратында сугыш корбаннары – татарлар җирләнүе хакында, әлеге урынның нык хөрмәткә лаек булуы турында Нурмөхәммәт абый бик яхшы белгән, күрәсең. «Моннан бик күп гасырлар элек хәзерге Нырсы җирлекләрендә дин өчен канлы зур сугыш булган, – дип сөйли иде Олы Нырсы авылында туып, гомер буе шунда тормыш иткән әбием Сәлимә Гыйльметдинова. – Көтмәгәндә, таң белән, авылга басурманнар бәреп керә. Иртәнге намаз вакытында өч бертуган Сәгыйдәбану, Шәһидәбану, Заһидәбануның башлары дошман кылычыннан үткәрелә. Бу хәлләргә ярсыган аталары – Зөлмөхәммәт, авыл һәм тирә-якта яшәүче ир-атларны җыеп, зур көрәшкә

**ХАЛЫККА ФАЙДАСЫ ТИЯР КЕШЕ – ИЗГЕ КЕШЕ (ХӘДИС)**

күтәрелә. Сугыш канлы һәм аяусыз була. Нырсуар елгасы кан булып аккан, диләр. Изге жаннарны бик зурлап, Изгеләр зиратына күмәләр».

Изгеләр зиратында бик борынгы кабер ташлары да сакланган. Мәсәлән, 1357 елда җирләнгән Сөләйман улы Шәех, 1399 елның 19 сентябрендә 36 яшендә якты дөньядан киткән Ибраһим улы Исхак, 1443 елның июнь аенда вафат булган Йосыф Шәйех углы, 1472 елның 6 декабрендә вафат булган Мөхәммәд углы Әйүб дип билгеләнгән кабер ташларының затлы, кыйммәтле булуы күзгә күренеп тора. Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов аларны җентекләп өйрәнгән. Галим билгеләвенчә, әлеге зираттагы ташларда искә алынган мәрхүмнәрнең исемнәре Казан ханы Сәхиб Гәрәй хан тарафыннан 1523 елның 3 гыйнварында Тарханлык ярлыгы бирелгән затларның исемнәре белән туры килә. Шуңа өстәп, янәшә торган ике таш бер нәселнең буыннары икәнлегенә ишарә. Ярлыкта әлеге нәселнең ничә буыннар заманында ханнар ярлыгы буенча тарханлык катлавына кертелгәннәре күренә.

Рузилә Габитова фотосы



Авыл халкы Нурмөхәммәт бабайга рәхмәтле. Тумышы белән бу яктан булмаса да, халык үз итте аны. «Зөлката», Нырсы суы, Бичерхан турындагы бәет-риваятьләрне, «Изгеләр»не зурлавы, зиратта эшләнергә тиешле гамәлләрне саклап килүенә куанмаслыкмыни? Табигате белән тәрбияле, тыныч холыклы, дини белемле Нурмөхәммәт бабай, кем генә үтенеч белән килсә дә, ярдәм кулы сузарга ашыккан. «Әйдәгез, балалар, шифасы булсын, узыгыз. Болай итеп карыйк әле... Аллаһының кодрәте киң», – дип, авыруларны өшкергән. Көмештәй чиста Изгеләр чишмәләренең суы белән авыру кешеләрнең күз, колакларын сыпырып, тәннәрен юдыртып, Аллаһтан аларга тәүфыйк, бәхет, сәламәтлек сораган. Аннан соң, авыруны Изгеләр зиратына алып менеп, җиде тапкыр әйләндерткән. Зират янында Нурмөхәммәт бабай бәләкәй генә йорт та төзеп куйган. Намазлык өстендә гыйбадәт кылу өчен җыйнак кына, бик чиста һәм тыныч урын була ул.

– 1962-1963 елларда без гаиләбез белән пароходка утырып, Балык Бистәсенә кайттык, – дип күңел хатирәләрен барлый улы Рәшид Мәннанов. – Әти юл буе үзенең иң өстендә авыр тимер рәшәткәләрне күтәреп кайтты. Олы Нырсы зиратындагы каберлекләрне әйләндереп алу өчен иде алар. Хәзер аларның күпме булуын төгәл генә әйтә дә алмыйм. Әмма коймаларның утыз-кырыктан да ким секциясе булмагандыр. Гаиләбез өчен бу бик зур чыгымнар торса да, әнкәй әтигә карышмас иде.

Гомер буе Нырсы ипиханәсендә эшләгән Әлфия апа Гәрәева сөйләвенчә, Нурмөхәммәт бабайның яшәгән йорты бик чиста, төзек һәм пөхтә булган. «Авылга кайтып төшүгә, ул һәр көнне эшкә барган сыман, Изгеләр зиратына юл тота иде, – дип сөйли Әлфия апа. – Зират тирәләрен чистартты, яшелләндерде, чишмәләрен тернәкләндерде. Бар көч-кодрәтен, мөмкинлеген Изгеләргә багышлады. Әле күптән түгел генә Изгеләр зиратына машина белән барып кайттык. Нурмөхәммәт абыйның зират янәшәсендә төзегән өен төзек, чиста күреп, сөендек. Шәһәр өе кебек матур ул... Андагы кыйммәтле намазлыклар, затлы тәсбихләр, йомшак мендәрчекләр, утырып торырга хәтта уңайлы бүкәннәр куелган... Без, абыстайлар, бүген дә: «Изгеләр зиратын тәрбияләгән, чишмәләрен караган Нурмөхәммәт абыйга» – дип, аның рухына багышлап дога кылабыз».

Нурмөхәммәт абый үзенең үткәне турында беркайчан да сөйләмәгән. Өлкәннәр әйтүенчә, аның тормышында авыр вакыйга булган, шуннан котылу өчен нәзер әйтеп, үзен шушы Изге зиратка багышлаган, дигән сүзләр генә йөри. Нурмөхәммәт бабайның рухи ныклыгына сокланып, кешеләр аны Изге кеше, дип таный. Бабай вафат булгач (1988 елда), Изгеләр зиратына җирлик, дигән фикер дә әйтелә. Ләкин аны, үзенең васыяте буенча, туган авылында гүргә иңдерәләр. «Зөлката» Изгеләр зираты авыл советы карамагында кала.

Нурмөхәммәт Мәннановның халык өчен кылган игелеге юкка чыкмый. Чишмәгә килгән һәркем татлы суга кинәнә. Ә борынгы зиратта төзекләндерелгән кабер ташлары, шаулап утырган агачлар татар бабаена баш иядер!..

Энҗе Басыйрова

# КЫЙБЛАСЫННАН БАРЫБЕР ТАЙПЫЛМАС ИДЕ

«Дөньяда комсыз булма, сине Аллаһ яратыр, кешеләр кулындагыга кызыкма, сине халык яратыр», ди пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең хәдисендә. Бар булганына шөкер итеп, халкы өчен җан атып яшәгәнгәдер, күренекле мөселман эшлеклесе, Татарстанның баш мөхтәсибе һәм казые булган Габделхак хәзрәт Саматов та, арабыздан киткәненә шактый гомер узса да, күңелләрдә моңлы бер җыр булып яши. Әңгәмә корганда дин әһелләре дә, намазлы гади кешеләр дә мәшһүр казый турындагы хатирәләрне яңартмый калмый. Аның дингә тугрылыгы, бәлки, туган җире Аксубай районы белән дә бәйледер. Ул яклар, Самара, Ульян өлкәләре элек-электән диндарлыгы белән аерылып торган бит. Хәер, ничек кенә булмасын, дини хезмәтенә генә түгел, тормыш юлына күз салсаң, үзен мөселман дип санаган һәркем шулай яшәргә омтылырга тиеш, дигән фикергә киләсең. Анда иман ныклыгы да, дин юлында куелган көч тә, фидакяр хезмәт тә, мәхәббәт тә, гаилә дә – һәммәбез өчен үрнәк булырлык. Мөхтәрәм хәзрәтнең олы кызы Фирдәвес ханым белән очрашып сөйләшкәч, әнә шундый нәтиҗә ясадым.



*Габделхак хәзрәт Саматов балалары, оныклары арасында*

Гаиләдә дүрт бала үсә: Фирдәвес, Саҗидә, Таһир һәм Хәлил (*Таһир һәм Хәлил Саматовлар хәзер үзләре үк күренекле дин әһелләре,* – ***авт.***). Алар гади, тыйнак тормышта тәрбияләнәләр. Ун елдан артык Габделхак хәзрәтнең бертуган абыйсы Кәнзелголүмнең гаиләсе белән бергә, уңайлыклары урамда булган кысан баракның ике бүлмәсендә яшиләр. Ун бала бер йодрыкка әйләнә... 1954 елда Габделхак армиядән кайтып төшүгә үк, менә шушы бердәнбер абыйсында туктала һәм шундук шофер булып эшкә урнаша. Бу вакытта инде Кәүсәрия, буй җитеп, бер кашык су белән йотарлык кәләш булып өлгерә. Егетне өйләндерү турында сүз чыгып, бер танышлары: «Авылда Кәүсәрия исемле кыз бар. Беркемгә карамагыз, шуны алыгыз», – дигәч, тимерне кызуында сугарга яраткан Габделхак авылга хат язып сала. Икенче җомгада инде кызның кулын сорарга кайтып җитә. Ике көн дигәндә, никах укытып, туй итәләр. Үзләре әйтмешли, ике күреп, бер сөйләшеп, гомерлек ярга әйләнәләр. Күрәсең, кызның кечкенәдән ястү намазын укыганда, намазлыгы юешләнеп беткәнче елый-елый кылган догалары, теләгән теләкләре кабул була. Сәҗдәгә киткәндә Аллаһыга кол, пәйгамбәргә өммәт булырлык, киң холыклы бәндә, тигез мәхәббәт сорый ул. Бергә оя коргач: «Кеше килсен, кайгы килмәсен», – дигән сүзләр тормыш девизына әйләнә. Шулай булмаса, кысан барак бүлмәсенә Казанга хастаханәгә ятарга, укырга керергә, суган сатарга һ.б. йомыш белән авылдан килгән һәркем сыяр, айлар буе яшәр идеме икән? Әлбәттә, юк. Әле бит яңгыр-мазар яуса, юешләнмәсен дип, сатарга дигән суганны да алып керәләр. Заманасы, буын башка булган дип, гаҗәпләнергә генә кала. «Ике бертуган арасындагы мәхәббәт һәм хөрмәткә әле дә шаккатам, – ди Фирдәвес ханым. – Әллә инде гаиләдә берсе – иң өлкәне, икенчесе – төпчек, калганнары мәрхүм булганга шулай яраттылармы икән бер-берсен, дип тә уйлыйм. Һәр эштә киңәшләшерләр, бөтен борчу-мәшәкатьләрне уртага салып сөйләшерләр, бергә хәл итәрләр иде. Безгә аерым фатир биргәч, йөрергә ерак дип, әти Кәнзелголүм абыйлардан аерылырга теләмәде хәтта. Торакны башкага алыштырдык. Әни белән соңгы көнгә кадәр шунда – Волгоград урамында ике бүлмәле «хрущевка»да яшәделәр».

Габделхак хәзрәт егерме елга якын машина йөрткәннән соң, авыр эшкә – беләге, ә кыю эшкә йөрәге булгач, дин таратырга уңайлы җир дип, Мәрҗани мәчетенә слесарь эшенә күчә. Дини өлкәдәге төпле эшчәнлеге дә шул чагында бөреләнә.

Хөрмәт сөйсәң, хезмәт тә сөй дигәндәй, хәләл көч белән көн күрә Саматовлар гаиләсе. Кәүсәрия абыстай да ир көе көйләп өйдә ятмый, дары заводында егерме елдан артык бил бөгә. Орчык кадәрле хатынның башкалар белән беррәттән җитмеш килолы капчык ташуын күз алдына китерүе кыен. Гаиләсен ашату өчен, хәзрәтнең тегү теккән, аяк киеме төзекләндергән вакытлары да була. Шуңа да карамастан, белемгә омтыла, җай чыгуга, кычкырып Коръән укый, аны ятлый. Балаларын да кечкенәдән дини юлда тәрбияли. Моннан берничә ел элек «Идел» журналы өчен әңгәмә корганда уллары Таһир хәзрәтнең: «Кечкенәдән Мәрҗани тузанын сулап үстек. Мәчеттә ремонт ясарга кирәкме, хуҗалык эшләре җыелганмы, һәммәсендә катнаша идек», – дип сөйләгәне истә. Гаилә башлыгының максаты ул-кызларының күңелендә дин сабагын ныгыту була. Эштән кайтып керүгә, алдагы көндә өйрәнергә кушкан сүрәне кабатлата, тыңлап карый. Аннары балаларын буй озынлыгы буенча тезеп бастыра да, бергәләшеп намаз укыйлар. «Әтинең бөтен теләге безне Аллаһыны танучылар итеп үстерү булды, – ди Фирдәвес ханым. – Үзе дә гел укыды. Ул заманда дин тыелган, белем эстәргә качып-посып баралар иде. Әтинең, җыенып, өйдән чыгып китүе, фильм караган кебек, әле дә күз алдымда тора... Әнә, эштән кайта, ашый-эчә дә әкрен генә җыенырга керешә. Читтән генә күзәтәм: бүген мине үзе белән алырмы икән? Йөрәк дөп-дөп тибә. Әти эшләпәсен башына элде, хәзер чыгып китә, ә миңа дәшми! Дүрт күз белән аңа карыйм. Менә инде борылып чыгып киттем дигәндә генә «нәрсә, барасыңмы соң», дип ымлап, серле елмая. Утырган җиремнән сикереп торам. Әти әнигә кызчыгын киендерергә куша. Ул минутларда миннән дә бәхетле кеше юк...»

Габделхак Саматов ике улын кырыс Себер якларына «сөргенгә» озаткан хәзрәт тә әле. Таһир белән Хәлилне Казанда калдыру мөмкинлеге булса да, «сез анда кирәгрәк, динне таратыгыз, әҗер-савап алырсыз», дип, каты тора. Хәзер инде Таһир – Сургут, Хәлил – Когалым шәһәренең абруйлы имамнары. Таһирнең улы Камил дә Сургутта җәмигъ мәчете имамы вазифасын үти. Хәер, заманында, мулла булып эшли башлагач, Габделхак Саматов үзе дә, ун ел буе кая җибәрсәләр, шунда бара. Башта биш ел Әлмәттә, аннары Оренбургта эшли. Хәрби кебек, шулай бер урыннан икенчесенә күченеп йөрсә дә, тормыш сынауларына сабыр итә. Балаларының колагына киртләгән сүзе дә «сабыр итегез» дию була. Бу – дәшми калу, вакыйгаларга кысылмыйча, читтә тору түгел, ә акыл белән эш итүгә корылган сабырлык. «Әти дә, әни дә сабыр булды, –

ди әңгәмәдәшем. – Сүзгә килсәләр дә, бер-берсенә карата канәгатьсезлекне пышылдап кына әйтәләр, без читтән генә кызыксынып күзәтә идек. Әтинең безне ачуланганда әйткән иң каты сүзе «оятсыз» дию булгандыр, мөгаен». Әйе, күркәм кием тән зиннәте булса, күркәм холык – җан зиннәте һәм игелекле юлдаш та әле. Килеш-килбәте, әнә шул күркәм холкы, эш-фигыле һәм, әлбәттә, хәзинәгә тиң белеме өчен Габделхак хәзрәтне халык ярата да инде, һәр сүзен йотлыгып тыңлыйлар. Вәгазе күңелгә үтеп керә, тавышы ягымлы, үзе ипле, нечкә күңелле.

Габделхак хәзрәтнең яшәү дәверендә берәүгә дә яраклашмау сыйфаты исә аерым игътибарга лаек. Әле дә аның шул ягын бик еш мисал итеп китерәләр. Коръән ничек куша, шулай гамәл кыла ул. Әлмәттә эшләгәндә берсендә шулай Фәрит Мөхәммәтшин аны үзенә чакырта хәтта: «Хәзрәт, халык синнән зарлана, никах укырга теләмичә чыгып китте, дип хат язганнар», – ди. Имам Коръән аятьләре, хәдисләр белән аңлатып, фикерен җөпләп бирә: никах укыганда кияү белән кәләш иман китерергә тиеш. Ә алар мәҗлескә килгәч, иман кәлимәсен укудан баш тарта, мин – комсомол, диләр. Мин исә үземне мулла дип, никах укымыйча китәм. Җитәкче җавапсыз кала. Хәзрәт иман китермәгәннәргә никах уку түгел, әмәрхүм кешене табутка салып, музыка белән соңгы юлга озатканда да җеназадан кайтып китә торган була. Кыскасы, заман модасына иярми. Шул сыйфаты аркасында шактый авырлыкларга да юлыга. Тик ул үзен җәберләсәләр дә дәшми кала. Аллаһ Тәгалә барысын күрә бит, дип күңеленнән генә үзен рәнҗеткән бәндәләрне кичерә дә үз юлыннан атлый бирә. «Әтинең өстәлендә төрле җитәкчеләрнең визит карточкалары бер кочак иде, – ди кызы. – Ә аңа: «Әти, шундый йомыш бар, танышларың күп бит, шылтырат әле берәрсенә», – дисәң, җавапны кыска тота: берсен дә белмим, ул карточкаларны үзләре калдырып китә, сорап алмыйм, ди. Берсендә хәлле генә бер кеше йөз квадрат метрлы фатир алгач, Коръән ашына әтине чакырган. Болын кадәр торакта хатыны һәм баласы белән генә яши, сабые велосипедта йөри икән. Әти шуннан кайткач үзенә урын таба алмады: авыр хәлдә яшәүчеләр өчен гарьләнеп елады. Ә бервакыт ул бер гарәпне кунарга үзләренә алып кайткан. Икенче көнне тагын кунарга кайтырга тәкъдим иткәч, чит ил кунагы: «Күңелең киң, тик фатирың кысанрак», – дип, килергә уңайсызланган. Бу хакта ул чактагы шәһәр мэры Камил Исхаковка әйткән. «Абруйлы хәзрәт шундый шартларда яши», – дип, җитәкчене оялтырга маташкан. Камил әфәнде әтине чакыртып, яшәп торырга зуррак, иркенрәк фатир бирәбез, дигәч, әти янә әрнеп кайтты. «Яшәр урыным була торып, ничек инде, халыктан оялмыйча, фатир алыйм? Без бит ике бүлмәле фатирда икәү генә! Башкалар тулай торакта да, подвалда да яши», – дип шактый тынычлана алмый йөрде». Ахыргы көннәренә кадәр шул фатирда яши ул. Гомеренең соңгы биш елын авырып уздыра, урын өстендә ята. Әмма бервакытта да намазын калдырмый. Ә пар канаты Кәүсәриясе яныннан китми, бала карагандай тәрбия кыла.

Хәзер дин акча эшләү рәвешенә кайтып калды, дигән сүзләр еш яңгырый. Ниндидер агымга эләгү ихтималың да бар. Габделхак хәзрәт исән-сау булса, мөгаен, үз кыйбласыннан барыбер тайпылмас иде, дөресрәге, ялгыш юлга керергә ныклы иманы ирек бирмәс иде аңа. Күрәсең, әнә шул ихласлыгы өчен догалары да кабул булган: балаларының, оныкларының һәркайсы дин белән яши, тормышлары җитеш, бәрәкәтле, дәрәҗәләре бар, халык хөрмәт итә үзләрен. Тик менә җор телле, йөзеннән бервакытта да елмаю сүнмәгән Габделхагын югалткан Кәүсәрия абыстай гына канаты каерылган кошка охшап калган. Аны ире турындагы җылы хатирәләр генә яшәтә кебек...



*Җор телле, йөзеннән елмаю сүнмәс хәзрәт*



Радик Сабиров

# ЯШӘҮЧЕ ЯШӘРГӘ ТИЕШ!

**«Төп максатым – авылны яшәтү һәм таныту» – берничә ел дәвамында Илшат Харисов әнә шундый изге, ихлас теләк белән 32 йортлы Яшәүче авылында гаҗәеп Сабан туе оештыра. Чирмешән районындагы Яшәүче авылы өчен генә түгел, күрше авыллар, күрше районнар өчен дә иң истә калган бәйрәмгә әверелә ул. Быел биредә «Идел» журналы хәбәрчесе дә булып кайтты.**

Бу авыл һәм биредәге Сабан туе турында күптән ишетеп беләм. Чөнки бирегә республиканың танылган сәхнә йолдызлары һәм көчле көрәшчеләре килә. Сәбәбе гади: шушы авылда туып үскән, бүгенге көндә Әлмәт районында хезмәт итүче Илшат Юныс улы Харисов – җитмештән артык җыр авторы һәм заманында Чаллыда танылган тренерларда шөгыльләнгән көрәшче. Әнә быел да бәйрәмгә Зөһрә Шәрифуллина, Лилия Муллагалиева, Алсугөл, Закир Шаһбан кебек җырчылар һәм исемнәре бөтен республикага танылган Булат Мусин, Динар Гатиятов, Руслан Хәмидуллин, Пунхан Наджафов кебек көрәш осталары, Алмаз Заһретдинов, Фәнил Залаков кебек остазлар һәм хөкемдарлар кайткан иде.



**ЗӨҺРӘ ШӘРИФУЛЛИНА: «ЯШӘҮЧЕ АВЫЛЫНДАГЫ САБАН ТУЕНА БЕРЕНЧЕ КАЙТУЫМ. ГӘРЧӘ ИЛШАТ БЕЛӘН УЛ ЧАЛЛЫДА ЯШӘГӘН ВАКЫТТА УК ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТӘБЕЗ. АНЫҢ ШИГЫРЬЛӘРЕНӘ ЯЗЫЛГАН ҖЫРЛАРНЫ БАШКАРАМ. «БЕЗ – МИШӘРЛӘР» ДИГӘН БИК МАТУР ҖЫР ИҖАТ ИТТЕК. МИНЕМ ИРЕМ ДӘ БУ ЯКЛАРДАН, ШУҢА МИШӘРЛӘРГӘ БЕРНИНДИ НАЧАР СҮЗ ӘЙТӘ АЛМЫЙМ, МИШӘР ЕГЕТЕ БЕЛӘН ЯШИ-ЯШИ ҮЗЕМ ДӘ МИШӘРГӘ ӘВЕРЕЛЕП БЕТТЕМ ИНДЕ. УҢГАН, БУЛГАН ХАЛЫК».**





## ХӘЙРУЛЛИН ДА, КУЛАК ОНЫКЛАРЫ ДА ЯРДӘМ ИТӘ

Яшәүче авылының тарихы әллә ни озын гомерле түгел. 1929 елда күрше Кармыш авылыннан күчеп килгән кешеләр нигез сала аңа. Иң зур вакытларында да 79 йортта 450ләп кенә кеше яшәгән. Әмма табигате, урнашкан җире гаҗәеп. Авыл үзе үзәнлектә урнашкан, әмма тирә-ягы таулар белән әйләндереп алынган. Ул тауларда, Кавказ якларын хәтерләтеп, матур-матур чишмәләр челтерәп ага. Моннан дистә ел элек Яшәүче авылында Сабан туйларын янә торгызып җибәргән Фаил абый Мортазинга мөрәҗәгать итәм:

– 60 яшемә кадәр «Ямашнефть»тә эшләдем. Авылга кайтып йөри идек. Берзаман, пенсиягә чыккач, хатыным белән кайткан идек тә, туган авылда төпләнеп калдык. Кайтуга ук авылның 80 еллыгын билгеләп үттек. Шул вакытта иллешәр ел күрешмәгән кешеләр очрашып киткән иде. Һәм Сабан туе уздыру идеясе дә туды. Хәзер кайчандыр авылыбыздан чыгып киткән кешеләр ел саен булмаса да, ара-тирә шул бәйрәмгә дип кайталар, рәхмәтләрен укыйлар. Шуның белән бергә, авылны яшәтү теләге дә ныгый бара. Бездә хезмәт сөючән, тырыш халык яши. Күпләп мал асрыйлар. Инде яңа йортлар пәйда була башлады. Социаль объектларыбыз да, Аллага шөкер, бар, эшләп тора. Авылыбызның икенче, рәсми исеме дә бар: Әшәлче.

Сабан туйлары мин кечкенә чакта да уза иде. Бәйрәмгә кадәр бер-ике атна кала, яшьләр үзара җыелышып, җыеннар уздыралар, бииләр, җырлыйлар... Тирә-юнь авыллардан да килә иде яшь җилкенчәк. Менә бу әрәмәлекләрдә кыр казлары, үрдәкләр, чиләннәрне хәтерлим әле.

Спонсор-иганәчеләребез дә җитәрлек, Ходайның биргәненә шөкер. Быел да бәйрәмне уздырыйк әле дип, районга барган идек, Дәүләт Думасы депутаты Айрат Хәйруллинның кабул итү көненә туры килдем. «Мин сезнең авылдан булсам, ярдәм күрсәтер идем дә бит», – дип җавап бирә башлаган иде, «Без бит сезне авылдан түгел, шушы округтан сайладык», – дигәч, килеште, булышырга булды. Район башлыгы Фердинанд Дәүләтшинга да рәхмәт, ул да ярдәмен кызганмады.

Илшат – молодец егет! Анда да хат яза, монда да. Каршы килүчеләр дә юк бит, Ходайның рәхмәте. Кемерово, Красноярскилардан кадәр ярдәм итүчеләр табыла. Әнә теге тау башында исә Лишуннар тавы урнашкан иде. Теге зәхмәтле елларда байларны, кулакларны Себергә сөргәндә, гаиләләрен менә шунда калдырганнар, землянкаларда яшәгәннәр, бәгырькәйләрем. Тирә-юнь авылларга төшеп, хәер-садака сорап көн күргәннәр. Менә шунда яшәүчеләрнең балалары-оныклары бүген Кемерово, Красноярскида гомер кичерә.

## БАР ДА БҮЛӘК АЛА

– Елның елында киләсе Сабан туена әзерлек алдагысы тәмамлануга ук башлана, – ди Фаил абыйдан эстафетаны кабул итеп алган Илшат Харисов.

Әлеге сүзләргә бик җиңел ышанам. Бер тауны хәтерләткән җыелган бүләкнең иге-чиге юк кебек. Мәйданга керүгә үк шуңа игътибар иттем: Сабан туе мәйданы авылның үзеннән дә зуррак сыман. Нинди генә аттракционнар эшләми дә, нинди генә уеннар оештырылмый биредә. Бала-чага рәхәтләнә: алар, теге яки бу уенда катнашып, бүләкләрне дә үзләре сайлап алу бәхетенә ия. Аннан килеп, төрле авыллардан җыелган ир-егетләр, хатын-кызлар, командаларга бүленеп көч сынаша. Кайберләрендә бер үк авылдан булганнар ярыша. Әйтик, аркан тарту бәйгесендә Түбән Кәминкә авылының бер оч егетләре белән икенче очныкылар очрашты... Бәйрәм дәвамында югарыда телгә алынган җырчылар чыгыш ясый.











Шунысы кызык: бәйрәмне уздырырга ярдәм итүчеләр Яшәүченекеләр генә түгел. «Бу эшкә Елховой, Кармыш, Түбән Кәминкә, Ак Бүре кебек авыллардан чыгучы якташлар да ярдәм итте. Алланың биргәненә шөкер, бәйрәмдә катнашучыларның берсе дә бүләксез калмады», – ди бу уңайдан үзе алып баручы, үзе бүләк ташучы, үзе ашатучы-эчертүче, халыкның күңелен күрүче Илшат Харисов. Әнә, танылган көрәшче, эшкуар, җырлар авторы, тумышы белән Чистай районының Каргалы авылыннан булган Рәис Гыймадиев башта гер күтәрүчеләргә өстәмә акчалата бүләк бирә, аннан кунаклар арасында баш батыр калган Булат Мусинны туган көне белән котлап, болай да күп бүләк алган егетне тагын да баета.

Әнә, әнисе шушы авылдан булган Чаллы эшмәкәре Гөлфия Васинаның көрәштә җиңү яулаган кызларга туннар алырга сертификатлары тапшырыла. Шундый ук бүләк «Иң зур бавырсак пешерүче» бәйгесендә (моны бары тик Яшәүчедә генә күрергә туры килде) җиңгән Фәния Мөнировага да бүләк ителә. Ә Фәния апаның малае исә авыл көрәшчеләре арасында баш батыр булып кала. Димәк, 52 яшендә тәкә откан Мохтар Кәримовка да алмаш үсеп килә: баш батыр аның сеңлесенең малае бит! Бәйрәм барышында авылның иң өлкән кешесе, 84 яшендә дә намазын, уразасын калдырмаучы Габделәхәт Якупов та, быел үзләренең юбилейларын билгеләп узучылар да, 10, 15, 20, 30, 40 ел бергә яшәүчеләр дә, бәйрәмне оештыручылар да – бар да, бар да бүләк ала биредә! Афәрин!

Һәм тагын бер нәрсәгә игътибар иттем. Яшәүче авылы Сабан туенда мин егылып ятучы исерекләрне дә, тәртипсезләнеп йөрүче яшьләрне дә, тавыш куптаручыларны да очратмадым. Янә бер афәрин!

### ИЗГЕ ТЕЛӘК

Илшат Харисов авылны яшәтүгә үзеннән зур өлеш керткән Чирмешән районы башлыгы Фердинанд Дәүләтшинга, районның авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Мирзаһит Гатинга рәхмәтле. «Авылыбыз кечкенә дип тормадылар, ФАП та, яңа клуб та төзелде, «Чиста су» программасы нигезендә сулы да булдык», – ди Сабан туен оештыручы. Сүз уңаенда, бу көнне Илшатның әнисе (бик иртә алты бала белән тол калган, бар балаларына югары белем биргән олы йөрәкле ана ул) бу көнне өйне тутырган кунакларны каршы алу, ашату-эчертү, озату белән мәшгуль иде. Сабан туена да килеп китте әле. Илшатның үзенә исә энесе Ирек ярдәм итеп йөрде. «Абый, абый!» дип торуын күзәтүе – үзе бер рәхәт!

...Авылдан чыгып киткәндә, кояш инде байый иде. Йөзләгән машина, тузан калдырып, авыл белән саубуллаша. Киләсе елга машиналарның саны тагын да күбрәк булыр, мөгаен. Авыл эчендәге йортлар каршында да машиналар тезелгән: балалар туган нигезгә җыела... Күңелдә бер уй: әйе, Яшәүче яшәргә тиеш!..



Эльвира Шакирова

# БАШКОРТСТАН ҖЫРЧЫЛАРЫ ГАДИ. ЧӨНКИ АЛАР АРТТА КАЛГАН?




Уфада Башкортстанда яшәүче татар һәм башкорт артистлары катнашында ябык кичә үтте. «Туган тел» музыкаль каналы оештырган бу чарада җырчылар беренче тапкыр кызыл келәмнән узды. Шунысы кызык: бу кичәгә Татарстаннан бер артист та чакырылмаган. Журналистлар арасында бердәнбер чакырылган кунак булуымны белгәч, Уфага бару мөмкинлеген кулдан ычкындырмадым. Бирегә баруымның тагын бер сәбәбе – Башкортстан эстрадасы белән якыннанрак танышу.

### «ШУЛЮМ»НАН БАШЛАНГАН МӘХӘББӘТ

Уфа мине чын мәгънәсендә колач җәеп каршы алды! Үзендә кунак итәргә теләүчеләр күп булса да, Башкортстанның популяр җырчысы Марат Шәйбәков нәкъ менә аларга баруымны теләде. Каршы килмәдем. Марат һәм аның гаҗәеп тормыш иптәше Ләйсән мине «шулюм» дигән шулпалы ризык белән сыйлады. Шәйбәковлар турында бер-ике сүз генә әйтеп үтәсем килә. Мондый гаиләләр бармак белән генә санарлык. Кунакчыл, киң күңелле, юмарт булуларына ишектән килеп кергә инандым. Ләйсәнгә аерым рәхмәт, чөнки һәркем дә белмәгән хатын-кызны каршы алырга, аны өенә алып кайтырга ирен төн уртасында чыгарып җибәрми. Марат белән Ләйсән Марсель исемле ул, Ралинә исемле кыз үстерә.

Марат Шәйбәков – үтә дә төгәл кеше. Ябык кичә буласы урынга, соңга калмас өчен, бер сәгать алдан килеп бастык. Без барганда, Илшат Вәлиев башка артистлар белән сөйләшеп тора иде. Казаннан җырчылар чакырылмады, диделәр, ә Илшат бит Казанда яши! Дөрес, тумышы белән ул да Башкортстаннан. Ябык кичәгә ничек килеп эләккәнен сорагач: «Мин – монда туып үскән кеше, туган якка кайттым», – диде җырчы Илшат.

### БАШКОРТСТАНДА БАР ДА ҖЫРЛЫЙ

Артистларның барысы да матур киенгән, чәчләр ясаткан, бизәнгән. Килә торганы бер-берсен җылы сәламли, кочаклаша, аралаша. Мондый татулыкка сокланып та куйдым. Кызыл келәмнән беренче тапкыр узганга күрә, күбесе дулкынлануын яшермәде. Бирегә барлыгы сиксәнгә якын артист чакырылган. Безгә таныш булган артистлар арасында Айдар Галимов, Элвин Грей, Гөлназ Асаева, Зифа Нагаева, Ризван Хәкимов, Әнвәр Нургалиев, Илшат Вәлиев, Гүзәл Әхмәтова, Марат Шәйбәков, Лилиана Ирназарова, Айгөл Габдуллина, Илмир Газизуллин, Илшат Яппаров, Идрис Кәлимуллин, Идрис Газиев, Лилия Биктимерова, Фәдис Ганиев, Мирхәт Гайсин, Фәридә һәм Роберт Тимер-

баевлар, Рөстәм Шакиров, Флорида Исмәгыйлева, Резедә Байтирәкова, Инсаф Галимов, Искәндәр Газизов, Алмаз һәм Айдар Юнысовлар, Ләйлә һәм Рөстәм Галиевләр, Флера Шәрипова, Наил Шәймәрданов һәм башкалар бар иде.

Башкортстан йолдызлары кызыл келәмгә чит ил машиналарында килеп туктады. Аларны иҗатларына гашыйк булганнар алкышлап каршы алды. Халык арасында интрига булдыру өченме, Элвин Грей белән Гөлназ Асаева келәмнән бергә узды. Бу пар банкетта да бергә утырды. Кызыл келәм – бәйрәмнең беренче өлеше, икенче өлеше ресторанда банкетта дәвам итте. Кичәне «Туган тел» каналының алып баручылары Айгөл Габдуллина, Лилиана Ирназарова, Роза Хәйруллина һәм Дилара Хәбибуллина алып барды. Бу кызлар үзләре дә өздереп җырлый! Башкортстанда барысы да җырлый белеп туамы әллә соң ул, дигән уй туды күңелемдә.

### «ТАТАРСТАН АРТИСТЛАРЫН БАШКОРТСТАНГА КЕРТМӘСКӘ ТЫРЫШАМ»

Мәҗлестә кайбер артистларга сүз бирелде. Әмма алар сүз әйтеп кенә калмады, коллегаларын җыр аша сәламләде.


«Мондый форматта, шушындый атмосферада хезмәттәшләремне күрергә шат. Сәхнә – ул сәхнә, ә без корпоративка җыелдык. Без – кунаклар ролендә, игътибар безгә юнәлтелгән булуына өйрәнмәгәнбез дә. Шуңа күрә башта үзебезгә сәерсенеп тә карап тордык», – диде Айдар Галимов.


«Туган тел» ачылган көннән бирле аның белән хезмәттәшлек итәм. Ул – минем беренче сукмагым. Җитәкчеләргә, артистларга – һәркайсына рәхмәтемне белдерәм. Бу чараның дәвамлы булуын телим. Банкет кына оештыру димәгән, җыелышып табигатькә чыгарга, ауга яки балыкка барырга да мөмкин», – дип сөйләде Элвин Грей.

Әлеге бәйрәмне оештыру идеясен телеканалның баш мөхәррире, җырчы Лилиана Ирназарова тәкъдим иткән. «Җитәкчебез Азат Вахитов тәкъдимемне хуплады. Бу бәйрәмгә нибары санаулы көндә генә әзерләндек. ТТstarpartyда матур булу өчен унбер көн эчендә җиде килога ябыктым. Өч көн буе бернәрсә дә ашамадым, су гына эчтем», – диде чибәр алып баручы. Аның әйтүенчә, тиздән бу чара Казан шәһәрендә дә үткәреләчәк.

Бу хакта исә «Туган тел»нең генераль директоры Азат Вахитов тулырак сөйләде. «Казанда телеканалның офисы ачылачак. Уфа артистлары катнашында концерт куярга планлаштырабыз. Бездә алар танылган, популяр булса да, Татарстан тамашачысы аларны белми әле. Шуңа күрә мин Татарстан артистларын кертмәскә тырышам, чөнки аларның барысын да күрсәтә башласак, үзебезнекеләргә игътибар кимиячәк. Нәкъ шул сәбәпле, бүгенге кичәгә,







Илшат Вәлиевтән кала, бары тик Башкортстанда яшәүче артистларны гына чакырдык», – диде җитәкче.

### ТОРТ, САЛЮТ ҺӘМ «ТУГАН ТЕЛ»

Азат Вахитов Казанда ачылачак филиалда Татарстан артистлары белән дә эшләргә теләвен белдерде. «Мин Казанда эшли торган «ТМТВ» һәм «Мәйдан» каналларын күзәтеп барам. Алар да, «Туган тел» дә бер-берсеннән бик нык аерыла, хәтта җырлары да башка төрле. Һәркайсының үз тамашачысы. Әйтик, безне күбрәк өлкән буын карый. Башкортстанда безне сиксән процент халык тамаша кыла, дип әйтә алам. Рейтингыбыз яхшы, әлегә безнең көндәшләребез юк. Әлбәттә, без Татарстан каналлары белән көч сынаша алмыйбыз, чөнки анда безне карый башладылар гына әле», – диде ул.

TTstarparty кичәсенең чыгымнарын да телеканал үзе күтәргән. «Бу чарага бер артисттан да акча алынмады. Чыгымнарны санап тормадык, якынча – 200-300 мең сум. Сер түгел, мәдәният өлкәсендә артык акча эшләп булмый, безнең максат – милләтне, сәнгатьне күтәрү. Артистларның канәгать булуы йөзләренә чыккан. Бу көн тарихка кереп калачак, диделәр. Гадәттә, сәхнә осталары кеше күңелен күрә, бүген исә без аларның күңелен ачтык. Икенчедән, артистларга безнең белән бергә булганнары өчен бу рәвешле рәхмәт белдердек», – диде Азат Вахитов.

Җырчылар зур торт белән чәй эчкәннән соң, урамга салют карарга агылды. Кичә исә «Туган тел» җырын җырлап тәмамланды. Бәйрәм бик күңелле узды. Монда җыелган кайбер артистларның дәрәҗәсен чамаласам да, берсе дә үзен югары тотмады, шулкадәр гади булды алар. Җитәкчеләре дә, артистлар да бергә күңел ачты, арыганчы биеде.

### АРТИСТЛАР ТУРЫНДА ЯЗУНЫ ТУКТАТЫЙК?!

Татар эстрадасы артистларының үзара мөнәсәбәтен яхшы беләм. Күбесе үзләре үк «артистлар арасында дуслык юк», ди. Татарстанда бердәмлек


бик юк шикелле. Популяр артистлар белән бик үк танылмаган артистлар арасында зур ара барлыгы сизелә. Моның сәбәбе – йолдызлык чире. Икенче бер сәбәбе – җырлый белсә дә, белмәсә дә сәхнәгә менү. Уйлануларым белән инстаграмдагы аккаунтымда да уртаклаштым. Кайтаваз буларак яңгыраган бер-ике фикерне сезгә дә тәкъдим итәм:

«Башкортстан артистлары вокал буенча көчлерәк, моңлырак. Татар эстрадасы артистларының мин-минлеген бетерүнең бер генә юлы бар – аларны мактап язуны, танытуны туктату», – диде танылган шоумен Илдус Закиров. «Бездә йолдыз чире белән авыручы йолдызлар шулкадәр күп! Үзләренә әйтсәң, «юк, мин андый түгел!» диләр. Югыйсә, читтән яхшырак күренә. Бигрәк тә журналистларга», – ди каләм әһеле Галия Рахман.


Башкортстан артистларының үзара җылы аралашуына шаккатуымны күреп, бер җырчы болай диде: «Татарстан артистлары артык популяр, шуңа күрә алар борынын чөеп йөри. Ә безнең артистларда андый әйбер бөтенләй юк. Менә кайсын гына алмагыз, берсе дә үзен әллә кемгә куймый. Барысы да бер-берсенә карата ихтирамлы, ихлас һәм гади». Моның хак булуына инандым, чөнки алар таныш булмаган кеше, ягъни минем белән дә (каян һәм кем икәнемне әйтмәгән килеш) ачылып сөйләште.

## ТАТАРСТАНГА БАРЫБЕР КИЛӘЧӘК АЛАР!

…Минемчә, Башкортстан эстрадасы берничә елга артта калган сыман. Алар әле шоу-бизнесның асылын аңлап бетерми, йолдызлык чирен йоктырмаган. Ләкин, ни кызганыч, бу чир аларны урап узмаячак. Бигрәк тә Татарстанга килсәләр. Ә алар Татарстанга юл тотачак! Күбесенең иң зур хыялы – Казанга килү, монда танылу. Моңлы җырчыларга Татарстан тамашачысының күңелен яуларга һәм һәрвакыт гади булып калырга язсын!










**Сөмбел Әхмәтҗанова ,**
*Сәләтлеләр Университеты Медиа Лабораториясе*

# «ХАЛКЫМНЫҢ ТАГЫН ДА ГРАМОТАЛЫ БУЛУЫН ТЕЛИМ»

## Әлмәт шәһәреннән 5 сыйныф укучысы Сколковода урыс теле буенча онлайн-проектын тәкъдим итте




Июнь башында Әлмәттән бер төркем мәктәп укучылары – «Бир бишне» («Дай5») проектында җиңүче команда Сколковода узган Startup Village конференциясендә катнашты. Катнашучыларның берсе – 2016 елда Сәләтлеләр Университетының «Сәләтлеләрне ачу» җәйге яшьләр мәктәбендә белем алган, Әлмәтнең 2 лицей укучысы Эвелина Мәҗитова. Ул безгә конференциянең Junior program мәйданчыгы һәм урыс теленә багышланган Rusmig авторлык проекты турында сөйләде.

**РУС ТЕЛЕ – МӘКТӘПТӘ ИҢ ЯРАТКАН ФӘНЕМ.** Мин еш кына рус теле буенча олимпиадаларда һәм фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашам. Илебездә яшәүче халыкның грамоталырак булуын телим.

**RUSMIG ПРОЕКТЫ – УРЫС ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮ БУЕНЧА 7-14 ЯШЬЛЕК БАЛАЛАР ӨЧЕН УЕН ФОРМАСЫНДА ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН САЙТ ҺӘМ TELEGRAM-БОТ.** Бердәм дәүләт имтиханнары, тестларга әзерләнгән мәктәп укучыларына да файдалы чыганак булып тора. Алар ярдәмендә урыс теле буенча булган белемнәрне төрле бүлекләр буенча тест режимында сынап карарга мөмкин.

**САЙТТАГЫ БИРЕМНӘРНЕ ҺӘМ КЕЙСЛАРНЫ ӘЗЕРЛӘҮ ӨЛКӘСЕНДӘ ОСТАЗЫМ – МИНЕМ ӘНИЕМ, УРЫС ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ ОЛЕСЯ МӘҖИТОВА.** 2016 елның җәендә Generation S 2016 предакселераторында читтән торып эшли башладым. Эшемнең нәтиҗәсе буенча, март аенда Мәскәүгә чакырдылар. Шунда минем проект белән Русиянең венчур компаниясе белгече, Мәскәү бизнес-тренеры Феликс Артеменко

Фотолар Сәләтлеләр Университеты Медиа Лабораториясеннән алынды

кызыксынды. Ул минем җитәкчемә әверелде, һәм без онлайн-хезмәттәшлекне башлап җибәрдек. Ул миңа Startup Village-2017 конференциясенә әзерләнергә ярдәм итте.

**OPEN INNOVATION STARTUP TOUR БӘЙГЕСЕНЕҢ ТӨБӘК ЭТАБЫНДА МИНЕМ ПРОЕКТНЫ STARTUP VILLAGE КОНФЕРЕНЦИЯСЕНДӘ КАТНАШУ ӨЧЕН САЙЛАП АЛДЫЛАР.** Rusmig – иң яхшы стартапларның берсе дип бәяләп, кубок белән бүләкләделәр. Конференция нәтиҗәләре буенча, миңа көз көне Мәскәүдә старт алачак стартаплар үсеше буенча халыкара программада катнашырга тәкъдим ясадылар. Startup Village та мин Generation S предакселераторының финалында чыгыш ясадым. Тамашачы мәхәббәтен яулаган өчен махсус бүләк һәм Нелли Орловадан InnMind.com CEO Инновацияләргә ярдәм итү фонды белән хезмәттәшлек итәргә тәкъдим алдым. Аңа минем Rusmig проекты ошаган, тагын... минем бик яшь булуым да гаҗәпләндергән. Стартаплар үсеше буенча программа эшли башлагач, миңа киләчәк хезмәттәшлек турында хәбәр итәчәкләр.

**STARTUP VILLAGE** конференциясендә мин төрле илләрдән килгән уңышлы эшкуарлар белән таныштым. Безнең алда IT, биомедицина, индустрия өлкәсендә эшләүче эшкуарлар чыгыш ясады. Иң истә калганы – Сан-Франциско эшкуары Артем Голдман (CEO Visabot һәм Legal Space) булгандыр. Ул ничек итеп хаталар аша сынаулар үтә-үтә уңышка ирешкәне һәм үзенең стартабын Америкада эшләтеп җибәүе турында сөйләде.

**ҮЗЕМНЕҢ ПРОЕКТ ӨСТЕНДӘ ЭШЛӘВЕМНЕ ДӘВАМ ИТӘЧӘКМЕН.** Сайтны үстерү, квалификацияле программист табу, мобиль кушымта чыгару һәм InnMind.com Инновацияләргә ярдәм итү фонды белән хезмәттәшлек итүне планлаштырам. Әлеге Фонд БДБ һәм Көнчыгыш Аурупа стартапларын инвесторлар, белгечләр һәм индустрия җитәкчеләре белән бәйли. Минем идеяләрем күп, ләкин әлегә техник яктан аларны мөстәкыйль тормышка ашыра алмыйм. Мобиль кушымта сайтның дәвамы булып торачак һәм без аны тормышка ашырырга тырышачакбыз.









Лиана Мәрданова

# ЗӘРИНӘ ХӘСӘНШИНА: «Җебеп торырга яратмыйм»



«Казан егетләре» белән «Ак чәчәкләр» җырын башкарганнан соң, җырчы Зәринә Хәсәншина тагын да танылып китте. Карап торышка бик җитди, усал кебек тоелса да, аралашканда Зәринәнең нечкә күңелле булуын аңлыйсың. Кыскача менә шулар, ә тулырак хәзер танышырсыз...

**Туган урыны:** Балык Бистәсе, Тәберде Чаллы авылы;
**Туган көне:** 26 март 1995 ел;
**Белеме:** И. Әухәдиев исемендәге Казан музыка училищесы, бүгенге көндә Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә белем ала;
**Ярата:** туры сүзле, төгәл булу;
**Яратмый:** икейөзлелек, кешегә яраклашу;
**Инстаграмы:** @zarinakhasanshina.

**Зәринә, әниең – укытучы, әтиең – хисапчы. Ә синдә җырга мәхәббәт кайдан барлыкка килде?**

Җырга сәләт әниемнең әтисе – бабамнан килгән, диләр. Ул моңлы итеп җырлаган һәм көчле көрәшче дә булган. Мин җырласам, энем спорт белән мавыга, җәен туп типсә, кышын хоккей дип, шугалактан кайтып та керми. Бабамның сәләтләре икебезгә дә күчкән.

**Ничә яшьтән җырлыйсың?**

Үземне белә башлаганнан бирле. Балалар бакчасында һәр ел Кар кызы итеп куялар иде. Яңа ел җырларын яратып башкардым. Шуннан башланып китте кебек. Һәм чынга ашарлык хыялга, максатка әверелде.

Руфинә Булатова фотосы

**Җырчы булыр өчен нинди сыйфатлар кирәк?**

Үҗәтлек һәм сәләт.

**Сәләт кирәклеген аңларга була. Ә җырчы кешегә үҗәтлек нигә?**

Кеше арасына чыгар өчен. Җебеп торсаң, көндәшләр «таптап» китәргә дә күп сорамас.

**Сәләт мөһимрәкме, әллә тырышлык та җитәме?**

Иҗат өлкәсендә сәләтсез булмый, билгеле. Сәләт белән уңышка ирешү җиңелрәк. Ләкин тырышлык һәр эштә, һәрвакыт кирәк. Кеше җигелеп эшләгәндә, сәләтле кеше йоклап ятса, артта калуы да бар.

**Җырчы һөнәрен сайламасаң, кем булыр идең?**

Полиция хезмәткәре. Формалары матур. Аларның, җырчылар кебек, башка һөнәр ияләреннән аерылып торулары җәлеп итә.

**Җырчы булып кына тормыш көтеп буламы соң?**

Була. Менә яшибез бит әле. Әлбәттә, хатын-кызга бу өлкәдә күпкә авыррак, дип уйлыйм. Терәк булырлык, сине аңларлык тормыш иптәше табу җайсыз. Ә хатын-кыз өчен иң мөһиме – шул.

**Бу темага килеп кергәнбез икән инде, дәвам итик. Күптән түгел мәхәббәт турында «Син дия» дип аталган җырың дөнья күрде. Зәринә Хәсәншинаның йөрәген яулаучы бармы?**

Сер булып калсын... *(Елмая.)*

**Синең, гомумән, гашыйк булганың бармы?**

Мин тиз гашыйк була торган кеше. Ләкин шулай ук тиз сүреләм дә. Әни миннән: «Ширпы кебек дөрләп янасың да шундук сүнәсең», – дип көлә инде. Ләкин чын-чынлап яратканым бар, дип әйтә алам.

**Сөйгән ярың нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

Әтиемә охшавын телим. Кырыс, үз сүзен әйтә торган. Хатын-кызны хөрмәт итсен.

**Фотоларда, видеоларда сине «Казан егетләре» төркеме белән күрәбез. Синең аларга бәйлелегең нинди?**

«Казан егетләре» белән 2013 елдан бирле эшлим. Бергәләп концертлар куябыз, ел дәвамында гастрольләргә чыгабыз. Гомумән, аларның канаты астында, дисәм дә була. Мине «Татар моңы» конкурсында күреп, шылтыраттылар. Үзләре белән гастрольләргә йөрергә җырчы кыз эзләгәннәр икән. Беренче гастрольләрдә чын мәгънәсендә сынау уздым. Хәзер менә бишенче концертлар сезонына әзерләнәм. Мин аларга бик рәхмәтле!

**Араларында Айдар Әгъләмов исемле буйдак егет тә бар. Арагызда нинди мөнәсәбәтләр?**

Яхшы дуслар. Кеше ни сөйләмәс, әмма без – коллегалар. Дистанцияне тота беләбез.

**Үзеңә үрнәк итеп кемне куясың?**

Беркемне дә үрнәк итеп алганым юк. Ләкин еш кына социаль челтәрләрдә уңышка ирешкән кешеләрне карап, үземә мотивация алам. Алар миңа тик торырга бирмиләр (*көлә*).

**Җырларың белән тамашачыларны сөендереп торасың. Клибың да бар. Иҗатыңда тагын нинди яңалыклар көтәргә?**

Яңа сезонда яңа җырлар булачак. Араларында яңартылган ретро-җырлар да, төрле авторлар иҗат иткән өр-яңа әсәрләр дә бар. Ә көз ахырларында тагын бер клип төшерергә планлаштырам. Әлегә нинди җырга икәнен әйтмим – сер булсын.

**Зәринәнең иң зур хыялына килсәк?**

Хыялларым бик күп. Санап бетерә торган түгел. Ләкин аларның һәрберсен чынга ашырып барам.

**Син бүген консерваториядә белем аласың. Уку авырмы?**

Авыр... Консерваториядә без классик әсәрләр башкарабыз. Тавышым – лирик сопрано, ләкин эстрадада алай җырламыйм, чөнки тамашачыларның бер-икесе генә сине мөкиббән китеп тыңлаячак, ә күпчелек өнәп бетерми. Классиканың югары музыка икәнен һәркем аңлыйдыр. Шуңа күрә быелгы концерт программасына, берне генә булса да, чит ил классик әсәрен кертергә ниятлим.

**Һөнәрең буенча кем булачаксың?**

Җыр укытучысы, җырчы, мәдәният хезмәткәре.

**Димәк, Зәринә Хәсәншина укытучы булып китәргә дә мөмкин?**

Бик мөмкин. Балаларны яратам, укытырга сәләтем дә бар, дип саныйм.

**Егерме елдан соң Зәринә Хәсәншинаны сурәтлә әле...**

Ул вакытта Хәсәншина булмам дип өметләнәм *(көлә)*. Илле яшен кырлаган җырчы Зәринә шундый ук гади булып калыр ул. Әлбәттә, барысын да белеп бетереп булмый, иң мөһиме, исәнлек диләрме әле?..

Зәринә Хәсәншина белән шәхсән таныш булмаганнар өчен әйтәм: җырлавы ничек сокландыргыч булса, күңеле дә шундый ук: тыйнаклыгы, эчкерсезлеге белән ул күпләрне таң калдырыр иде... Шундый булып кал һәм җиһанга яктылык өләш, Зәринә!

Рәйсә Борһаниева

# ЛИЛИЯ КАДЫЙРОВА: «Креативлыкның милләте юк!»

TMTV – Татар музыкаль каналы. Анда җор телле, кыю, шаян, тырыш яшьләр эшли. Биш ел дәверендә алар бик кызыклы проектлар оештырды. «Без мәҗбүри бөтен кешене татарча сөйләтә, җырлата алмыйбыз. Махсус кануннар да кабул итү хокукыбыз юк. Без бары тик туган телебездә сыйфатлы контент булдырырга тырышабыз. Үз телебездә тәүлегенә егерме дүрт сәгать эшләгән һәм тамашачыда иң популярлар рәтендә булып, яратып карый торган телеканал нәкъ менә шул телне саклау максатыннан булдырылды», – ди телеканалның баш мөхәррире Лилия Кадыйрова.



Марат Хафизов фотосы

**– Лилия, укучыларыбызны үзең белән таныштыр әле.**

– Гүзәл табигатьле Кама Тамагы районындагы Келәнче авылында туып үстем, КДУның журналистика һәм социология факультетында белем алдым. Юлымда һәрчак профессионаллар очрап торды. Деканыбыз, профессор Васыйл абый Гарифуллин: «Әгәр диплом артыннан гына килмәгәнсез икән, укыган арада бай кияү табып кияүгә чыгу өчен генә йөрмәсәгез, әлеге һөнәр буенча китәргә уйласагыз, укыганда ук үзегезне азмы-күпме күрсәтергә тиешсез, укуны тәмамлаганда эшкә ярый бу, дип кемдер көтеп торырга тиеш», – дип әйтә иде.

Атнаның бер көне иҗатка багышлана, ул көнне кая да булса эшләп үткәрергә кирәк. Башта газеталарга яздым, аннан «Татарстан – Яңа гасыр» каналында хәбәрче булып, практика үттем, «Матбугат ру» порталында каләм чарладым. Данил Сәфәров белән танышкач, аның фикерләү рәвеше якын тоелды мина, бүгенгәчә аны алдынгы карашлы журналист итеп саныйм. Ул журналистиканың аермасын күрергә өйрәтте. Газетада яратып укылган материалны интернет-порталда ачып та карамаска мөмкиннәр. Газета-журналга язган мәкалә, теле-, кибер-журналистика... Бу өлкәләр төрле. Үзеңне табыйм дисәң, һәрберсендә эшләп карарга кирәк.

Журналистика өлкәсендә формалашуымда зур роль уйнаган икенче кеше – Илфат абый Фәйзрахманов. Телевизион журналистиканың нечкәлекләренә өйрәтте ул мине. Ә иң мөһиме – һәрвакыт кеше булып калырга! Мин журналистикада аның кебек принципиаль (яхшы мәгънәсендә) кешеләрне башка белмим дә бугай. Журналистлар бәйрәмнәрендә катнашып, шәхесләр белән аралашып, алардан үрнәк алганбыз. Мәрхүм Илфак абый Шиһаповка рәхмәтлемен, ул да остазларымның берсе. «Лайтовый стиль»не дә ул ачты. Телевидениедә эшләү – балачак хыялым. Әниемнең туганы – журналист Рәйсә Гәрәевага гел сокланып карый идем. Фәнни хезмәтемне дә ул алып барган «Аура любви» тапшыруы турында яздым. Көн-төн Рәйсә апа янында идем, барысын да күзәтеп, булышып, өйрәнеп йөрдем. Нәтиҗәдә, ул эш миңа бик якын тоелды. Кызганыч ки, бездә телевидение журналистларын әзерләп чыгара торган ныклы базалы мәктәп юк, бары нигезләрен генә укыталар, юнәлеш бирәләр.

**– Үзегезгә эшкә урнашырга килгән кадрларны ничек сайлыйсыз?**

– Кадрлар бөтен нәрсәне дә хәл итә! Кайвакыт биш кеше белән озаклап эшлисе эшне, бер кеше белән дә җиренә җиткереп башкарырга мөмкин. Әгәр эшләргә ашкынып, күзләре янып тора икән, кадрны үзеңә ясарга кирәк, дип уйлыйм. Мәскәүләрдә махсус белем алганнан соң кире сиңа эшкә кайтыр дип өметләнеп утыруның мәгънәсе юк, мин белгәнне өйрәтү яклы. Бер команда бит. Журналист белгечлеге буенча укыганы белән театр училищесы студентын бергә кушсаң, бездә эшләргә яраклы хезмәткәр килеп чыгарга мөмкин. Үзем тәҗрибәне төрле урыннарда эшләп тупладым. «Татарстан – Яңа гасыр»да практика үтеп йөргәндә, өлкәнрәк курстагы кызлар Мөселман киносы фестивален үткәрүдә булышырга тәкъдим итте. Чөнки халык күп килә, чит илдән кунакларны каршы алырга, алар белән эшләргә кирәк. Шулай итеп матбугат үзәгенә эләктем. Төрле илләрдән килгән кешеләр бөтенләй башка, алар шундый ирекле, шул ук вакытта әдәпле, зыялы, акыллы, бәхетле – күзләремне зур итеп ачып, исем китеп карап торуларым әле дә хәтеремдә. Бу өлкә иҗатка гына түгел, оештыру сәләтенә, теләсә нинди шартларда эшеңне җиренә җиткерергә өйрәтә. Өч ел кинофестивальдә хезмәт куйдым, «Татаркино» оешмасында матбугат үзәге эшен алып бардым. Сыйфатлы видео, контентны тоемлау, ясарга өйрәнгәнем өчен мин кинофестивальгә рәхмәтле. Шул чакта үземне кызыксындырган видео дөньясында белемнәрне арттырырга кирәклеген тойдым.

**– Татарда креативлык бармы?**

– Креативлыкның милләте юк! Кыю идеяләр, үзенчәлекле караш булу – бер нәрсә... ә аны кабул итү кайвакыт бик катлаулы процесска әверелә. Олырак кеше синең фикерең белән килешмәскә мөмкин. Креатив фикерләү җенестән дә, яшьтән дә тормый. Бездә креативлык җитми, дип язарга ярататалар инде. Аклану өчен түгел, аерманы тояр өчен генә, бер мисал китерәсем килә. Бөек Ватан сугышыннан соңгы авыр заманнарда Американың «Дисней» клубы бар көченә эшләп торган. Күңел ачу индустриясе дигән төшенчә булган! Бездә «татарча күңел ачу индустриясе» дигән төшенчәне соңгы егерме ел эчендә беренче тапкыр «Барс медиа» Татар Медиа Группасы эшли башлады. Ә америкалылар 1934 елда ук «Белоснежка и семь гномов»ны күрсәтеп, сигез миллион доллар акча эшли! Без бу өлкәдә беренче адымнарны гына ясыйбыз. Яңача эшләнгәнне башта кабул итмиләр, тәнкыйть утына тоталар. Хәтта яшь җырчылардан да «Бу безнең татар халкы өчен түгел, мине аңламаячаклар, авылыбызда бик матур урыннар бар», дигән фикер ишетергә туры килә. Эшләп карамый торып, каян белә ул аны?! Әнә Элвин Грей икеләнеп тормады, эшләп карады һәм уңышка иреште.

**– Телеканалда ничә кеше эшли?**

– Без – уникe кеше. Иң мөһим сыйфат – тырышлык. Практика узарга дип журфактан да, мәдәният һәм сәнгать институтыннан да килгәлиләр. Социаль челтәрләрдә дә язалар. Шәхсән үземә иртәнге сәгать дүрттә торып клип төшерергә чыгып китүнең бер кыенлыгы да юк. Ә кайбер практика үтүче студентларым йә йоклап кала, йә өлгерми, иртән тора алмый икән, имеш. Таркаулык ялкаулыкка китерә. Үзеңне кызганып, җайлы урыннар гына эзләп йөрсәң, шундый дулкынга ияләшәсең. Мин үз организмымны

үзем теләгәнчә эшләргә мәҗбүр итә алам. Мине аңлап, эшемнең шул якларына түзеп яшәгәненә ирем Айнурга рәхмәтлемен.

**– Синең кебек яшь, мөлаем хатын-кызга җитәкче булу авыр түгелме?**

– Эш процессында төрле хәлләр була. Кайвакыт кешегә бирем бирәсең. Үзем бу эшне бик тиз генә җиренә җиткереп эшли алам. Ә кушкан кешегә аның очына чыгу кайвакыт авыррак, күбрәк вакыт таләп итә. Бәлки сыйфат ягы да син көткәнчә үк булмас. «Көне буе шуны эшләдеңме, балакай?» – дип әйтәсе килә. Ләкин үземне туктатам. Йодрыкларымны кысып төйним дә, тырнакларым уч төбенә батып кергәнен тоюга, мин әйтәсе сүзләрдән шушы кешенең күңеле дә шулай яраланачак, дип уйлап куям. Сабыр гына тагын бер кат аңлатам, тәмам өйрәтеп бетермичә тынычланмыйм. Җырчылар белән аралашканда да үзенә күрә бер психолог булу кирәк. Алар еш кына үпкәлиләр, күңелләре дә кителә, ләкин күпмедер вакыттан мөнәсәбәтләр барыбер җайлана. Шуның өчен дә иҗат бит ул, катлаулы процесс!..

**– Шоу-бизнеска кагылышы булган шәхесләр иртәме-соңмы җырлый башлый. Синең дә җырлар яздыру, аларны сәхнәдән башкару теләге юкмы?**

– Мин җыр-моңга гашыйк гаиләдә үстем, бала чагымда рәхәтләнеп җырладым. Әлеге күңелле, татлы мизгелләр барлык тормышыма җитәрлек булды, шуңа күрә олы сәхнәләргә чыгып җырларга омтылышым юк. Әнием Ләлә гомер буе мәктәптә физика-математика фәнен укытты. Бүген мин нәрсәгә дә булса ирешкәнмен икән, болар барысы да әниемнең хезмәте. Чөнки ул миндә шәхес тәрбияли алды, үз-үземә ышанырга өйрәтте. Әтием Дамирга килгәндә, ул башта күмәк хуҗалык рәисе булды, хәзерге вакытта авыл җирлеге җитәкчесе вазифасын башкара. Гомере буе туган авыл, аның кешеләре дип яши, барлык көчен куя. Икесе дә бик тырышлар, туктаусыз янып-көеп йөри торган кешеләр. Әбием Гайшә искиткеч матур итеп җырлый иде. Авылыбызда аны Сандугач Гайшә дип атап йөртәләр. Якыннарым өчен җырлыйм, аларны да, мине дә канәгатьләндерә бу өй концертлары.

**– Шигырьләр язасың дип тә беләбез...**

– Элек күбрәк языла иде. Хәзер кызу темплы тормыш рәвеше үзең белән үзең аралашыр өчен вакытны бик аз калдыра. Аннары минем шигырьләр йә бик бәхетле, йә үземне бик бәхетсез итеп тойганда туа. Шуңа мин аны йә иремә генә, йә әнигә генә укытам – артыгы кирәкми... Шулай да бер искәрмә бар, берсенә җыр иҗатителде – Ләйсән Гыймаева репертуарындагы «Онытылмый, иркәм, сүзләрең» дип атала ул.

**– Мондый кызу темплы тормышта кызыңны тәрбияләргә вакытың каламы соң?**

– Кызыбыз Азалия актив бала, бик яратып рәсемнәр ясый, ару-талуны белмичә, төрле түгәрәкләргә йөри, мөмкин булганча балабызның теләкләрен истә тотарга, сәләтләрен үстерергә тырышабыз. Гаиләдә бер генә бала булуына карамастан, иркә түгел. Үзен җаваплы итеп тоярга ярата, берәр эш кушсаң, шуның өчен мактап та куйсаң, күңеле үсеп китә. «Үскәч кем буласың?» дигән сорауга: «Әни кебек матур булам!» – дип җавап кайтара.

Без – балаларны, балалар безне тәрбияли. Кызым белән телевизордан «День добрых дел» тапшыруын карыйбыз. Анда авыру сабыйлар, балалар йортлары турында сөйлиләр. Кайчак икебез дә елап җибәрәбез, фондка еш кына смс-хәбәр юллыйбыз. Әлеге гамәлем белән кызыма тормышта төрле хәлләр булырга мөмкинлеге хакында җиткерергә телим. Юк, куркыту өчен түгел. Үзенең ни дәрәҗәдә бәхетле икәнен тоеп торсын өчендер, бәлки.

**– Яшьләр татарча телеканал карамый, милли көйләрне яратмый, дип зарланалар. Мондый шартларда уңышлы эшләүнең сере нидә?**

– Телеканалның заманча эшләргә омтылуындадыр. Чыннан да, тамашачы төрле каналлар карый, аның сайлау мөмкинлеге бик киң. Яңача тапшырулар, яңартылган аранжировкалар, яңа стильләр, яңа техник чаралар, яңача бизәлеш. Без шулардан өйрәнергә, үзебезнең җирлеккә яраклаштырырга тырышабыз. Җитәкчебез Марат Мәүлет улы Гәрәевнең «Җыр – татар халкының иң еш кулланган продукты һәм нәкъ менә җыр аша татар телен саклап калырга мөмкин», дигән фикерен куәтләп, шуны әйтәсем килә – без мәҗбүри бөтен кешене татарча сөйләтә, җырлата алмыйбыз. Махсус кануннар да кабул итү хокукыбыз юк. Без бары тик туган телебездә сыйфатлы контент булдырырга тырышабыз.

Реклама хокукында